

Мөхсин Мөхәммәд Салих




# Палестина мәсьәләсе: тарихи җирлеге һәм 2001 нче елга кадәрге үсеше



Доктор Мехсин Мөхәммәд Салих

# ПАЛЕСТИНА МӘСЬӘЛӘСЕ:

*Тарихи җирлеге һәм 2001 нче елга кадәрге үсеше*

**КАЗАНЬ — 2005**

УДК 93/94
ББК 63.3
М86

Доктор Мехсин Мөхәммәд Салих
*Палестина тарихы һәм Яна Чор Гарәп тарихыннан профессор*

Гарәп теленнән Эльмира Әхмәтева тәрҗемәсе

**Доктор Мехсин Мөхәммәд Салих**

Палестина мәсьәләсе: Тарихи җирлеге һәм 2001 нче елга кадәрге үсеше. Казан. 2005. — 126 б

© Мехсин Мөхәммәд Салих, 2005.

**Бисмилләһи әр-рахмән әр-рахим**

## Такъдим

**Мөхәммәд әш-Шәйх Мәхмүд Сыйам:**

Экса мәчетенен элеккеге хатыйбы, хәзерге көндә Гизза Ислам университетында реислек хезмәтен алып баручы.

Палестина масьәләсен яктырткан китапларны соңгы елларда өстән өстән генә карап чыгарга күнеккәнмен, чөнки бу тема мина бик таныш: ул хакта күп укыдым, шул җирдә гомер иттем. Гадетемче, бу китап белән дә "күз йөртеп кенә танышырга" уйлаган идем, ләкин бу мөмкин булмады — китап беренче юлларыннан ук мине үзенә җәлеп итте һәм бик көчле кызыксыну белән укый башладым...

Мина калса, бу китапның төп үзенчәлекләрен түбәндәге фикерләргә туплап биреп булыр иде:

**Беренчедән**: язучы Палестина проблемасы барлыкка килүнең тарихи җирлеген һәм алга таба үсешен фәнни яктан җентекләп тирәнтен өйрәнүгә ирешкән.

**Икенчедән**: бу китап гыйльми стильде язылган булуга карамастан, һәр катлам укучысы да кабул итә алырлык дәрәҗәдә гади телдә язылган; шулай ук вакыйгаларның хронологик яктан тартипкә салынып бирелүе дә укучыларга язылганнарны жинел аңларга ярдәм итә.

**Өченчедән**: бу кечкенә генә китап үз эченә гаҗәеп дәрәҗәдә күп мәгълүмат сыйдырган, лекин шуна да карамастан ул укучыны туйдырмый да, арытмый да, "битләрдән йөгереп үтергә теләк тә тудырмый, киресенчә, беренче битләреннән үк укучыны җәлеп итеп, соңгы юлларына җиткәнче үзенә тартып тора.

**Дүртенчедән**: автор хакыйкатьлерне турыдан-туры, ничек бар шулай ача, бу хакта моңарчы әйтелгәннәргә сукырларча

иярми, шулай ук фикерларен матурлау өчен хакыйкатьне "купертеп, зиннәтләп" бирүләрдән дә ерак тора.

**Бишенчедән**: бу китап түбәндәге әһәмиятле темаларга туктала:

1) Палестина тарихы борынгы чорлардан алып хәзерге көннәргә кадәр хронологик тәртиптә бирелә.
2) Палестина жирендә гомер итүче гарәп милләте бу җирдә ин озак яшәгән милләт булып санала.
3) Палестинада иң озак вакыт халык белән бергә гармониядә яшәгән дин- ислам дине.
4) Яһүдләрнең Палестина җиренә хак даулаулары аларның тарихларына һәм изге китапларына үз куллары белән ясалма үзгәрешләр кертүләре нәтиҗәсендә барлыкка килә.
5) Палестина тарихында күп сугышлар булып уза, ләкин жирнең төп халкы һәрвакытта да үз җирләрендә, үз ватаннарында яшәүләрен дәвам итәләр.
6) Бетенденья колониясе хәленә төшү, яхшы уйланылган сионист фикеренең бик кызу үсеше һәм шулай ук бетен денья тарафыннан сионистларга бирелгән көчле ярдәм дә Палестина халкын үз ватаннарын һәм изге җирләрен яклап сионистларга каршы бер-бер артлы баш күтәрүләрдән туктата алмый.
7) Әл-Кудс, Әкъса мәчете һәм гомумән, изге Палестина жире Үзенең әһәмиятен югалтмаган. Сионистларның Әкъса мәчетен мыскыллаула- рына протест рәвешендә күтәрелгән халык көрәше, шуның ачык мисалы булып тора. гареп һәм мөселман халкы ечен
8) Бу китапта бирелгән тикшеренүләр һәм анализлаулар Палестина мәсьәләсен бары тик тыныч юл белән генә хәл итүнен бөтенләй мөмкин түгеллеген дәлилләп тора.
9) Бу проблемадан чыгу юлы бары тик бер генә — кораллы каршылык. Палестина сафларын туплап, ватаннарын азат итеп, аннан залимнарны куып чыгару гына Палестина жиренә һәм халкына яңадан тыныч тормыш алып киләчәк.
10) Палестинадагы ислам хәрәкәте, башка җирле азатлык хәрәкәтләрен дә үзе артыннан ияртеп, бу изге көрәштә

Аллаһ Тәгалә ярдәме белән әйдәп баручы көч булыр һәм жиңүгә иреше, инша Аллаһ

Сонгы сүз итеп, Палестина проблемасының тарихын, Хозерге көндәге торышын, гомумен, сионистлар белән барган бу корошнен чын асылын белергә теләгән һәркемне шушы китапны укырга чакырабыз.

Аллаһ Тәгалә авторга шушы тырышлыгы һәм хезмәте өчен үзенец эжерен һәм иң хәерлесен бирсә иде.

Әл-хәмдүлилләһи Раббил ‘әләмин.

*Доктор Мөхәммәд Сыйам.*
*Куала Лумпур, 16-9-2001 нче ел.*

## Язучының кереш сүзе.

Галәмнәрнең раббысы булган Аллаһ Тәгаләгә хәмедлә- ребез һәм анын илчесе Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзене, гаиләсено һәм сахабәләренә салават, сәламнәребез барып ирешсә иде.

Бу китапта Палестина мәсьәләсе буенча алып барылган фәнни эзләнүләребез бергә туплап кыскартып бирелә. Башта хезмәтне "Жир", "Халык", "Дошман", "Кераш" кебек өлешләргә бүлеп язарга уйласак та, бу рәвешле язу фикерләрне кыска итеп бергә туплап бирүдә авырлык тудырып, китапның күләме артык озынга китәргә мөмкин иде. Нәтиҗәдә, хезмәт тарихи вакый галарның үсеш хронологиясе һәм мантыйкый фикерләү эзлек- лелеге буенча фасылларга бүленде. Бу бүленеш рәвеше укучыга топ проблеманы һәм тарихи вакыйгаларга бәйле рәвештә барлыкка килгән үзгәрешләрнең сәбәпләрен дөрес анларга ярдәм итәр дигән теләкте калабыз

Укучы кулындагы бу китап Палестина мәсьәләсе буенча гомуми могълумот алырга теләгәннәргә атап язылды, шуңа да кечкенә кеса китабын хәтерләтә, тиз укыла, янда йөртергә дә унайлы... Бу тема белән кызыксынып та, өйрәнергә буш вакыт таба алмаганнарга хезмәтебез бик матур бүләк булыр дип уйлыйбыз.

Бу хезмат Палестина балаларының үз җирләренә хаклары булуга, бу жирнең мөселман-гарәп жире икәнлегенә һәм кыямәт көненә кадәр аларныкы булып калачагына инанып язылды.

Гомумән алганда, китап фәнни-академик хезмәт булып тора, шуна да карамастан, мөмкин кадәр җиңел тел кулланып, бөтен халык катламы да аңларлык дәрәжәдә язарга һәм мөмкин кадор тулы мәгълүмат бирергә тырыштык.

Бу китап Аллаһ Тәгалә ризалыгы өчен булсын иде.

# БЕРЕНЧЕ ФАСЫЛ

## Палестина мәсьәләсенең барлыкка килу тарихы

Палестина проблемасының гарәпләр һәм, гомумән, мөселман деньясы өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуын түбәндәге өч төп сәбәп белән аңлатып булыр иде:

**Беренчедән**: Палестина жиренең изге һәм бәрәкәтле табигате һәм мөселманнарның бу җиргә рухи һәм дини яктан бик нык бәйләнгән булуы

**Икенчедән**: дошманның бу җиргә булган низагы — аларнын дини ышануларының бер өлеше һәм Аллаһтан аларга бирелгән вәгъдә итеп кабул ителүе. Шул сәбәпле, ислам һәм меселманнарга карата булган күралмау хисләренең сионист- яһүдләр күңелендә тарихи һәм идеологик яктан бик Тирен урнашкан булуы

**Өченчедән**: көнбатыш-сионист проектынын империалистик табигате: көнбатыш цивилизациясе һәм сионистларның ислам Доньясын бүлгәләү, зәгыйфьләндерү һәм югары державаларның гегемониясе хәлендә саклау максаты белән бергәләшеп эш йертүе аны

Сионист идеологиясенә корылган Израил дәүләте 1948 нче елда нәкъ менә мөселман Өммәтенең үзәге булган Палестина жирендә шытып чыга. Бу яна дәүләттән янаган көчле сәяси һәм хәрби куркыныч бөтен моселманнарны берләшергә һәм Палестина халкы җитәкчелегендә азатлык көрәше юлына басарга этәрә.

Палестина жирендә туган бу проблема, берничек тә бары тик бу ил гарәпләре проблемасы гына булып кала алмый, чөнки Израилнен нәкъ менә Палестина җирендә барлыкка килүе үзе үк бу программаның алдан ук яхшы уйлап эшләнелгән Көнбатыш- Яһуд программасы икәнен бик ачык раслап тора. Европада явудлар проблемасы барлыкка килу, яисә Христианнарда

яһудларга карата дини симпатия хисләре тууы гына, берничек то бу яна сукбайлар иле барлыкка килүнең бердәнбер төп сәбәпләре була алмый. Хакыйкатьтә Көнбатышның яһүд проблемасын Палестина халкына золым салып, аларны ватаннарыннан куып чыгарып, үз дәүләтләрен булдырудан мәхрүм итеп хәл итүләре һәм бөтен моселман халкының тынычлыгын куркыныч астына куюлары аларның ни дәрәҗәдә гаделсез һәм залим икәнлекләрен исбатлап тора. Шунысы кызык: бу гаделсезлек һәм кешелексезлекләр барысы да Көнбатыш үзен кеше хокукын һәм донья тынычлыгын тәэмин итүче һәм саклаучы көч дип игълан иткән чорда, нәкъ менә аның үзе тарафыннан эшләнә.

**Палестина:**

Палестина элеше ул Азия Палестина исеме белән Билəд Әш-Шәм (Зур Сирия) территориясенең көньяк-көнбатыш атала, континентының көнбатышына һәм Урта диңгезнең көнчыгыш ярына урнашкан. Аның урыны стратегик әһәмияткә ия: ул исламның ике канаты булган Азия һәм Африка арасына урнашып, аларны тоташтыручы меһим звено ролен үти.

Археологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, Палестина жирендә Борынгы гасырлардан бирле кешеләр яшэгән. Табылган экспонатлар анда яшәгән кешеләрнең хәтта хайван асраучылык чорыннан игенчелеккә күчеш чорын кичерүләрен дә раслап торалар. Шулай ук, кешелек тарихындагы иң борынгы шәһәр булган Иерихон (Жерико) да б.э.кадәр 8000 нче елларда нәкъ мене Палестина жирендә төзелгән булган.

Палестина территориясе борынгы заманнарда анда яшәгән халык исеме белән "Кәнгән жире" (Ард әл-Кәнгән) дип аталган була. Кәнгәнлеләр бу урыннарга б.э. кадәр 2500 нче елларда Гарәп ярымутравыннан күчеп килгән булалар. Палестина исеме иса сонрак бирелә, ул — Диңгездән килгән кешеләр кавеме исеменен күплек формасы. Фараз ителгәнчә, бу кавем б.э. кадәр 12 нче гасырларда Көнбатыш Кече Азия һәм Агеан диңгез ягыннан килгән була. Аларнын исемнәре борынгы Мисыр кульъязмаларында "П, Л, С, Т"хәрефләре белән бирелгән, ә "Н" хәрефе исә күплек сан кушымчасы буларак өстәлгән булса кирәк.

Бу халык башлыча яр буйларына урнашып яши, кәнгәнлеләр белән тиз арада ассимиляцияләшеп, бары тик исемнәре генә бу жирга бирелеп сакланып калына.[1]

Илнен чикләре, 1920-1923 нче елларда Британия тара-фыннан тегал билгелән куелганчы, тарихи вакыйгалар нәтиҗәсендә еш үзгәреп торган. Әмма тулаем алганда, Палестина жире тарих дәвамында Урта диңгез, Үле диңгез һәм Иордан елгалары арасына урнашкан территорияне үз эченә алган була.

Ислам чорында Биләд әш-Шәм әжнәд (берлек саны: жүнд) ягъни өлеш, провинцияләргә бүленгән булып, Палестина исә шуларның берсен тәшкил итә. Ул Мисыр Синаеннан алып, хәзерге Женин шәһәреннән 18 километр төньякта урнашкан әл- Ләжжүн шәһәренә кадәрге территорияне үз эченә алган була. Ислам тарихы буенча бу бүленешләр кайбер үзгәрешләр кичерса дә, Палестина һәрвакытта да Биләд әш-Шәмнең бер өлеше булып кала, халкы үзен мөселман өммәтенең бер өлеше итеп саный.

Хәзерге көндә иса Палестинаның территориясе 27009 квадрат километр исәпләнә.[2]

Палестина ундырышлы Урта диңгез климатына урнашкан булып, бу халыкка тормыш алып барырга һәм авыл хужалыгын үстерергә уңайлы шартлар тудыра. Палестина жирен, гомумән алганда, өч төп регионга бүлеп булыр иде: яр буйлары тигезлеге, уртача таулы регион һәм Иордан елгасы регионы. Яр буйлары регионы сәүдә, икътисад һәм мәдәният үзәге булу сәбәпле, халыкның күпчелек өлеше шунда яши. Таулы җирләр өлеше исә ән-Нәкаб сөзәк тавын, ал-Җәлил (Галилео), Наблус (Самариа) һам әл-Хәлил (һеброн) таулары чылбырын тәшкил ите. Теньякка урнашкан әл-Жармак (Мерон) тавы исә Палестинадагы ин биек тау (1207м.) булып санала. Борынгы гасырлардан алып, Палестина крестьяннары бу биеклекләрдә яшәгәннәр, хайван асраганнар, иген икканнар, яшелчә, җиләк-җимеш үстергәннәр. Палестинаның өченче регионы булган Иордан тигезлеге исә Иордан елгасы Үле диңгезга коя торган җирдә урнашкан. Ул деньядагы ин түбән җир исәпләнә (дингез тигезлегеннән 400 м.

түбәнлекто). Мондагы кызу һава халыкка хермо, банан һәм төрле төр яшелчәләр үстерергә мөмкинчелек бирә.

**Палестинанын исламдагы урыны:**

Палестина жиренең мөселманнар өчен әһәмияте бик зур. Аллаһе Тәгалә үзенең китабы Корьанда бу жирне мөкаддос (**изге- Э.Ә.**) һәм бәрәкәтле җир дип атаган[3]:

"Эй, минем кавемем, Аллаһ сезгә язган мөкаддәс (изге-Э.Ә.) жирга керегез, югалтуларга дучар булмау өчен андагы хакимнәрдән куркып кире чигенмәгез, югыйсә Аллаһ сезгә язган җиңүдән һәм аның сезгә рәхмәтеннән мәхрүм калырсыз"[4] .

"*Дан булсын Аллаһка, кем үзенең колын* (Мөхәммәд салал- лаһу әләйһи вә салламне Э.Ә.) *төнен сәяхәт иттерде әл- мәсҗит әл- Хәрамнан әл- мәсҗит әл-Әкъсага* (**бу жирнен Э.Ә.**) *тирәсен без бәрәкәтле иттек - кайбер билгеләребезне ана күрсәтүгә без сәләтлебез. Ул* (**Аллаһ Э.Ә.**)- *бөтен нәрсәне ишетүче һәм күрүче бердәнбер заттыр"*[5].

"*... Һәм без Сөләйманга көчле җилне буйсындырдык, аның амере белән без бәрәкәтләгән җирдә йөрсен өчен... һәм без моның белән бәйләнештәге һәрнәрсәне алдан белдек*"[6].

Мөселманнарның беренче кыйбласы булган Әл-Әкъса мәчете дә Палестина җирендә урнашкан. Бу мәчет изгелек буенча ислам мәчетләре арасында өченче урында тора, шуңа да анда укылган бер намаз башка гади мәчетләрдә укылган 500 намазга тиңләшә. Мөхәммәд салаллаһу әләйһи вә сәллам әйтүенчә: "Өч мәчеткә генә сәяхәт кылына: Харам мәчете, минем мәчет (Мәдинәдә урнашкан- Э.Ә.) һәм әл-Әкъса мәчете"[7]. Икенче бер хәдистә Салаллаһу әләйһи вә саллам болай ди: "Харам мәчетендәге бер намаз ун мен намазга тин, минем мәчетемдәге бер намаз мен намазга тиң, Бәйтүл Мәкъдистәге (әл-Әкъса-Э.Ә.) бер намаз биш йөз намазга тиңләшә"[8].

Палестина расүлләр һәм нәбиләр (аларга сәламнәребез булсын) жире булып исәпләнә. Коръәндә әйтелгәнчә, бу жирдә Ибраһим, Лут, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб, Йосыф, Давыд,

Солайман, Салих, Зәкәрия, Яхья, Гыйсә (аларга сәламнәр булсын) пәйгамбәрләр яшәгән. Шулай ук Мөхәммәд салаллаһу әләйһи вә сәллам дә бу изге жирне зиярат кылган. Палестинада Коръәндә телгә алынмаган башка Бану Исраил пәйгамбәрләре дә мәгълүм, шуларның берсеннән булган Юша е пәйгамбәрнең исеме (ана сәламнәребез булсын) сахих хадиста яшове телгә алынган.

Палестина — Исра’ (тенге сәяхәт-Э.Ә.) жире, Аллаһе Тәгалә Мөхәммәд салаллаһу әләйһи вә сәлламне төнен Харам мәчетеннән Әкъса мәчетенә китертә, Нәбиебез салаллаһу аләйһи вә сәллам шушы мәчеттөн күккә Мигъраж (күккә күтәрелү-Э.Ә.) кыла. Аллаһе Тәгалә бу җирне олылап, моңарчы гомер итеп киткән бөтен пәйгамбәрләрне шушы мәчеттә бергә жыя, бу пәйгамбәрләр Мөхәммәд саллаллаһу әләйһи вә сәллам имамлыгында бергәләп намаз укыйлар. Бу вакыйга бөтен нәбиләрнең дә **тәүхид** (Аллаһның берлеге-Э.Ә.) идеясе белән килүенә, бу төүхид идеясенең мирас булып бер нәбидән икенчесенә күчеп, Мөхәммәд салаллаһу әләйһи вә сәлламгә килеп җитүе һәм бөтен нәбиләрнең дә (аларга сәламнәр булсын) ислам динен пропагандалауларына дәлил булып тора.

Сахих хәдистә әл-Әкъса мәчете мәхшәр һәм мәншәр (кабердән кубарылу һәм бергә җыелу көне) жире дип телгә алынган.[9] Икенче бер сахих хәдистә исә Биләд әш-Шәм (Палестина аның бер өлеше) турында "михнәт һәм фетно чорында исламны саклаучы үзәк булып калачак" , — дип әйтеле[10].

Палестинада Аллаһ ризалыгы өчен мөҗәһид һам мурабит булып калучылар турында исә әт-Табарани риваять иткән хәдистә болай диелә: "Әш-Шәм халкы — хатыннары, балалары һәм коллар — барысы да Аллаһ юлындагы межәһидләр. Алардан кем дә булса шәһәр яисә крепость алса да межәһид санала"[11]. Әл-имам Әхмәд буенча риваять кылынган хәдистә әйтелгәнчә: "Кыямәт көненә кадәр дөрес, хак юлда булган секта Шәмдә, бигрәк тә Бәйт әл-Мәкъдис һәм аның тирәсендә яши”[12].

алынган Югарыда телгә шушы хакыйкатьләр белән танышып чыккач, моселманнарның күңелләре вә йөрәкләре бу бәрәкәтле вә изге җир белән аерылгысыз бәйләнгән булуы һәм анын очен хәтта җаннарын да кызганмаулары бездә бернинди дә гаҗәпләнү хисе уята алмый.

**Палестинага тарихи күзлектән караш:**

сандагы 13 Археологик тикшеренүлөр раслаганча, Палестина жирендә Борынгы Таш гасырлардан (б.з. кадәр 50000-14000) бирле кешеләр яшәгән. Урта Таш Гасыр чорында бу җирдә Натуфайн цивилизациясе булуы мәгълум. Б.э. кадар 2500 нче елларда Палестина җиренә Гарәп ярымутравыннан куп Кәнгәнлеләр күчеп килеп, бу җирнең төп халкына әйләнәләр. Алар тарафыннан Палестинада ике йөзләп авыл һәм шәһәрләр төзелә. Мәсәлән: Бәйсан (Беит Шиан), Әскалән (Ашкелон), "Экъка (Акра), Хайфа, Әл-Халил (Хеврон), Әсдүд, Бир ал-Саба (Беершеба) һәм Бәйт әл-Ләһм (Бифлеем) — әнә шулардан.[13] Тарихи тикшеренүләр күрсәткәнчә, хәзерге көндәге Палестина халкы, бигрәк тә авылларда яшәүчеләрнең нөселе Көнган, Аморитлар, Филистин (Флитстимлян), шулай ук исламга кадәр һәм аннан сон бу җирләргә килеп урнашкан гарәп кабиләләренә барып тоташа. Җыеп әйткәндә, алар инде унөч гасыр дәвамында шәхси һәм җәмгыять тормышында үз теләкләре белән ислам законнарына буйсынып яшиләр; аларны ислам дине һәм гарәп теле бер туганнар итеп бергә берләштерә.

Бу бәрәкәтле һәм изге Палестина җиренә тәухид нурын алып килүче шәхес булып Ибраһим пәйгамбәр (ана сәламнәребез булсын) исәпләнә (якынча б.э.кадәр 1900 нче елларда). Ул Кудсның (Иерусалем-Э.Ә.) шул чордагы хакиме Мәлки Садыйкъ белән якын мөгаләмәдә булып, бу хакимнең үзенең дә иманлы кеше булганлыгы мәгълүм. Пәйгамбәрләр атасы булган Ибраһим әләйһи әс-сәлам Палестина халкы тарафыннан бик җылы каршы алына һәм алга таба шушы җирдә яшәп, иркен рәвештә үзенең тәүхид нурын тарата; шушы җирдә вафат булып, ул җирләнгән шәһәр алга таба аның исеме белән Әл-Хәлил дип йөртелә башлый. Ибраһим пойгамборнең (ана селамнәребез булсын) ике улы булып, алар да этиләре юлын дәвам итәләр: Исмәгыйль

әләйһи әс-сәлам Мәккәдә, ә Исхак һәм аның улы Ягъкуб әләйһимә әс-сәламнәр исә Палестинада иман нурын пропагандалыйлар. Ягъкуб пәйгамбәрнең Бәнү Исраил ( "Исраил балалары", а Исраил исеме иса Ягъкуб пайгамбарнен ләкабе булып тора) исеме белән танылган унике улы Мисырга күчеп китә һәм бу нәсел берничә гасырлар буена Фиргавеннор тарафыннан газап чигеп яши. Б.э. кадәр 13 нче гасырда Аллаһе Тәгалә бу нәселдән булган Мусаны пәйгамбәр итеп сайлый, Фиргавенне һәм аның армиясен һәлак итеп, Исраил балалары населен коллыктан коткара. Ләкин инде бу чорда Исраил балалары куркак һәм мескен холыклыга әйләнгән булалар, үзләренең борынгы җирләре Байт әл-Мәкъдис һәм Палестинага керүдән баш тарталар һәм Муса әләйһи әс-сәламгә: "Әй Муса, андагы халык ул җирдән чыгып китми торып без анда мәңге кермәячәкбез. Син һәм Раббын анда барып икегез алар белән сугышыгыз, без монда кетеп утырабыз[14], — диләр.

Озакламый Муса әләйһи әс-сәлам вафат булып, аның Палестинага керү хыялы тормышка аша алмый кала. Бәнү Исраил халкы исә, кырык ел буена Синай сахрасында адашып йөреп, кыю яна буын белән тулылана. Ахыр чиктә Юшәә бин Нүн исемле яна пәйгамбәр (әләйһи әс-сәлам) җитәкчелегендә б.э. кадәр 1190 нчы елларда, Иордан елгасын кичеп чыгып, Палестинаның теньяк- көнчыгыш өлешенә урнашалар. Шулай да сонрак Исраил балалары арасында хаос, аңлашылмаучылыклар,- әхлакый һәм дини йомшаклыклар һәм башка төрле бозыклыклар кин тарала. Шул рәвешле 150 ел буена фәсәд эчендә яшәгәч, ниһаять, тәхетка Тапут (Саул) исемле көчле вә кодрәтле патша килә һәм халыкны бергә туплап, дошманнарны җиңүгә ирешә.

Б.э. кадер 1004 нче елда Дауд әләйһи әс-сәламнең Талуттан сон властька килүе белән бу мөбәрәк җирдә тәүхид нурынын яна этабы башлана. Ул, кәферләрне җиңүгә ирешеп, берничә ел эчендә Палестинаның яр буйларыннан кала бөтен өлешен дә дип әйтерлек үз контроле астына ала. Б.э. кадәр 995 нче елда исә Иерусалем шәһәре бу патшалыкның башкаласына әверелә. Дауд пейгамбернен вафатыннан сон Палестина белен анын улы Сөләйман әләйһи әс-сәлам идарә итә. Аллаһе Тәгалә Сөләйман пайгамборго моңарчы бер җан иясенә дә бирелмәгән кодрәт бирә,

мәсәлән, изге китап Коръәндә, хәтта женнәр һәм җилнең де Сөләйман пәйгамбәргә буйсынуы телгә алына. Ул идарә иткән чорда (б.э.кадор 963-923 нче еллар) Палестинада күп яна шәһәрләр төзелә, халыкның тормышы һәм көнкүреше гаҗәеп дәрәҗәдә яхшыра. Хакыйкатьго, Дауд һом Сөләйман пәйгамбәрләр иман һәм тәүхид байрагы астында идарә иткән сиксән еллык период исламга кадәрге Палестина тарихының "Алтын чоры булып исәпләнә.

Сөләйман пайгамбәр үлү белән бу патшалык бер-берсенә Дошманлык саклаучы ике мәмләкәткә бүленә. Беренчесе — "Израил мәмләкәте", Палестинанын теньягында б.э. кадәр 923 нче елда төзелә. Фәсәд, коррупция, бозыклык кебек сыйфатларны уз эченә җыйган бу хакимлеккә "Энциклопедия Британниа", "Койрыклы дәүләт" дигән мыскыллы исем биргән. Дәүләт б.э. кадәр 721 нче елда шул чордагы иң көчлеләрдән саналган Ассирия цивилизациясе, төбәп әйткәндә, патша Саргон 2 нче тарафыннан җимерелә. Нәтиҗәдә, Израил халкы төньяк Сирия, Гыйрак һом Фарсы якларына күчеп китәргә мәҗбүр булып, алар урынына бу җирләргә Арамиеннан берничә группа халык китерела. Шушы вакыйгалардан соң бу дәүләт яшәгән территориядә Исраил балаларыннан бернинди дә эз калмый.

"Яһуде" (Жоудаһ) исемле икенче дәүләт исә б.э. кадер 923- 586 нчы еллар аралыгында башкала булган Иерусалемнан торып идара ита. Ләкин аның бик зәгыйфь булуы сәбәпле, ил белән күп очракта басып алучылар хакимлек итә. Мәсәлән, б.э. кадәрге 10 нчы гасыр ахырында Мисыр фиргавене Шешоунг башкаланы басып ала. Ә б.э. кадәр 849-842 нче елларда яһуди патша Яхурам вакытында Фаластыйнлылар тарафыннан басып алына, шулай ук ассирианнарга жизья (ясак) түли. Соңында б.э. кадәр 586 нчы елда Вавилоннарның Нибукаднезар (Навуходоносор) патшасы тарафыннан тулысынча басып алына, Иерусалем, гыйбадәт-ханәләр җимерелә, 40 мен яһүд кол итеп бу җирләрдән алып кителә. Шулай итеп, бу мәмләкәт тә юкка чыга... Борынгы яһүд кульязмалары Тәүратта бу газапларның һәм түбәнсетелүләрнен төп сәбәбе итеп яһүдләрнең кылган гөнаһлары күрсәтелә. Анда бер нәбиләре Әшгияһ (Исайи) тарафыннан әйтелгән мондый сүзләр язылган:

Легънет яусын гөнаһлы өммәткә,
Куп начарлык эшләгән халыкка,
Явызлык эшләүчеләр нәселенә,
Фәсәд кылучылар балаларына,
Алар Аллаһ юлын ташладылар,
Исраил Аллаһын ачуландырдылар,
Хак диннән борылып киттеләр.

(Исанах Китабы, 1.4)

Тәүратның икенче бер урынында исә болай әйтелә:

Җир үзендә яшәүчеләр тарафыннан пычранды
(пакълеген югалтты),

Чөнки алар Аллаһ законнарын үтәмәделәр,
Аллаһ әмерләрен үзгәрттеләр,
Мәңгелек килешүне боздылар.

(Исанах Китабы, 24:4,5)

Гомумен алганда, Исраил балаларының Палестина белән хакимлек итүләре бары тик дүрт гасыр дәвамында гына була, монда шулай ук аларның тулаем Палестина жире белән бөтен вакытта да идарә итә алмауларын да өстәргә кирәк. Мәмләкәт куп очракта загыйфь булып, үзеннән көчлерәк булган күрше дәүләтләр гегемониясе астында яши. Шунысын да әйтергә кирәк, Палестинаның төп халкы Кәнгәнлеләр һәм башка кабиләләр бу җирдә яшәүләрен һәрвакытта да дәвам итәләр, авыр чорларда да бу җирдән күчеп китмиләр.

Вакыт узу белән Фарсы императоры Курыш (Кир) яһудлорго Палестинага әйләнеп кайтырга рөхсәт биро, шулай да аларның бик азы гына монда кире кайта, алары да Палестиналылар белән бергә гомер итәләр. Билгеле булганча, Иерусалем регионы б.э. кадәрге 539-332 нче еллар аралыгында Фарсы дәүләте астында үз-идарә формасында яши, ә б.э. кадәрге 332-63 еллар аралыгында исә Греклар тарафыннан идарә ителә. Б.э. кадәр 164 нче елдан башлап, яһүдләр шулай да берничә тапкыр кечкенә территориядә булса да үзләренең шәхси дәүләтләрен булдыруга ирешәләр, ләкин шул заманның иң зур көчләреннән булган Птолемий, Сасанид һәм Романнарның

(Римлылар) Палестина жире өчен көрәш алып барулары нәтиҗәсендә гел унышсызлыкка очрыйлар. Романлыларнын б.э. кадәр 63 нче елда бөтен Палестина жирен басып алулары нәтиҗәсендә, яһүдләр Иерусалемдагы үз-идарәләрен бөтенләй югалталар. Безнен эраның 66-70 нче елларында яһудләр басып алучыларга каршы баш күтәреп карасалар да, Роман гаскәре башлыгы Титус (Тит) аларны рахимсез бастыра, храмнарын җимерә. Яһүдләр безнең эранын 132-135 нче елларында тагын бер һәм соңгы тапкыр баш күтәрәләр, нәтиҗәдә Сефруз җитәкчелегендәге Роман армиясе аларны тәмам тар-мар итеп, Иерусалемны җимерә. Роман императоры Адриан Иерусалем харәбәләре өстендә яна шәһәр салдырып, ана үз исемен бирә — шәһәр Илия Капитолина дип атала. Алдагы ике йөз ел буена яһүдларга Иерусалем территориясенә керү тыела[15]. Яһүдләр аннан сонгы 18 гасыр буена Палестина җирендә бик аз санда яшиләр. Егерменче гасырда Израил дәүләте төзелгәнче илнең төп асыл халкын хаклы рәвештә Кәнгәнлеләр һәм башка гарәп кабиләләре тәшкил итә, алар хәзерге көнгә кадәр илнең тулы хокукка ия булырга хаклы бердәнбер гражданнары булып калалар.

**Палестина ислам чорында:**

Палестина жирендә урнашкан Әл-Әкъса мәчете месел- маннар өчен исламның беренче көннәреннән үк, аерым әһәмиятле урын алып тора. Исра могҗизасы вакытында Мөхәммәд салаллаһу әләйһи вә сәллам Хәрам мәчетеннән Әкъса мәчетенә сәяхәт итә. Әкъса мәчете шулай ук мөселманнарның йөзләрен тебеп намаз укый торган беренче кыйблалары була. Гомумон алганда, Биләд әш-Шәмне исламга ачу (Палестина исә аның бер өлеше булып тора) Мөхәммәд салаллаһу әләйһи вә сәллам исән вакытта ук башлана: Фатхе Хәйбәр 7 нче елда (һижри), Муәттә сугышы 8 нче елда (һижри) һәм Тәбүк сугышы 9 нчы елда (һижри) урын ала.

Палестинаның үзен ачу мәсьәләсенә килгәндә исә, аны ачуга бәйле сугышларның иң көчлесе Халид ибн Вәлид җитәкчелегендәге Әҗнәдин сугышы була (13 нче ел һижри; 30 нчы июль, 634 нче ел миләди). Бәйт Җәбраин янында булган бу

сугышта оч йөз меңләп румлы солдатлар үлә. Шулай ук 635 нче елның 23 нче январенда Иордан елгасының көнбатышында булып узган Бисән сугышы да көчлеләрдән була. Ләкин Палестина жиренең киләчәген хәл иткән сугыш – 636 нчы елның 12 нче августында (һижри 15 нче елның 5 нче рәжәбе) Иорданиянен теньягында урын алган Ярмүк сугышы. Әбү Убәйдә һәм Халид бин Вәлид җитәкчелегендәге мөселманнар армиясе 36 мең булып, каршы яктагы румлылар армиясенең саны 200 меңгә җитә. Биләд әш-Шәмне ачуда топ урын алып торган бу сугышта Румлылар зур югалтуга дучар булалар: кайбер тарихчылар язулары буенча, бу сугышта аларның 130 мең солдатлары үтерелә. Мөселманнарның хәлифәсе Гомәр ибн әл- Хәттаб (Аллаһ аннан разый булсын) Бәйт әл-Мәкъдиснен ачкычларын алырга үзе килә. Мөхәммәд салаллаһу әләйһи вә сәлламнең мөәзине Биләл ибн Рубах, нәби вафатыннан сон азан кычкырудан тыелган булып та, Бәйт әл-Мәкъдистә беренче азанны үзе кычкыра.[16] Холифе Гомер Кудс (Иерусалем-Э.Ә.) әһелләре белән ике арада договор яза. "Гомәр гарантиясе"[17] дип аталган бу шартнамә болай башланып китә:

*"Бисмилләһи әр-рахмән әр-рахим Бу шартнамо Мөэминнәр Әмире Габдуллаһ Гомердән Илия әһелләренә иминлек вәгъдә итә, үзләренә, малларына һәм гыйбадәт урыннарына иминлеккә гарантия бирә..."*

Дөньякүләм дини көчләүләр киң урын алган чорда язылган бу договор исламдагы башка дин әһелләренә карата бирелгән дин тоту ирегеn һәм мөселманнар тарафыннан аларга карата кылынган гаделлекне раслаучы бер дәлил булып тора.

Вд Идарә эшләре буенча бүленеш ягына игътибар итсәк, Биләд әш-Шәм Холофа ор-Рашидин чорында (Мөхәммәд пәйгамбәр салаллаһу әләйһи сәллам вафатыннан соң сайланган Әбу Бәкер чорын, икенче халифә Гомар ибн ал- Хаттаб, аннан соңгы хәлифә Госман һәм дүртенче хәлифә Гали- Аллаһ Тәгаләә алардан разый булсын идарә иткән чор ислам тарихында "Хөләфә әр-Рашидин" чоры дип йөртелә; һижри 11- 41 нче еллар аралыгы-Э.Ә.) дүрт жүндкә бүленгән булып, Палестина шуларның берсен тәшкил итә. Шул рәвешле,

Палестина ислам дәүләтенең бер аерылгысыз өлешенә әверелә, ислам цивилизациясенең сәяси һәм мәдәни үсешендә актив катнаша. Ислам тарихы дәвамында хакимият берничә тапкыр үзгәрсә дә, Палестина гарәпләре һәм мөселманнары һәрвакытта да ислам дәүләтенә вә шәригать законнарына тугърылыклы булып калалар.

Хөләфа әр-Рашидин чорыннан сон ислам дәүләте хакимиятенә Үмәййәләр династиясе (миләди: 661-750, һижри: 41-132 нче еллар аралыгы) килә һәм ул үз чиратында Аббаслылар нәселе белән алышына. Аббаслылар идарәләренең беренче өлешендә (миләди 750-861 нче еллар) бетен ил белән турыдан-туры идарә итсәләр дә, ул чорда ислам дәүләте территориясе бик зураю сәбәпле, акрынлап үзәкләштерелгән идарә йомшаклана бара, нәтиҗәдә җирле вилаятьләр үсеп чыга. Палестина 878-905 нче еллар (һижри: 264-292 ) аралыгында Мисырда урын алган Тулунлылар гаиләсе виләятенә керсә, 935- 969 нчы еллар (һижри: 323-358 нче еллар) аралыгында Әл- Әхшидиюн гаиләсе виләятенә карый. Ләкин бу урында шунысын әйтеп үтәргә кирәк: Тулунлылар һәм Әл-Әхшидлеләр гаиләләре икесе дә Аббаслылар гаиләсенен авторитетын танып, анын исеме астында идарә итәләр, үзләрен беркайчан да ислам өммәтеннән аерылган яисә мөстәкыйль дип санамыйлар.

Һижри 358 нче елдан башлап, Палестина җире Исмәгыйлия мәзхәбеннән (шига мәзхәбенең бер тармагы-Э.Ә.) булган Фатыймалылар виләятенә керә. Ләкин җирле халыкның баш күтәрүләре һәм каршылыклар нәтиҗәсендә Фатыймалылар Палестина белән идарә итүне Сөнни Сәлҗүклеләргә калдырырга мәҗбүр булалар. Шулай итеп, бу җир белән һижри 464 нче елга (миләди 1071 нче ел) кадәр Сәлҗүклеләр гаиләсе идарә итә. Ләкин бу вакытта Сәлҗүклеләрнең үз гаиләләре эчендә һәм шулай ук бу гаилә белән Фатыймалылар арасындагы узара низаглар урын ала. Шуңа өстәп, Биләд эш-Шәмгә Тәречеләр дә битараф калмый, бу территория аларның төп максатларына әверелә. Фатыймалылар Тәре йөртүчеләргә хат язып, аларны Сәлжүкләргә каршы бергәләп сугышырга чакыралар; жиңгән очракта Палестинаны Фатыймалылар үзләренә калдырып, Биләд эш-Шәмнен калган өлешен Төречеләргә вәгъдә итәләр.[18]

Әлбәттә, бу хезмәттә Тәре йөртүчеләр белән булган сугышларга тәфсилләп тукталып тору безнен бурычыбыз түгел.[19] Ләкин шунысын әйтергә кирәк: Тәречеләр 1099 нчы елда (һижри 493), 70 мен мөселманның канынннан диңгез ясап, Кудска керүгә ирешәләр.

Мөселман өммәте, үз эчләрендә булган төрле низаглар, бәрелешләр һәм сәяси конфликтларга карамастан, гыйлемле һәм цивилизацияле булу өлкәсендә бу Тәре йөртүче Европалылардан күпкә өстенрәк булган. Тиз арада халык арасыннан мөҗәһид геройлар үсеп чыга. Алар арасыннан иң күренеклеләре итеп эл- Бәрсәкый (һижри 508-520) Гыймад әд-Дин Зәнки (һижри 521-540 нчы еллар аралыгында), анын улы Нур әд-Дин Мәхмүд Зәнки (һижри 541-569 нчы елларда) исемнәрен атап булыр иде. Сонгысы исә мөселман командиры үрнәгенә әверелә, ислам нигезләренә таянып җирләрен азат итәргә чакыра; бераздан Мисырны Ү3 хакимлеге астына алып, Фатыймалылар хакимиятенең яшәүдән туктавына сәбәпче була. Иллеләп шәһәр һәм крепостьны Тәречеләр кулыннан алып, Мисыр һәм Шәмне тулысынча дип әйтерлек азат итеп вафат була.

Нур әд-Диннән соң җиһад байрагын Салах әд-Дин әл- Әййуби (һижри 569-589 нчы елларда) үз кулына алып, Шәм һәм Мисыр җирләренә берләшү алып килә. Аерым алганда, 1187 нче елның 4 нче июлендә (һижри 583 нче елның 24 нче рабигул ахыр ае) булган Хәтыйн сугышында Тәречеләрне тәмам тар-мар итеп, 88 ел буе Салыйбиләр (Тәре йөртүчеләр) кулы астында булган Бәйт әл-Мәкъдис, ягъни Иерусалемны азат итә.

Әййүбидләрдән сон идарәгә 1250 нче елда Мемлуклар гаиләсе килә. Аларның өлешенә монгол яуларына каршы тору насыйп була. 1260 нчы елның 6 нчы сентябренда ике арада булган Жалут сугышында мөселманнар дошманнарын жинүгә ирешә. Шуннан соң Мәмлүкләр Палестина һәм гомумән Биләд әш- Шәмнең һаман да Салыйбиләр кулы астында калган кечкенә өлешләрен дә азат итеп бетерәләр.

Мәмлүкләр гаиләсе зәгыйфьләнгәч, аларны 1516 нчы елда Госманлылар алыштыра. Шул вакыттан башлап 1918 нче елга

кадар Палестина Госманлы солтанлыгынын бер өлешен тәшкил ите.

Белгәнебезчә, Роман империясе, безнен эраның 394 нче елында икегә бүленеп, Византия империясе шуның көнчыгыш өлешен тәшкил иткән була. Палестина исә исламга ачылганчы шушы империя астында була. Алда инде язып үтелгәнчә, Палестина исламга Хәлифә Гомәр (Аллаһ аннан разый булсын) вакытында 636 нчы елда (һижри 15 нче ел) ачыла. Шул вакыттан алып, Палестина жире мөселман өммәтенең аерылгысыз өлешенә әверелә, халкы массакүләм рәвештә ислам диненә керә, Палестинада инде исламга кадәр үк кулланылган гарәп теле ислам теленә әверелә һәм бу мөбәрәк җир, хаклы рәвештә, ислам цивилизациясенең бер кисәген тәшкил итә башлый.

Тәречеләр белән барган сугышлар чоры Палестина халкының һәм жиренең тоткан кыйбласына артык зур тәэсир ясый алмый. Тәречеләр Палестина жире белән башлыча бары тик 88 ел буе гына идарә итә алалар, ләкин шушы кыска гына чор эчендә дә, җирле мөселманнарның һөҗүмнәренә еш дучар булып, бу җиргә үз законнарын урнаштырудан бигрәк, үзләрен саклау һәм еш кабатланган һөжүмнәргә каршы торырга тырышу белән мәшгуль булалар.

Дәвамында Палестина жирендә 12 гасыр буе дәвам иткән ислам идарәсе, 1917 нче елга кадәр дәвам итеп, бу җирдә кешелек тарихы булып үткән башка идарәләр белән чагыштырганда ин озын хакимлек чоры исәпләнә. Шушы озын 12 гасыр буена илнең халкы мөселман була, бөтен Палестина жире ислам кануннары буенча гомер итә, андагы ислам хакимияте илнең башка диндәге гражданнарына дин тоту иреге биру һәм гаделлек кылу буенча идеаль мисал булып тора. Палестина халкы 12 гасыр буена бу изге җирнең иминлеген саклый, ана хезмәт итә.

ныгып Ислам диненен Палестина жирендә урнашуы Мөхәммәд салаллаһу әләйһи вә сәлламнең кайбер сахәбәләре тырышлыкларының нәтиҗәсе булып тора. Убәдәһ ибн әс-Самит, Шәддәд ибн Ауз, Усамоћ ибн Зайд ибн Харисаһ, Вәсиләһ ибн әл-

Эска, Файруз ад-Дәйләми, Дивйов әл-Калби, Габлерахман иби Ганам әл-Әшгари, Зү әл-Әсәбиги әт-Тәмими, Әбү Үбәй ибн Хәрам әл-Әнсари, Үнайф ибн Милләһ әл-Җүзәйми, Әбү Рувайһәһ әл-Фазги, Ауз бин әс-Самит, Мәсгүд бин Ауз, Зинбога бин Рух, Сүвэйд бин Зәйд һәм баш к а сахәбәләр (Аллаһ алардан разый булсын) бу изге җиргә күчеп килеп, кешеләргә ислам динен өйрәтәләр, яна дингә кергәннәргә исламча яшәү үрнәге булалар, шушы җирдә яшәп, шунда вафат булалар, шунда күмеләләр.

Сахоболордон сон Килгән Тәбигыйннәр буынынын Палестинадагы иң күренекле вәкилләреннән Раҗә ибн Хәйваһ әл- Кинди исемен аерып атап булыр иде. Ул, Бисан шәһәреннән булып, үзенең Үмәййәһ хәлифе Сөләйман ибн Габделмәликкә хәлифәлекне Гомәр ибн Габделгазизгә тапшырырга киңәш итүе белән тарихка кереп калган. Палестина жиреннән булган Убәдәһ ибн Нусаи әл-Кинди, Раух ибн Зинбәләр дә иң күренекле табигыйннәрдән саналалар. Мәлик ибн Динар, Әл-Әузаги, Һәни иби Калсум, Хамид ибн Габдуллаһ әл-Лахми, Суфьян эс Саури, Ибн Шиһәб әз-Зуһри кебек танылган шәхесләрнең исемнәре дә Палестина белән бәйле булып, алар бу җирдә бераз вакыт гомер сөргәннәр, яисә аны зиярат кылганнар.

Мөселман теологы, факиһ әл-Имам әш-Шәфигый да тумышы белән Палестинаның Газа шәһәреннән була. Бу жирдә яшәгән, яисә аны сәяхәт кылган голәмәләрдән иң күренеклеләре булып Ибраһим ибн Әдһәм, ал-Лаис иби Сагид, Әбу Бәкр Мөхәммәд әт-Тартушый, Әбү Бәкр ал-Жүрҗәни, Ибн Кудәмә әл- Мәкъдисиләр санала.

Палестиналы булган мөселман геройлары, хәрби коман- дирлар яисә галимнәрдән Фәтих эл- Әндәлүс (Әндәлүсне ачучы- Э.Э.) Муса ибн Нүсәйр әл-Ләхәми, әдәбият белгече һәм үзе яшәгән чорның иң атаклы шагыйре булган Абделхәмид ибн Яхья әл-Кәтиб, химия фәннәре буен ч а ислам тарихында беренче белгечләрдән булган Халид ибн Язид әл-Уммавиләр исемнәрен атап булыр иде. Кыскасы, Палестина жире ислам цивилизациясенең үзәген тәшкил итә, андагы галимнәр һәм

гомумән бөтен ил халкы Мөселман Өммәтенең ренессансында эффектив роль уйныйлар.[20]

**Палестина җиренә хаклары булуын яһүдләрнең үз диннәренә һәм тарихларына нигезләп "исбатлаулары":**

Яһүдләр һәм аларның иярченнәре үзләренең Палестина жирен вәхшиләрчә басып алуларын кайбер тарихи һәм дини сәбәпләр белән акларга тырышалар. Алар әйтүенчә, бу жир яһудлөргө Аллаһе Тәгалә тарафыннан вәгъдә ителгән. Шулай ук яһүдләр, ерак тарихта монда яшәүләрен һәм хакимлек итүлөрен сәбәп итеп алып, үзләрен бу жир белән тарихи һәм рухи яктан бәйләнгән дип саныйлар, бу жир алар өчен изге булып тора.

Әлбәттә, без яһүдләрнең үз диннәрен тотарга тулы хокуклы булуларын яклыйбыз, аларның дини ышануларын көчлеп үзгәртергә беркемнең дә хакы юк. Ләкин шул ук вакытта аларның да, үз дини ышануларын корал итеп алып, башкаларны ойлорсинон, илләреннән куып чыгарырга, җирләрен, байлыкларын һәм дини урыннарын конфискацияләргә хаклары юк икәнлегенә инанабыз.

Бу урында шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: мөселманнар яһүдләрнең изге Палестина жирен үзләренең дини хаклары дип санауларын кире кагалар; ченки бу жир Аллаһе Тәгалә тарафыннан Бәнү Исраилгә вәгъдә ителгән һәм бирелгән чорда алар, пәйгамбәрләре һәм руханилары белән берлектә, Тәүхид идеясен тараталар, бер Аллаһка ышаналар. Ләкин вакыт үтү белән яһүдләр, кайбер пәйгамбәрләрне үтерүләре, Аллаһтан иңгән китапларны үзгәртүләре, төрле бозыклыкларга өндәүләре һәм шушы бозык эшләрне үзләренең диннәре итеп атаулары сәбәпле, тәүхид, ягъни пәйгамбәрләренә иңгән хак диннән читләшәләр; ахыр чиктә, юлдан язып, бу изге җиргә булган хакларын да югалталар... Яһүдләр баш тарткан тәухид, ягъни бер Аллаһка ышану идеясен күтәргән хак динне алга таба мөселманнар дәвам итеп алып китәләр. Мөселманнар үзләрен тәүхид идеясенең тулы хокуклы бердәнбер варислары дип саныйлар, чөнки ислам дине — Ибраһим, Исхак, Ягъкуб, Исмәгыйль, Муса, Дауд, Сөләймән, Гыйса (аларга соламнәребез

булсын) пәйгамбәрләр бер Аллаһка табынырга чакырган тәухид диненен хаклы дәвамы. Әлбәттә, диннәрен үзләренә яраклаш- тырып үзгәртеп бетергән кавемнәр белән чагыштырганда, бары тик ислам динен тотучылар гына тәүхид мирасының бердәнбер хаклы варислары була ала. Укучы шунысын дөрес аңларга тиеш: проблема монда милләт, насел яисә кавем белен бәйләнмәгән, ә дини принципларга таяну өлкәсенә карый. Шуна да без — мөселманнар — бөтен пәйгамбәрләр тарихын үз тарихыбыз итеп кабул итәбез, аларның тәҗрибәләрен үзебезнеке итеп саныйбыз, аларның рухи байлыгы — безнеке дә. Аллаһе Тәгаләнең Коръәндә китергән аятьләре дә шуның ачык мисалы булып тора:

"*Ибраһим яһуд тә, христиан да түгел иде, ләкин хак* мөслим — *Бер Аллаһка ышанучы иде, ширек китерүчеләрдән тугел иде. Ибраһимга иң якын вәлиләр — ана ияручеләр һәм менә бу нәби, шулай ук иман китерүчеләр булды. Һәм Аллаһ иман иялоренен валиедер (яклаучы, саклаучысы- Э.Ә.)*"[21]

"*Һәм Ибраһим улларына васыять кылды, шулай ук Ягъкуб та: Әй, улларым! Аллаһ сезнең өчен иман, Бер Аллаһка ышану динен сайлады.........*[22]"

"*Исена ал, Ибраһим Раббысы тарафыннан кайбер әмерлор белән сыналып, аны уңышлы башкарып чыккач, Ул (Аллаһ) әйтте: мин сине бөтен кешеләргә имам (дини җитәкче-Э.Ә.) итәм. Ул (Ибраһим) әйтте: Һәм минем нәселемнән дә! Әйтте (Аллаһ): ләкин минем вәгъдәм залимнарны читләтеп үтә".*[23]

Аятьләрдән күренгәнчә, беренчедән, сүз Аллаһ индергән хак юлны саклау турында барган очракта, Аллаһе Тәгалә Ибраһим пәйгамбәргә аның нәселеннән булган залимнар һәм бозыклык юлындагыларның имамлыктан, ягъни лидерлык һәм әйдәп бару роленнән мәңгелеккә мәхрүм булачакларын хәбәр итә. Икенчедән, сүз бары тик нәсел дәвамы турында гына барган очракта да, яһүдләрнең үзләрен Ибраһим пәйгамбәрнең бердәнбер варислары дип санаулары берничек то хакыйкатька туры килә алмый. Белгәнебезчә, Ибраһим әләйһи әс-сәламнең ике улы булып, бер улы Исхак яһүдләрнең нәсел башы булса,

анының икенче улы Исмәгыйль нәселеннән исә Аднан гарәпләре барлыкка килә, Мөхәммәд салаллаһу әләйһи вә сәлламнең нәселе булган Кураеш кабиләсе нәкъ менә шушы Аднан гарәпләреннән була да инде. Бәлки, Ибраһим әләйһи әс-сәламгә бирелгән вәгъдәдә сүз анының улы Исмәгыйль әләйһи әс-сәлам нәселе турында барадыр?!

Мәсьәләгә тарихи яктан якын килеп карыйк. Исраил балаларының Палестина жире белән идарә итүләре бары тик дүрт гасыр дәвамында гына булып, анда да Палестинанын кайбер өлешләрен генә үз эченә ала. Инде алда язып үтелгәнчә, мөселманнарның бу җирдәге идарәсе, Тәречеләр белән сугыш вакытында булган кыска гына өзеклекне исәпкә алмаганда, унике гасырга сузыла (636-1917 нче еллар аралыгы). Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: яһүдләрнең күбесе гасырлар дәвамында Палестина җиреннән читтә яшиләр, унсигез гасыр буена (135 нче елдан алып - 20 нче гасырга кадәр) Палестина белән бернинди дә бәйләнешләре булмый. Ә инде Палестинадагы топ халыкка килгәндә, алар 4500 ел буена шушында көн күрәләр, 1948 нче елда, жирләренә яһуд бандитлары күчеп килеп, аларны өйләреннән көч белән куып чыгарганчы, Палестинада яшәүләрен дәвам итәләр; шулай ук, бу җирне үзләренеке дип санаудан хәзерге көндә дә баш тартмыйлар, үз илләрендә тыныч яшәү өчен жиһад алып баралар.

Ин кызыгы, яһүдләрнең үз галимнәре әйтүенчә (мәсәлән, танылган яһүд язучысы Артур Кестлерның "Унеченче кабилә: Хазар империясе һәм анын мирасы" китабы), хәзерге көндәге яһүдлэрнен 80% ы Исраил балалары нәселеннән түгел, ә хазар нәселеннән икән, шулай булгач, аларның Палестина җиренә несеп ягыннаннан да, тарихи яктан да бернинди дә катнашлары юк. Хәзерге көндәге яһүдләрнең төп массасы булган бу хазар коньяк Россиядәге төньяк Кавказ җирендә яшәгән борынгы терки кабиләдән булып, безнең эраның сигезенче гасырында ханнары Булан җитәкчелегендә яһүд динен кабул итәләр (740 нчы ел). Ханлыклары таркалгач, Россия һәм көнчыгыш Европага таралып, хәзерге көндә "Әшкеназ"яһүдләре исеме белән аталып йөриләр.[24] Әгәр дә аларның үз тарихи җирләренә әйләнеп кайтырга хаклары бар дип саныйбыз икән,

аларнын Палестинага агылулары хакыйкатькә бөтенләй якын килми, бәлки көньяк Россиягә кайтулары дөресрәк һәм гаделрәк булыр иде.

**Яна Чор тарихында Палестина мәсьәләсенең барлыкка килу сәбәпләре:**

Алда инде әйтеп үтелгәнчә, яһүдләрнең Палестина жире белән мен сигез йөз ел буена ныклы бәйләнешләре булмый. Шушы чор буена аларның дини галимнәре дәүләтләрен һәм яшәү урыннарын югалтуларын эшләгән гөнаһлары сәбәпле булды дип аңлатып киләләр һәм яһүдләргә алар өчен атап җибәреләчәк Мәших (Мәсих, Месна) килүен көтәргә боералар. Алар әйтүенчә, бары тик шул вакытта гына яһүдләргә Мәсих җитәкчелегендә Палестинага әйләнеп кайтырга рөхсәт ителәчәк һәм алар анда үз дәүләтләрен төзүгә ирешәчәкләр.

Европада барлыкка килгән кайбер моһим үзгәрешләр, шулай да, яһүдләрнең тоткан кыйблаларына һәм уйлау рәвешләренә көчле йогынты ясый, нәтиҗәдә сионизм проекты барлыкка килә. Бу радикаль үзгәрешләр, бигрәк тә 16 нчы гасырда Европада, атап әйткәндә Британия, Америка, Нидерланд һәм Германиянең бер өлешендә барлыкка килгән протестант реформа хәрәкәте белән бәйле. Башка христиан хәрәкәтләреннән, аермалы буларак, протестантлар яһүдләрнең дини китабы булган борынгы Тәуратны укуны рөхсәт итәләр һәм анда "яһүдләр — Палестинаның төп халкы, хәзерге вакытта анда кире әйләнеп кайту өчен Мәсихнең килүен көтәләр; менә шуннан сон меньеллык бәхетле тормыш этабы башланачак дигән карашка тап булалар. Моны дин итеп кабул иткән протестантлар "яһүд булмаганнар сионизмы" дигән караш барлыкка китереп, яһудләр проектын дини яктан нигезләп үстерергә һәм якларга ярдәм итәләр.[25]

Шулай ук Европа, унтугызынчы гасырдан башлап, бик күп сәяси үзгәрешләр кичерә. 1789 нчы елдагы Француз Революциясе нәтиҗәсендә башланып киткән идеяләр алга таба чиркәү эшчәнлеген һәм динне сәясәт һәм дәүләттән аера, нәтиҗәдә хәзерге секуляр Европа дәүләтләре хасил була. Бу дәүләтләрнең

теп асыл лозунглары булып национализм һәм патриотизм идеяләре барлыкка килә.

Бу либераль җирлектә, бигрәк тә Көнбатыш Европада яшәүче яһүдләр дә "либеральләшә", аларны илнең тулы хокуклы гражданнары итеп таный башлыйлар. Моңарчы үз җәмгыятьләре эчендә бикләнеп яшәргә мәҗбүр булган еврейларга болай ирек бирелүе аларга Көнбатыш җәмгыятенең сәяси, икътисадый һәм информация өлкәләренә җиңел генә үтеп керергә бик зур мөмкинчелек бирә.

Шул ук вакытта бу национализм һәм патриотизм идеяләре Россиядә һәм Көнчыгыш Европада икенче төрле юнәлеш ала. Бу җирләрдә яшәүче яһүдләр, башка радикаль революцион хәрәкәтләргә кушылып китеп, Рәсәй патшаларының тираник һәм террористик рәвештә көч кулланып алып барган ассимиляция һәм яңартып кору (модернизация) программасына каршы чыгалар. Шушы сәбәпләр нәтиҗәсендә һәм бигрәк тә 1881 нче елда патша Александр Икенче үтерелүдә яһүдләр кулы да уйнаганлыгы ачыклангач, Россия һәм Көнчыгыш Европада "антисемитизм" исеме белән аталган яһүдләрне эзәрлекләү, алардан канлы үч алу, газаплау кампанияләре массакүләм төс ала.[26] Семит расасыннан булган яһүдләргә каршы оештырылган бу эшләр алга таба бөтен дөньяда "Яһуд проблемасы" дигән исем белән аталып йөртелүче зур проблема барлыкка китерә. Рәсәй яһүдләре бу авырлыклардан чыгу юлларын эзли башлыйлар, көнбатыш Европа һәм ике Америкага күп меңләгән сандагы яһуд эмиграцияләре башлана. Бу вакыйгалар сионист хәрәкәтенә шушы "яһуд проблемасын бары тик яһүдләр өчен Палестинада үз илләрен төзеп кенә хәл итеп булачагын пропагандаларга зур мөмкинчелек бирә. Күп Европалылар һәм Американлылар, дини сәбәпләр яисә үз җирләренә яһүдләр агылуын туктату өчен, сионистларның бу чакыруын зур симпатия белән каршы алалар.

Көнбатыш илләренең зәгыйфьләнгән Госманлы терри- ториясен узара бүлешергә ашкынулары да "яһуд программасы"на нигез салынуга сизелерлек ярдәм итә. 1905-1907 нче елларда булып узган Империалистик Лондон конференциясендә Госманлы дәүләтенә кергән Палестина жирен "буфер дәүләт"

итеп билгеләү турында сүз кузгатыла һәм бу фикер Британиянең шул чордагы Премьер Министры Кэмпбелль Ванерманга җиткерелә.

Бу идеянен топ асылы түбәндәгедән гыйбарәт була: Урта диңгезнең көнчыгышында бу регион халкы (мөселманнар) белән дошман һәм көнбатыш илләре белән союздаш булган бер милләткә "ей, ватан" төзергә.[27] Яһүдләр, әлбәттә, бу империалистик программада куллану өчен иң әйбәт корал булалар.

Палестинада "буфер дәүләт” төзү идеясенең нигезендә моселман деньясының Африка һәм Азия канатларын бер-берсеннән аерып, алар арасында алга таба берләшү мөмкинчелеген бөтенләй юкка чыгару, шул рәвешле мөселман деньясын зәгыйфь хәлдә саклауны гарантияләү идеясе ята.

Бу дошман яһүд дәүләтенең, әлбәттә, мөселман өммәтен озак вакытларга бәхәсләр һәм көрәш хәленә куеп, нәтиҗәдә аның хәрби һәм экономик яктан зәгыйфьләнеп һәм сәясәт өлкәсендә тулысынча параличланып, Көнбатышның супер көчләренә буйсынуын тәэмин итәчәге алдан ук көн кебек ачык иде. Бу яна сионист дәүләте, алга таба яшәвен дәвам итү өчен, Көнбатыш гарантиясенә мохтаж булган кебек, Көнбатыш үзе дә мөселман деньясын зәгыйфь, бүлгәләнгән хәлдә саклау өчен бу сионист программасына мохтаж иде. Шуңа күрә дә алар арасында Яһуди Сионист-Көнбатыш Тәрече берләшүе барлыкка килүе бер дә гаҗәп түгел. Бу мәңгелек һәм берләшкән союзның бер Палестинаны гына түгел, ә бөтен мөселман дөньясын, өммәт берлеген үзенә мишень итеп алган булуын мөселманнар дөрес анласыннар иде.

Көнбатыш христиан деньясы безнең эраның 11 нче гасырыннан башлап Үзеннән көчлерәк күрше мөселман дәүләтләре белән ике арадагы үзара конфликтлардан күп җәфалар күрә. Ислам тарихына күз салсак, бер мөселман дәүләте көчсезләнә башлау белән, кагыйдә буларак, икенче бер көчле ислам дәүләте барлыкка килә: Хөләфә әр-Рашидин Үмәййәһ дәүләте белән алышына, анысы да көчсезләнгәч, алмашка Аббасидлар килә, Мәмлүкләр... Шул рәвешле,

мөселманнар гасырлар буена деньядагы иң зур көч һәм иң көчле дәүләт булудан туктамыйлар. Мәмлүкләргә алмашка килгон Госманлылар исә берничә гасыр буена ислам сакчылары ролен үтиләр, көнчыгыш Европаның күп өлешен исламга ачалар, гарәп деньясын үз асларында берләштерәләр һәм берничә гасыр буена мөселман өммәтенең көчен саклыйлар. Ләкин 18 нче гасырдан сон, бигрәк тә 19 нчы һәм 20 нче гасырларда Госманлы дәүләте зәгыйфьләнә. Шул чорда прогрессив үсеш алып киткән империалистик Европа көчләре, ислам дөньясында һәрвакыттагыча көчсезләнгән Госманлыларга алмашка яна көчлерәк дәүләт барлыкка килмәсен һәм Европа үзе генә бердәнбер көчле дәүләт булып калу тәэмин ителсен өчен мөмкин булган барлык чараларны да күреп калырга тырышалар.

Мөселман өммәтен икегә аерып, очсыз-кырыйсыз кон- фликтлар белән анын ботен энергиясен сарыф итәчәк бу "буфер" сионист дәүләте оештыру идеясе нәкъ менә Европа үзенең бердәнбер Бөек Супер көч булуын тәэмин итү өчен күргән чараларның нәтиҗәсе булып тора да инде.

**Палестина мәсьәләсенен 1914 нче елга кадәрге сәяси үсеше:**

Н. Бонапартның 1798 нче елның июлендә Мисырны бик жинел генә басып ала алуы Европа көчләренә инде тәмам загыйфьләнеп, "Европаның авыру ир-аты" ("sick man of Europe") исеме белән атала башланган Госманлы дәүләтенең зур территориясен үзара бүлгәләп колониягә әйләндерергә юл ача. Наполеонның 1799 нчы елда Палестинага оештырган экспедициясе французларнын Экре капкасы янында катастрофик җиңелүләре белән тәмамланса да, бу шәхес 1799 нын 20 нче апрелендә яһүдләрне Палестина жирендә ирекле дәүләт төзергә рәсми рәвештә чакырган беренче Европалы сәяси җитәкче була.[28]

Шул чорның иң бөек державасы Британиянец Урта Көнчыгышка карата булган империалистик планында Мисыр һәм Биләд әш-Шәм төп әһәмиятле урынны алып торган булалар. Британия 1838 нче елда ук Иерусалемда консуллык ачуга ирешa ate һәм бу консуллык 1914 нче елгы сугышка кадәр Палестинадагы

яһүдләр өчен иминлек һәм ярдәм үзәге булып тора.[29] Дөрестән да, Британиянең Тышкы Эшләр министры тарафыннан консул ярдәмчесено җибәрелгән беренче күрсәтмә хатта ук бу консуллыкның яһүдләр өчен, нинди илдән килгән булуларына карамастан, иминлек сакчылары һәм ярдәмчеләре булулары таләп ителгән була. Британия 1878 нче елда Кипрны, аннан сон 1882 дә Мисырны басып алып, Урта диңгезнең көнчыгыш ярында хәрби базалар урнаштыруга ирешә, нәтиҗәдә ул Урта диңгез территориясендәге бердәнбер көчле колонизаторга әверелә. Шул ук вакытта Палестинаны да, инде алда телгә алынган сәбәпләр аркасында, күз уңыннан жиберми. Бигрәк тә Индия белән ике арадагы бейләнеш чарасы булган Суез каналын (Суэцкий канал) саклау өчен стратегик урында урнашкан булуы очен дә Британия Палестинага мохтаҗ була. Менә шуңа күрә дә Британия хөкүмәте сионист программасын, "буфер дәүләт төзү" идеясе белән тулы- ландырылган хәлендә, бик җылы каршы ала һәм аңа ярдәмен кызганмый, бу программаны алга таба үзенең империалистик, дини, мәдәни һәм сәяси максатларында бик оста эксплуатацияли.

Әлбәттә, яһүдләр һәм сионистларның изге җиргә "әйләнеп кайтырга чакырулары 19 нчы гасыр ахырына кадәр дә очраштыргалый. Бу чакыру беренче тапкыр 16-17 нче гасырларда ук, бигрәк тә Британия юристы һәм адвокаты Х.Финч үзенең 1621 нче елда язылган китабында яһүдләрне Палестинага "әйләнеп кайтырга һәм бу ил белән идарә итәргә чакыргач башланып китә. Алга таба яһүдләр һәм христианнар тарафыннан бу темага кагылышлы күп сандагы китаплар һәм чакырулар языла. Мәсәлән христиан динендәгеләрдән Жан Жак Руссо (1712-1778), Д.Пристли (1733-1804), Шафтсвейри һәм Оливант исемнәрен атап булса, яһүдләрдән Исак Ньютон (1643-1727), Саббатай Цеви (1626-1676), Жудаһ Алкали (1798-1878) һәм Музес Хесс (1812-1875) кебек күренекле шәхесләр бу теманы алга таба үстерергә үзләреннән өлеш кертәләр.[30] Ләкин шунысын да әйтергә кирәк: яһүдләрнең "әйләнеп кайту" термины әле бу чорда сәяси тос алып өлгермәгән була, бу бары тик Изге жирне зиярат кылу, ана якынрак урнашу кебек дини максатларны гына чагылдыра, шуна да Палестинада яшәгән яһүдләрнең саны чагыштырмача аз булуын дәвам итә: 1799 нчы елда Палестинада

барлыгы 5000 яһуд булса,[31] 1876 нчы елда исә монда 13 920 яһуд исәпләнә.[32]

Россиядә "яһуд проблемасы" кабыну белән, 1882 нче елдан башлап, яһүдләрнең Палестинага иммиграциясе бермә-бер арта. Шул чорда Палестина белән идарә иткән Госманлы хөкүмәте яһүдләрне Палестинага күпләп кертүдән тыю өчен чаралар кү- рергә тырыша, мәсәлән, 1887 нче елдан башлап, Сирия виләятенә караган Кудс (Иерусалем) турыдан-туры үзәк административ контроль астына куела.[33] Госманлы хөкүмәтенең бу изге жирне саклау өчен күргән чаралары эзсез югалмый: 1881-1914 нче еллар аралыгында Россия һәм Көнчыгыш Европадан киткән яһүдләр- нен саны 2 366 941 гә җитсә дә, аларның бары тик 55 мене генә (2.32%) Палестинага барып урнаша алган, калган яһүдләр исә АКШка, Көнбатыш Европа һәм Көньяк Америкага күчеп китәләр.[34]

Теодор Герцль җитәкчелегендә Бөтендөнья Сионист Организациясе (алга таба БСО дип кенә биреләчәк-Э.Ә.) оештырылу һәм аның 1897 нче елның 27-29 нчы августларда Швецарияда булып үткән Беренче Конференциясе Палестина жирендә яһүд Дәүләте төзүне саяси юнәлешкә кертеп систематик рәвештә башлап җибәрә. Герцль бу программаны тормышка ашыру өчен шул чордагы Бөек Көчләрнең, бигрәк тә Бөекбританиянең ярдәменә мохтаҗ икәнлекләрен яхшы аңлаган хәлдә, үзенең төп энергиясен шушы хезмәткә сарыф итә. Хәтта Палестина белән идарә итүче Госманлы солтаны Әбделхәмидкә (1876-1909) зур күләмдә акча бәрабәренә Палестина жирен алар- га сатарга, киләчәктә бу җирдә Госманлы хөкүмәте астында яһүд үзидарәсе оештырырга тәкъдим итә. Авыр чор кичергән Госман- лы дәүләте финанс ягыннан бу зур күләмле ришвәт акчасына мохтаж булса да, Солтан Әбделхәмид Икенче бу тәкъдимне кире кагып, яһүд программасына кискен каршы булуын дәвам итә һәм Герцльга түбәндәге сүзләрне җиткерергә боера:

" Мин ана бу мәсьәләгә башка беркайчан да кире әйләнеп кайтмаска нәсыйхәт итәм. Бу җирнең бер генә адымын сату да минем кодрәтемнән килми, чөнки ул минем шәхси милкем түгел, бу жир — минем халкымныкы. Халкым бу дәүләтне каннары бе-

лән төзеде. Корбаннар биреп гасырлар дәвамында аны сакла- ды...һәм бу җирне үзебезнең каныбыз белән соңгы минутка кадәр кемгәдер аны алу мөмкин булганчы саклрабыз.... Яһудлар мил- лионнарын үзләренә сакласыннар. Әгәр дә империя таркала икән, алар Палестинага бушка да керә алалар. Ләкин бу таркалу безнең үле гәүдәләребез аша гына булырга мөмкин. Һәм мин үзем исән чагында беркайчан да, бер нәрсә хакына да моны кабул итмәя- чәкмен". [35]

Менә шуңа күрә дә солтан Әбделхәмидне фаҗигале рәвештә хакимияттән бәреп төшерү вакыйгасында нәкъ менә яһудлорнен топ инструменталь роль уйнаулары бер дә гаҗәп түгел. Яһудлөр, "Яшь Төрекләр Оешмасы" һәм аның "Берләшү һәм Прогресс Комитеты"на күпьяклы тәэсирләре нәтиҗәсендә, ниһаять, 1909 нчы елда солтанны властьтан төшерүгә ирешәләр. Солтаннан тәхеттән баш тартуын таләп иткән рәсми делегация арасында Палестинаны яһүдләр өчен сатып алырга теләве сәбәпле Әбделхәмид тарафыннан сарайдан куып чыгарылган сионист Эммануэль Красов та булуы бу вакыйгаларның төп сәбәпләрен бик яхшы аңлата.[36] Яһүдләр 1909-1914 нче еллар аралыгында Госманлы властена килгән башка җитәкчеләргә дә көчле тәэсир ясауларын дәвам итәләр. Мисал өчен 1913 нче елда "Яшь төрекләр" кабинетының уноч министрыннан өчесе яһуд милләтеннән булуын язып үтү дә җитәр иде; иң кызыгы, империя халкының яртысыннан күбрәге гарәпләр булса да, гарәпләр бары тик бер генә министрлык урынына ирешә алганнар.[37]

Палестина халкының сионист программасына каршылык күрсәтүе бик иртә башлана. 1886 нчы елда бер төркем Палестина крестьяннары кайбер көчеп килгән яһүдләр белән бәрелешкәч, куп Палестиналылар, Госманлы хакимиятенә мөрәҗәгать итеп, яһүдләрдән янаучы басып алу куркынычының зурая баруын хәбәр итәләр. Шул чорларда актив эшчәнлек алып барган "Әл- Кармал" һәм "Фаластыйн" вакытлы матбугаты да Палестинаның киләчәгенә янаган куркынычның ни дәрәҗәдә хәтәр икәнен күрсәтү өлкәсендә эш алып бара. Күренекле мөҗәһид Рәшид Риза узенец "Әл-Монар" журналында һәм Йосыф Дия Әл-Халиди, Сөләйман Әт-Таҗи Әл-Фарукый, Исгәф Ән-Нәшашиби кебек Палестинаның күркәм ирләре дә бу каршылык күрсәтүгә

үзләреннән өлеш кертәләр. "Яшь төрекләр" алып барган "төрекләндерү сәясәте һәм аларның про-сионист политикасы Палестиналыларны Госманлы дәүләтен реформаларга чакырган "Хизб әл-ләмәркәзийяһ" һәм "Әл-Гарәбийяһ әл-Фәтәһ" кебек гарәп җәмгыятьләренә кушылып китәргә этәрә.[38]

**Палестина мәсьәләсе Беренче Бөтендөнья сугышы чорында (1914-1918):**

1914 нче елда сугыш башланып киткән чорда Палестина җирендәге яһүдләр саны мен сиксән тирәсе була. Ләкин яһүдләрнең Госманлыга каршы лагерьдагы Британия һәм аның союздашларына көчле симпатия белдерүләре сәбәпле, Гос- манлылар яһүд хәрәкәтләрен кайбер кысрыклауларга дучар итәләр. Шул сәбәпләр нәтиҗәсендә Палестинада яшәүче яһүдләр саны сизелерлек кими, сугыш беткәндә бу җирдә бары тик илле биш мен тирәсе генә яһүд кала.

Сугыш бөтен кеше, барлык партияләр өчен катастрофа булып торса да, күпләр бу форсаттан файдаланып калырга, үзләре өчен киләчәктә отышлы булачак контактлар булдырырга, яшерен килешүләр төзеп калырга тырышалар. Халыкара сионизм яһуди диаспорадан, бигрәк тә төп лидерларның Германиядә булуларыннан җәфа чиксә дә, сионист С.Вейцман, бу моменттан файдаланып, Лондонда үзенең абруен һәм позициясен ныгыта.

Британия, үз өлешендә, Биләд әш-Шәм һәм Гыйракка карата булган стратегик планын тормышка ашыру вә сугыштан җиңүче булып чыгу өчен, мәкерле уенын тагын да дәвам итә — параллель рәвештә бер-берсенә бөтенләй капма-каршы булган яшерен еч дипломатик эш алып бара:

Алардан **беренчесе** — Хиҗәз әмире Әш-Шәриф Хөсәен ибн Гали белән алып барылган "зәвыклы алыш-биреш" эше. "Хөсәен — Мак-Магон язышуы" исеме белән тарихка кереп калган бу алыш- биреш, 1915 нче елның июленнән 1916 нчы елның мартына кадәр вакыт аралыгында ике арада хат белән хәбәрләшүдән гыйбарәт булып, нәтиҗәдә түбәндәге яшерен килешү төзелә: Хөсәен Госманлыларга каршы Гәрап революциясен игълан итәчәк, икенче яктан Британия исә, Гарәпстан, Биләд әш-Шәм һәм

Гыйрактагы төп гарәп территорияләренең бәйсезлегенә гарантия бирәчәк. Гарәпләр Сугышның башында, ботен узара каршылыкларны читкә куеп, Госманлылар белән уртак дошманга каршы көрәшкән булсалар да, алга таба "Яшь төрекләр" алып барган сәясәтнең киләчәктә бу дәүләттә исламга урын юклыгын ачык күрсәтүе сәбәпле, гарәп лидерлары киләчәктә бу империянен алар өчен чит булачагын бик яхшы төшенәләр. Шуна өстәп, Госманлы тарафыннан Сириягә җибәрелгән вәли Җәмал Паша әс-Сәгыйр кайбер гарәп лидерларын хаксызга үлемгә хөкем иткәч, гарәпләрнең ачуы тагын да кабара, алар җитди рәвештә бу империядән чыгу юлларын эзли башлыйлар. Әлбәттә, әш-Шәриф Хөсәенгә Британиянен вәгъдәсендә тормау политикасы алдан ук яхшы таныш була, шуңа күрә дә ул аннан гарәп илләренең киләчәктәге чикләрен төгәл итеп ачыклавын сорый. Нәтиҗәдә 1915 нче елның 24 нче октябренда Британия мәсьәләгә кайбер ачыклыклар кертә: Мәрсин, Адана, Алеппо, Химс, Хама, Көньяк Йемен, Гольф Гарәп Әмирлеге бу киләчәктәге гарәп дәүләте составына кермәячәк, бәлки бу жирләр Британия колониясе хәлендә калачаклар. Шулай ук Британия коньяк Гыйракта үзенең махсус административ идаресен куюны таләп итә.

Әлбәттә, әш-Шәриф Хөсәен инде колониягә әйләнгән гарәп илләренә мөнәсәбәттә үзенең бернәрсә дә эшли алмаячагын яхшы аңлый, шулай да көнбатыш Алеппо, Химс һәм Хама (хәзерге Либнан) җирләрен яна Гарәп дәүләте составына кертүне соравын дәвам итә. Ахыр чиктә, ике як та бу ихтиләфләрне сугыштан соң хәл итәргә килешәләр. Шуннан соң әш-Шәриф Хөсәен Британия ягына кушылуын ачыктан-ачык рәсми рәвештә белдерә һәм 1916 нчы елның 10 нчы июнендә Атаманнарга каршы Гарәп Революциясен игълан итә. "Әл-Гарәбийяһ әл- Фәтәһ" ("Яшь гарәпләр”), “әл-Ләмәркәзийяһ" ("Децентрали- зация") һәм Биләд әш-Шәмдәге “әл-Әһд” ("Бурыч") кебек гарәпләр арасындагы популяр оешмалар да әш-Шәриф Хе- сәеннең бу адымын яклап чыгалар.

**Икенчедән**, Британия, әш-Шәриф Хөсәен белән дип- ломатик сөйләшүләр алып барган чорда, Франция белән дә (ахырдан аларга Россия дә кушыла) Гыйрак һәм Биләд әш-

Шәмнең киләчәге хакында яшерен килешүләр алып бара. Сөйләшүләрнең нәтиҗәсендә бу илләр арасында Сайкс-Пико килешүе төзелә. Килешү буенча, Британиягә хәзерге көндәге Гыйракнын барлык өлеше дә дип әйтерлек, Көнчыгыш Иордания, Палестинадагы Һәйфә биреләчәк; Либнан һәм Сирия исә Франция контроле астында калачак, стратегик әһәмияткә ия булган Палестина жире исә халыкара күзәтү астына куелачак.

**Өченчедән**, Британия, нәкъ шул вакытларда Бөтендөнья Сионист Организациясе (БСО) белән дә Палестинаның киләчәге хакында сөйләшүләр алып бара. Бу чорда сугышнең хәлиткеч минутлары булып, Британия Американың ярдәменә мохтаж була. Яһүдләр лоббиеның АКШ сәясәтендә мәһим роль уйнавын яхшы аңлаган хәлдә, Британия аларны Америка хөкүмәтен сугышка кертергә ризалату өчен куллана. Британиянең планы 1917 нче елның мартында тормышка аша. Әлбәттә, Британия инде алда тукталып үткән дини, стратегик һәм сәяси сәбәпләр, шулай ук илдәге ныклап урнашып өлгергән сионист лоббие һәм идарә кабинетының үзендә дә сионистлар булуы сәбәпле сионист программасына ярдәмен кызганмый. Илнен Премьер Министры Лорд Джорж һәм Тышкы Эшләр секретаре Бальфур сионист программасын яклаучылар булсалар, Эчке Эшләр министры Гербер Самуэль исә тумышы белән үзе яһүд милләтеннән була. Аларның тырышлыгы нәтиҗәсендә 1917 нче елның 2 нче ноябрендә Бальфур Декларациясе барлыкка килә, анда Британия яһүдләргә Палестина жирендә алар өчен Милли Ватан төзергә вәгъдә бирә... Бу вәгъдә кешелек тарихындагы иң гаҗәп, акылга сыймаслык дәрәҗәдәге гадәти булмаган вәгъдә булып тора. Британия, халыкара килешү төзү принципларын бозып, бу жирнең үз гражданнарының хокукларын, иминлекләрен, кеше буларак кыйммәтләрен һәм горурлыкларын аяк астына салып таптый, мыскыл итә. Ин шаккаткычы: Британия бу җиргә ия булмаган, ягъни әле басып алмаган килеш аны бу җиргә бөтенләй хаклары булмаганнарга бирергә вәгъдә итә. Бөтен кешелек законнарына каршы бу гаделсезлек һәм җинаять Британия «Бөекбритания намусы» хакында сөйләгән чорда, үзен кешелек принципларын яклаучы һәм саклаучы дип игълан иткән чорда нәкъ менә Британиянең үзе тарафыннан эшләнә.

Әлбәттә, "без капчыкта ятмый", башка халыкларны мыскыл иту һәм түбәнәйтү булып торган Сайкс-Рико килешүе һәм Бальфур Декларациясе озак сер булып саклана алмаган. 1917 нче елнын октябренда Россиядә Коммунистлар Партиясе жиңүгә ирешкәч, ил сугыштан чыгуын игълан итә һәм Сайкс-Рико, Бальфур Декларациясе серләрен дә бөтен дөньяга фаш итә. Бу яналык Мисыр прессасы аша гарәп илләренә дә барып ирешә.

Британиянең бу шаккаткыч хыянәте Гарап Революциясен шок хәлендә калдыра, ярсыган солдатлар Британия белән союзда сугышудан баш тарталар һәм Британия хөкүмәтеннән аңлатма таләп итәләр. Британия исә ярсыган гарөп халкын һәм лидерларын үзенең чираттагы ялганы белән тынычландырырга керешә. 1918 нче елнын январенда Британия әш-Шәриф Хөсәенне тынычландыру максаты белән Хогратны ана илче итеп жибәрә һәм яһүдләрнең Палестинага иммиграциясе бу җир кешеләренең саяси һәм икътисадый мәнфәгатьләренә бернинди дә зыян китермәячәк дип чираттагы вәгъдәсен бирә. Шушы ук елның июнендә исә Британия Сирияле жиде лидерга ике яклы вәгъдә бирә: Британия астында булган көньяк Палестина һәм коньяк Гыйрак шул җирнең халкы сайлаганнар тарафыннан идарә ителер; ә инде әлегә Госманлы астында булган теньяк Палестина, көнчыгыш Иордания, Сирия, Либнан һәм төньяк Гыйрак җирләре исә сугыштан соң мөстәкыйль дип игълан ителәчәк. Сугыш ахырында, төгәл әйткәндә 1918 нче елның 7 нче ноябренда кабул ителгән Англия-Француз декларациясе дә Госманлы астында булган гарәпләргә азатлык һәм мөстә- кыйльлек вәгъдә итә.[39]

## ИКЕНЧЕ ФАСЫЛ

### Палестина Британия оккупациясе астында (1917-1948):

Британия Палестинаның көньяк һәм үзәк өлешләрен басып алуны 1917 нче елның декабрь аенда тәмамлый, шул исәптән 9 нчы декабрьда Иерусалем да рәсми рәвештә оккупацияләнә. Британиянең хәрби командиры Лорд Алленби шушы вакыйга унае белән горур һәм тәкәббер рәвештә түбәндәге сүзләрне әйтә: "Чукындыру походлары, ниһаять, менә әле тәмамланды".[40] Бу сүзләрдән аңлашылганча, европалылар сигез йөз ел буена үзләрен мөселманнар белән чукындыру сугышлары алып баралар дип исәпләгәннәр, Палестинаны басып алу исә шул күп гасырларга сузылган сугышның ахыргы нәтиҗә ноктасы булып тора икән. Британия, үзенең басып алу политикасын дәвам итеп, 1918 нче елның сентябрь-октябрь айларында төньяк Палестина, көнчыгыш Иордания, Сирия һәм Либнанны басып ала. Шушы вакыттан башлап, Британия Палестина җирен яһүдләштерү буенча үзенең рәхимсез программасын башлап җибәрә. Франция белән ике арада булган Сайкс-Рико килешүе буенча Палестинаны халыкара ил дип игълан итү мәсьәләсенә килгәндә, Британия түбәндәгечә "судан коры чыгу" юлын эзләп таба: Британия Фәйсал ибн Шәриф Хөсәен тарафыннан Дамаскта оештырылган гарәп хөкүмәтенә булышуны туктатачак, бу нәтиҗәдә Франциягә Сирияне колониягә әйләндерергә юл ачачак. Шушы "булышу" хакына Франция Сайкс-Рико килешүеннән баш тартачак, шул рәвешле, Палестинаны халыкара ил итү темасы ябылачак, бу исә илне яһүдләштерү эшен бермә-бер җиңеләйтәчәк. Шуңа өстәп, 1922 нче елның 24 нче июлендә Милләтләр Лигасы, Британиянең көчле басымы астында, үзенең төп принципларына каршы килгән Бальфур декларациясен рәсмиләштерергә һәм Палестина жирендә Британия мандаты төзү хакында резолюция кабул итәргә мәҗбүр була. Әлбәттә, Милләтләр Лигасы мандат төшенчәсе хакында сүз йөрткәндә бу мандат астындагы халыкка ярдәм итү, аларның азатлыгын саклауны, Палестинадагы теп жирле халыкның (җирле халык ул чорда илдәге бөтен халыкның 92% ын тәшкил итә[41]) гражданлык һәм дини хокукларын яклауны һәм аларның җирле учреждениеләрен үстерүне күз алдында

тоткан була. Ләкин чынбарлыкта империалистик Британия бу хокукларны бөтенләй санга сукмый, көннән-көн үсә барган гарәп-яһуд конфликтында үзен тышкы яктан нейтраль итеп күрсәтеп Палестиналыларны алдый, гарәп лидерларын үз хокукларына "гражданлык хокукына ирешү" һәм конституция юлы белән ирешергә өнди, шул рәвешле, зур революцион шартлау булдырмау өчен "куркынычсызлык клапаны" ролен ути. Британия, ике арадагы мәсьәләләрне хәл итүне һаман суза килгән вакытта, яшерен рәвештә Палестина жирен яһудләрнең милли ватаннарына әйләндерү өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли.

1920 нче елның июнь ахырында Британия ботен Палестина жирен хәрби идарә астына куя, ләкин соңрак бу идарә Британия Югары Илчесе җитәкчелегендәге гражданлык идарәсе белән алыштырыла. Ил белән идарә итүче Илчеләр арасында беренчесе Герберт Самуэль (1920-1925) үзе үк сионист булып, анын идари варислары да сионист программасын тормышка ашыруда актив эшлиләр. Алар арасында сионист программасына иң тырышып хезмәт итүче булып Артур Вашуп санала, ул идарә иткән 1931- 1938 нче еллар аралыгында Палестинадагы сионист заговоры узенен ин куркыныч ноктасына җитә.

**Сионист программасының алга таба үсеше:**

Британиянең Палестина жире белән турыдан-туры контрольлек итүе Югары Илчеләргә чикләнмәгән хокуклар һәм абсолют власть бирә, ләкин шул ук вакытта Палестинаның үз халкын конституцион үзидарәләрен булдырудан мәхрүм итә. Шуна өстәп, илдә алып барылган про-сионист экономик сәясәт һәм "кисәкләргә бүлгәлә вә иркенләп идарә ит" политикасы нәтиҗәсендә Палестиналыларның яшәү шартлары, бигрәк тә эш табу яклары бик нык авырая, тыныч тормыш һәм хәләл юл белән ризык табудан мәхрүм булу җәмгыятьтәге бозыклыкларны бермә-бер арттыра, бу исә гаиләләрдә, кешеләр арасында төрле каршылыклар һәм аңлашылмаучылыклар туугa сәбәп була. Шул ук вакытта илдә Британия-сионист интригалары һәм керемле сатып-алу тәкъдимнәре киңкүләм тарала. Башкача яшәргә мөмкинчелеге калмастай хәлгә житеп хәерчеләнгән Палес-

тиналылар үз җирләрен яһүдләргә сатарга мәҗбүр булалар. Ләкин яһүдләрнең һәм британлыларнын чиктән тыш тырыш- лыгына карамастан, Палестина җиренә сатып алып ия булу эше бик акрын бара. 1918 нче елда Палестинада 55 мен яһуд булып, алар илдәге халык санының 8% ын тәшкил итсә, бу сан 1948 нче елда 650 меңгә җитеп, халык санының 31% ын тәшкил итә; әмма яһүдләр бу чор эчендә бөтен Палестина жиренең бары тик 6.5% ына гына ия була алалар һәм бу сатылган җирнең дә күпчелек өлешен элеккеге хөкүмәт җирләре яисә Палестиналы булмаган сирияле, либнанлы җир хуҗаларыннан сатып алынган җирләр тәшкил итә. Шуңа да карамастан, яһүдләр шушы аз гына җирдә до 291 торак пункт төзергә өлгерәләр.

Шушы кырыс сәяси һәм икътисадый шартлар өстенә, Британия Палестиналыларның корал йөртү яисә ана ия булуларына каршы кискен эмбарго чарасы куллана. Палестиналыларның порох яисә "салкын корал" булган хәнҗәр, озын пычакларга ия булулары да озак срокка төрмәгә ябылу белән тәмамлана, ә инде утлы корал ияләре исә үлем җәзасына хөкем ителәләр. Шул ук вакытта Британия авторитетлары яһүдләрнең кораллануларына күз йомалар, хәтта кайчак үзләре үк яһүдләрне яшерен рәвештә шуңа өндиләр. Британиянең Палестинадагы мандаты тәмамланган вакытта яһүдләр зур сандагы яхшы өйрәтелгән һәм югары дәрәҗәдәге дисциплиналы хәрби көчкә ия булалар. 1948 нче елгы сугышта аларның 70 меңнән артык бандиттан торган хәрби көчләре була: 64 мен — Хаганадан, 5 мен — Иргуаннан һәм 2 меңнән артык санда — Штерннан. Бу хәрби көч 1948 нче елгы Гарәп-Израил сугышында катнашкан жиде гарәп иле армиясеннән өч тапкырга көчлерәк була!

Бу чор эчендә яһүдләр Палестина жирендә социаль- экономик һәм мәгариф өлкәсенә караган шактый сандагы әһәмиятле учреждениеләр төзүгә ирешәләр. Мәсәлән, Хистадрут (Эшчеләр берләшмәсе) төзиләр, 1925 нче елда Иерусалемда Хеброу (Яһуд) университеты ачыла, ә 1929 нче елда исә Палестина жирендә көчкә һәм югары дәрәҗәгә ия булган Яһуд вәкиллеге барлыкка килә һәм ул алга таба яһүдләрнең Палестинадагы Рәсми Илчелек органына әверелә.[42] Бу

организацияләр барысы да алга таба, һичшиксез, 1948 нче елда Палестинада төзелгән Яһүд дәүләтенең ныклы фундаментын тәшкил итәләр.

**Палестина Милли хәрәкәте барлыкка килү:**

Палестина һәм башка күрше гарәп илләре Беренче Бетендонья Сугышыннан соңгы периодта загыйфьлек, йомшаклык һәм авыр сынау чорын кичерәләр. Гомумән алганда, бу чорда бөтен мөселман деньясы, колониягә әйләнеп, империалистик көчләр тарафыннан идарә ителә. Палестинаның икътисадый мөмкинчелеге һәм сәяси көче, әлбәттә, көчле халыкара яһүд лоббиена һәм дөньяның иң көчле илләре тарафыннан якланган сионист программасына каршы торын көрәшерлек дәрәҗәдә көчкө ня булмый. Шулай да Палестиналылар Британия оккупациясе астында яшәгән бу чор дәвамында үз хокукларын, азатлык даулап көрәш юлына басалар. Бу җиһад хәрәкәте һәм сәяси активлык түбәндәге таләпләр буенча эш итә:

- Гаделсез һәм золым кылучы Бальфур декларациясен гамәлдән чыгарырга
- Яһүдләрнең Палестинага иммиграциясен тиз арада туктатырга.
- Палестина жирен яһүдләргә сатуны тыярга.
- Палестина халкы ирекле рәвештә сайлап куйган Парламент тарафыннан идарә ителүче Милли Палестина хөкүмәте төзергә.
- Британия белән аның Палестинадагы гегемониясен туктату өлкәсендә сөйләшүләр алып барырга.

Палестина милли хәрәкәте менә шушы максатларга ирешү өчен көрәш нигезендә барлыкка килә һәм 1919 нчы елның 27 нче Январь — 10 нчы февраль аралыгында Иерусалемда Беренче Гарап Палестина конференциясен оештыруга ireша. Делегатлар Европа көчләренең колониягә әйләндерү өчен үзләренә отышлы итеп Биләд әш-Шәмне өлешләргә бүлгәләүләренә кискен каршы чыгалар, гарәпләргә яңадан берләшү өчен азатлык сорыйлар һәм Палестина хөкүмәтен төзүне таләп итәләр. 1928 нче елга кадәрге

вакыт эченда Палестина милләтчеләре бер-берсенә ошаган шундый жиде конференция уздыруга ирешәләр. Бу сәяси көрәшне, гомумән алганда, ике күренекле шәхес әйдәп бара. Аларның беренчесе — Муса Казыйм әл-Хөсәйни, Палестина Конгрессы Башкарма Комитетының президенты була (1934 нче елда вафат була). Икенчесе исә — ал-Хаж Әмин әл-Хөсәйни (1974 нче елда үлә), 1921 нче елда Иерусалем (Кудс) ның мөфтие дәрәҗәсенә ирешә: 1922 нче елда Югары Мөселман Консуллыгы төзелгәч, анын президенты булып сайлана. Бу шәхес үзенең ботен максаты һәм нияте белән Палестина халкына азатлык яулау юлында көрәшә, Палестинада Британия гегемониясе беткәнче (1948 нче ел) җиһад хәрәкәтенең төп әйдәп баручы һәм җиңелмәслек лидеры булып тора.

**Палестина Милли Хәрәкәте 1918-1929 нчы еллар аралы-гында:**

Сионист программасына каршы күтәрелгән Палестина Милли көрәше, тулаем алганда, 1918-1929 нчы еллар аралыгында мәсьәләне тыныч юл белән генә хәл итәргә омтыла. Милләтчеләр Үзләренең эшчәнлекләрен Британиянен Бальфур декларациясенә карата булган позициясен үзгәртүенә ирешергә һәм алга таба аның бу декларацияне бөтенләй гамәлдән чыгаруын тормышка ашыруга юнәлтәләр. Палестина лидерлары ил халкы көчле Британияне илләреннән куып чыгара алырлык дәрәҗәдә кодрәткә ия түгел дип саныйлар һәм шул ук вакытта Британия үзе аларның хәлләренә керер, вакыйгаларны уңай якка үзгәртер дип оптимистларча өмет итәләр. Ни дисәң дә, Беренче Бөтендөнья сугышы чорында британиялеләр гарәпләр лидеры әш-Шәриф Хөсәен белән бер якта булалар, шуның өстенә Сионист программасы. да әле Палестинанын Язмышын Үзгәртерлек житди дәрәҗәгә җитәргә өлгермәгән була. Хакыйкатьтә, бу рәвешле миражга алданып өмет белән фикер йерту ил лидерларының саяси яктан өлгереп житмәгән булуларын, бу өлкәдә тәжрибәләре бик азлыкны һәм халыкны инкыйлаб юлыннан әйдәп алып бара алуга сәләтләре юклыкны күрсәтеп тора. Милли хәрәкәтнең төп энергиясе, бигрәк тә, үз эчендәге ике гаилә арасында барган лидерлык өчен тартышуга сарыф ителә. Бу Хөсәйнийяһ һәм Нашашибийяһ гаиләләре алга

таба Британия алып барган "бүлгәлә һәм тынычлап идарә ит сәясәтен кабул итеп, Палестина Милли Хәрәкәте эшчәнлегенә зур зыян салалар. Шуңа да карамастан, бу йомшаклыклар һәм ихтилофлар Палестиналыларның сионист программасына һәм Британия империализмына карата булган төп позицияләренә һәм саяси таләпләренә артык зур үзгәрешләр китермиләр.

Сәясәт өлкәсенә килгәндә исә, Палестина җитәкчелеге берничә кыю адым ясый: 1921 нче елның июнендә Лондонга делегация жибара. Бу делегация Британиянең Колонияләр буенча Дәүләт секретаре Уинстон Черчиль һәм аның берничә ярдәмчесе белән очраша, ләкин бу очрашу көткән нәтиҗәләрне бирми, Британия хакимияте Палестина җитәкчелеге таләпләренә колак салмый. Шулай да Британиянең Лордлар Серемониаль Палатасы (Серемониальная Палата Лордов) 1922 нче елда Бальфур декларациясен кире каккан резолюция кабул итә, тик бу резолюция да хөкүмәтнең Палестина мәсьәләсенә карашын үзгәртүгә ирешә алмый.

Палестинаның үз эчендә булган вакыйгаларга килгәндә, 1923 нче елда Британиянең Палестина жирендә Символик Кануни Мәжлес оештыру ниятенә халык кискен рәвештә каршы чыга. 1925 нче елда "Хөрмәтле" Бальфур Палестинага визит ясагач халыкның ачуы тагын да арта, бу вакыйга Палестиналыларның эффектив ровешто бойкот белдеруе белән каршы алына: илкүләм забастовкалар һәм башка җәмгыяви протест акцияләре булып уза. 1922 нче елның 22-25 нче августларында булып үткән Бишенче Палестина Конгрессында катнашучылар, бертавыштан ант итеп, тубондоге милли резолюция кабул итәләр:

"*Без — ботен Палестина гарәпләре вәкилләре, Наблуста узучы бу Бишенче Гарәп-Палестина Конгрессында Аллаһ каршында, тарих һәм халык алдында ант бирәбез: без илебезне азат итү юлында һәм гарәпләрне законлы юллар белән берләштерү өчен үзебезнең корошебезне алга таба да довам итәчәкбез, яһуд иммиграциясенә яисә яһудләрнең Палестинада Милли Ватан төзүләренә беркайчан да юл куймабыз*."[43]

1918-1929 нчы еллар аралыгында Палестина халкы сионист программасына һәм, гомумән, яһүдләргә каршы өч тапкыр баш күтәрә. Милләтчеләр кайбер практик сәбәпләр аркасында Британияга ачыктан-ачык дошманлык белдермәсәләр дә, бу күтәрелешләрнең өчесе дә нәкъ менә Британия тарафыннан рахимсез бастырыла.

"Мәусим Нәби Муса исеме белән тарихка кереп калган беренче баш күтәрү 1920 нче елның 4-10 нчы апрелендә Иерусалемда булып уза, ул биш яһүд һәм дүрт гарәп үлеме, ике йөз унбер яһүд, егерме дүрт гарәпнең яралануы белән тәмамлана. Икенче бәрелеш исә Җәффада (Яффа) башланып китә һәм теньяк Палестинаның башка өлешләренә дә тарала. Монда кырык жиде яһуд һәм кырык сигез гарәпнең гомерләре өзелә, шулай ук йөз кырык алты яһүд һәм җитмеш өч гарәп яралана. Бу чордагы соңгы баш күтәрү исә 1922 нче елның 15 нче август — 2 нче сентябрь аралыгында яһүдләр ал-Окъса мәчетенең ал-Бурак исеме белән аталган көнбатыш стенасын атакалагач протест рәвешендә башланып китә һәм тиз арада бөтен Палестинага тарала. Нәтиҗәдә йөз утыз өч яһүд һәм йөз уналты гарәп үтерелә, өч йөз утыз тугыз яһүд һәм ике йөз утыз ике гареп яралана.

Йомгаклап әйткәндә, бу бәрелешләрнең барысында да яһүдләр гарәпләр тарафыннан зыян күрәләр, ләкин гарәпләр һәрвакытта дип әйтерлек Британия армиясе яисә полициясе тарафыннан үтереләләр яисә яраланалар. Иң мөһиме: бу баш күтәрүләр барысы да ислам байрагы астында алып барыла, Палестина мөфтие әл-Хаж Әмин әл-Хөсәйни исә беренче һәм өченче күтәрелешләрне үзе җитәкли. Ләкин иң кызыгы: урта юлны сайлаган рәсми Палестина җитәкчелеге үзенең бөтен көчен халык белән бергә уртак дошманга каршы көрәшүгә түгел, бәлки накъ менә яһүдләргә каршы күтәрелгән үз халкының ярсуын, ачуын бастыруга сарыф итә.[44]

**Палестина Милли хәрәкәте 1929-1939 нчы еллар аралыгында:**

1929 нчы елда урын алган әл-Буракъ күтәрелеше сионист проектына һәм шулай ук Британия империализмына каршы яна

жиһад хәрәкәте дулкынын башлап җибәрә һәм бу яна харакат 1936-1939 нчы еллардагы Бөек Палестина революциясе чорында узенең иң югары ноктасына жита. 1930-1935 нче еллар аралыгында йөз илле ике мен яһуднең (күбесе Германиядән, барысы да дип әйтерлек югары белемле төрле профессия вәкилләре, атаклы галимнәр, бай сәүдәгәрләр) иммиграциясе нәтиҗәсендә, Палестинадагы яһүдләр санының бермә-бер артуы (1929 нчы елда илдә йөз илле алты мең яһүд саналган) сионист проектының Палестина халкы өчен ни дәрәҗәдә куркыныч булуын тулысынча ачып бирә. Шуңа өстәп, яһүдләр 1930-1935 нче еллар аралыгында 229 мен донум (бер донум — 1000 кв. метр) Палестина җиренә ия булырга өлгерәләр. Шулай ук яһүдләр Палестина җиренә законсыз рәвештә масса күләм корал ташый башлыйлар. Мәсәлән, 1930 нчы елның 15 нче мартында һәм 1935 нче елнын 16 нчы октябренда яһүдләрнең Палестинага законсыз рәвештә корал кертерүләре фаш ителә.[45]

Утызынчы елларның беренче яртысы Палестинада саяси активлык көчею һәм “авыруның асылы вә бөтен бәлаләрнең сәбәпчесе булган" Британия идарәсе белән ике арада дошманлык хисләре һәм хәрби каршылык арту белән сыйфатлана. Кайбер Палестина сояси партияләре һәм оешмалары нәкъ менә шушы периодта формалаша да инде. Алар арасында ин беренчесе булып 1932 нче елның августында "Хизб әл-истикълэл" (Мес- тәкыйльлек партиясе) барлыкка килә. Британиягә каршы көрәш идеясе белән сугарылган бу партиянең тәэсире 1933 нче елларда кими. Шушы оешма идеяләре нигезендә 1935 нче елның мартында оешкан "әл-Хизб әл-Гарәби әл-Фәләстыйни" (Гарәп- Палестина партиясе) исә халык арасында тагын да популяр була һәм шулай ук мөфти әл-Хаҗ Әмин тарафыннан да көчле ярдәм һәм яклау таба.[46] Бу чорда шулай ук кайбер мөселман яшьләре организацияләре дә Гиз әд-Дин әл-Кассам "Жиһадийййәһ" ("Көрәшчеләр") һәм Абделка- дыйр әл-Хөсәйни җитәкчелегендәге "Әл-Жиһад әл- Мекаддес" ("Изге Кораш") хәрәкәтләре дә туган җирләрен басып алган дошманга каршы үзләренең яшерен хәрби көрәшләрен башлап җибәрәләр. Бу чорда шулай ук "Әл-Кәфф әл-Әхдар" ("Яшел Кул") кебек кайбер кечкенә революцион группалар да барлыкка

килеп, бу партияләр һәм хәрәкәтләр барысы да империалистик власть белән бәрелешәләр.

Бу чорда Палестиналыларның үз хокукларына бары тыныч юл белән генә ирешергә өметләре тәмам өзелә, бу әл-Хаж Әмин әл-Хөсәйни сүзләрендә дә ачык күренә: "1932 нче елга кадәр бездә әле өмет очкыннары бар иде, ләкин алар инде эреп тәмам юкка чыктылар. Безнең бөтен газапларыбыз һәм сызлануларыбыз кемнеңдер бик оста эшләнгән планы буенча бара... Безгә шәһид китүдән башка юл калмады инде...”[47] Британиянен Иминлек Саклау көчләре бүлеге мөдире тарафыннан язылган хатирәләрдә мондый юллар бар: "Гарәпләрнең Британия мандатына һәм илдәге идарәгә каршылык хисләре тагын да артты. Бу хисләр халыкның бөтен катламына да хас, барысы да ачулы, ярсыган һәм бу күралмау хисләре елдан-ел арта бара. Британия үзләренә карата гаделлек кылыр дип көткән гарәпләрнең өметләре аяк астына салып тапталды”[48]. Алга таба берничә вакыйга сәбәпле халыкның Британия идарәсенә карата булган каршылык хисләре тагын да көчәя. Башта Британия хөкүмәтеннән кискенләшә барган хәлләрне тыныч юл белән уңай якка хәл итүне сорап 1930 нчы елда Муса Казыйм әл-Хөсәйни җитәкчелегендә Лондонга җибәрелгән делегация уңышсызлыкка очрый. Аннан соң Британия хөкүмәте тарафыннан Палестинага жир мәсьәләсе, буенча килеп туган проблемаларны тикшерергә һәм хәл итәргә тәҗрибәле белгеч Д.Х.Симпсон җибәрелә. Ныклап тикшергәннән соң, ул түбәндәге нәтиҗәгә килә: Палестинада инде яһүдләргә бирердей буш җирләр калмаган. Шуңа да ул бу җиргә иммиграцияне бик нык киметергә яисә бөтенләй туктатырга киңәш бирә.[49] Ләкин белгеч тәкъдим иткән җир реформалары аны бу җиргә тикшерү өчен җибәргән Британия хөкүмәтенең үзе тарафыннан ук кире кагыла. Шуңа өстәп, Британия хөкүмәте алга таба 1930 нчы елда язылган "Ак китап"ның "Яһудләрнен Палестинага эмиграциясен контроль астына алырга" дигән пунктын 1931 нче елда "Кара китап" белән рәсми рәвештә бөтенләй гамәлдән чыгара. Бу вакыйга Британиянең сионист программасы тарафдары икәнен ачыктан-ачык раслый, нәтиҗәдә илдәге хәлләр тагын да кискенләшә.[50]

Милләтчеләр Палестина мәсьәләсенең бөтен гарәп-ислам деньясы проблемасы икәнлеген раслау өлкәсендә дә актив эшчәнлек алып баралар. Рәсми отчётларда (май, 1931 нче ел) эйтелгәнчә, гарәп илләрен, бигрәк тә Палестина һәм Сирияне саклап калу буенча Мөселманнарның Революцион планнары төзелә. Либнанның атаклы ислам лидеры принц Шәкиб Арсәлән иса әл-Хаж Әмин әл-Хөсәйни һәм Индия мөселман активисты Мәүләнә Шәүкәт Гали белән берлектә бу революцион план төзү хәрәкәтен үзе җитәкли. Принц Шәкиб шулай ук Гарәп Ярымутравы, Гыйрак, Мисыр һәм әш-Шәмдәге гарәп азатлык хәрәкәтләре тарафыннан да зур яклау таба. Ләкин Британияга каршы оештырылган планга тормышка ашу насыйп булмый.[51] Ислам дөньясының Палестина проблемасына мөнәсәбәте, бигрәк та, 1931 нче елның 17 нче декабренда Иерусалемда әл-Хаж Әмин әл-Хосейни президентлыгы астында булып үткән Гомуми Ислам Конгрессында бик ачык күренә. Бу конгресста егерме ике илдән вәкилләр катнашып, алар арасында Шәйх Мөхәммәд Рәшид Рида, Индия галиме һәм шагыйре Мөхәммәд Икбал, Индия лидеры Шәүкәт Гали, Тунисия җитәкчесе Габделгазиз әс- Сәгалиби, Иранның элеккеге Премьер Министры Зыя әд-Дин әт- Табтабәэй һәм Сирия лидеры Шукри әл-Кувәтли кебек күренекле галимнәр һәм атаклы шәхесләр дә була.[52] Бу мөселманнар җыены Ислам университеты ачу, Палестина жирен саклап калу буенча комерческая компания булдыру һәм кайбер илләрдә Палестина Комитетларын оештыру кебек берничә практик карар кабул итә.[53] Ләкин бөтен мөселман дөньясының империалистик көчләр гегемониясе астында булуы, Британиянең чираттагы ялган һәм заговорлары сәбәпле бу карарларның күбесе тормышка ашмый кала. Алга таба көрәш юлында әйдәп бару ролен Палестина галимнәре үз кулларына алалар. Аларның 1935 нче елның 25 нче январенда булып узган Беренче конференцияләре, шулай ук яһүдләргә җир сатуны ислам законнары буенча харам итеп тыюлары һәм бу дини тыюны бозган һәркемне кәфер дип игълан иту кебек фәтвәләр бирүләре дә шуны бик ачык чагылдырып тора.[54]

Бу чорда яһүдләргә һәм аларның төп ярдәмчеләре булган британиялеләргә каршылык һәм дошманлык хисләре көннән-көн арта бара. "Яшел Кул"хәрәкәте утызынчы еллар башында ук

узена нигез салучы Әхмәд Тафиш җитәкчелегендә җиһад кампанияләрен башлап җибәреп, хәтта берничә кыю операцияләр ясарга да өлгерә. Ләкин Британия бу организацияне коч кулланып 1930 нчы елнын февралендә таркатуга ireше, житәкчесен кулга ала.[55] 1933 нче елның октябренда Палестина сояси җитәкчелегенен оппозициясе җитдирак тос ала, нәтиҗәдә тиз арада ике көчле демонстрация кабынырга өлгерә: беренчесе 13 нче октябрьда Иерусалемда әл-Экъса мәчетендә була, икенчесе исә 27 нче октябрьда Җәффада җомга намазыннан сон башланып кита. Бу акцияләрдә Палестина җитәкчеләре үзләре дә катнашалар, тиз арада илкүләм забастовкалар кабына. Бу вакыйгалар нәтиҗәсендә 35 гарәп шәһид китә, 255 гарәп яралана. Бу ярсулы демонстрацияләр рухы башка шәһәрләргә дә күчә: Хәнфә, Иерусалем, Наблус, Бир әс-Сәбьә (Биршеебә) һәм әл-Лүд (Лудда) шәһәрләре халкы илкүләм демонстрацияга кушыла, ботен ил жиде көн буена забастовка хәлендә яши. Нәтиҗәдә, Палестиналыларның югалтулары да зур була. Шул исәптән, Муса Казыйм әл-Хөсәйни анын югалтканчы кыйналып, бу алган яралары сонрак аның үлеменә сәбәпче була (1934 нче елнын мартында сиксән бер яшендә вафат була).[56] Шулай ук унике Палестина житәкчеләре дә кулга алына, аларның өчесе исә Идарә Комитетыннан булалар.

Икенче бер яшерен жиһад организациясе — "Әл-жиһадийяһ хәрәкәте" — исе әш-Шайх Гыйзз әд-Дин әл-Кассәм тарафыннан "Бары тик җиһад: я җиңәргә, я үләргә" девизы астында 1925 нче елда оешкан була. Төньяк Палестинада, бигрәк тә эшче һәм крестьяннар арасында, киңкүләм популярлык казана. Анын сафларында төп үзәкне ике йөзләп мөҗәһид тәшкил итеп, тагын сигез йөзләп кеше ярдәмче рольне башкарганнар. Бу яшерен оешма утызынчы елларның беренче яртысында яһүдләргә каршы берничә кыю операция оештыруга ирешә, ә 1935 нче елның ноябрендә үзен ачыктан-ачык игълан итә. Егерменче ноябрьда исә хәрәкәтнең лидеры Шәйх әл-Кассам һәм аның ике коллегасы полиция белән ике арада булган бәрелештә шәһид китәләр, ләкин хәрәкәт моның белән генә тукталып калмый, әш-Шәйх Фәрхан әс-Сәгъди лидерлыкны үз кулына ала. 1936-1939 нчы елларда булган Боек Палестина Революциясендә әйдәп бару ролен нәкъ менә бу хәрәкәт башкара да инде.[57]

"әл-Жиһад әл-Мекаддәс" исемле милли-ислам хәрәкәте исә ботен игътибарын Иерусалем һәм Хеброн тирәсендәге көрәшкә юнәлтә. Хәрәкәтнең җитәкчесе Габделкадыйр ал-Хөсәйни булып, Мөфти әл-Хаж Әмин үзе аңа кулыннан килгән кадәр ярдәм күрсәтә. 1935 нче елда исә бу организациянең әгъзаләре саны дүрт йөзгә житә.[58] Бу хәрәкәт тә Бөек Революциядә бик актив катнашып, бигрәк тә Иерусалем һәм Хеброн регионнарындагы көрәштә әйдәп баручы көч булып тора.

**Бөек Палестина Революциясе (1936-1939 нчы еллар):**

Яна һәм Хәзерге чор Палестина тарихында иң югары хәрби күтәрелеш булып торган бу Бөек Революция 1936 нчы елның 15 нче апрелендә әш-Шәйх Фәрхан әс-Сәгъди җитәкчелегендәге "Жиһадийяћ" (Касыймийяһ) төркеме кулыннан ике яһуд үтерелгәч башланып китә. Гарәпләр һәм яһудләр арасын сонгы чиккә җиткергән бу вакыйгадан соң мөнәсәбәтләр тагын да катлаулана, алга таба гарәпләр тарафыннан берничә революцион адым ясала: 178 көнгә сузылган илкүләм забастовка башланып китә (Палестина тарихында булган ин озын забастовка санала), бөтен гарәп хәрәкәтләре һәм партияләре бер фронтка берләшәләр, 20 нче апрельдә исә әл-Хаж Әмин әл-Хөсәйни президентлыгында Югары Гарәп Комитеты формалаша... Милләтчеләр революцияне үзләренең төп таләпләре үтәлгәнче, төбәп әйткәндә — демократик рәвештә сайланган Палестина хөкүмәте төзелгәнче, Палестинага яһуд иммиграциясе һәм илнең жирен бу сукбайларга сату туктатылганчы дәвам итәргә сүз бирәләр. Шулай да гарәп илләре әмирләре һәм мәликләре милләтчеләрдән Палестинадагы бу шартларга житешкән ситуацияне тикшерү һәм чаралар күрү өчен Британия Король Комиссиясенә (Пил комиссиясе) мөмкинчелек бирүләрен сорагач, милләтчеләр 1936 нчы елның октябренда үзләренең революцион эшчәнлекләрен вакытлыча туктатырга риза булалар. Ләкин бу тикшерүләр нәтиҗәсендә 1937 нче елның июль башында Палестинаны гарәпләр һәм яһүдләр арасында икегә бүләргә дигән уңышсыз рекомендация булгач, революция кискен борылыш кичерә. 1937 нче елның 26 нчы сентябренда әл-Жәлил районындагы Британия губернаторы Эндрюс үтерелгәч, илдәге революция дулкыны тагын да көчәя. Чиктән тыш ярсыган

Британия хөкүмәте Югары Мөселман Советын, Югары Гарәп Комитетын һәм башка милли комитетларны тарката. Ләкин хөкүмәтнен әл-Хаж Әминне кулга алырга тырышуы уңышка ирешми, ул утыз жиденең октябрь урталарында илдән чыгып китеп, алга таба Либнаннан торып революция белән җитәкчелек итә. Шулай да Югары Гарәп Комитетының дүрт әгъзасе кулга алынып, һинд океанындагы Сейшельс утравына сөргенгә озатыла.

1938 нче елның жәендә революция үзенең иң югары ноктасына җитә. Мәжәһидләрнең авыл җирләре белән идарә итүләре һәм хәтта кайбер Палестина шәһәрләрен тулысынча басып алулары нәтиҗәсендә Британия идарәсе өлешчә таркала. Әгәр дә сүз бары тик милләтчеләр һәм колонизаторлар арасындагы кара-каршы бәрелеш турында гына барса, әлбәттә, Британия халык таләпләренә чигенеп, аларга тиешле хокукларын да бирер иде. Ләкин сионистларнын эшчәнлеге һәм аларның үз проектларын тормышка ашыру өчен Британиядән ярдәм таләп итүләре бу ситуацияне бик нык катлауландыра. Яһудләрнең көчле тәэсиргә ия лоббие Британияне Палестина жиренә тагын да күбрәк армия жибәрергә ризалата. Хайнинг, Мантгомери кебек атаклы хәрби командирлар житәкчелегендәге бу яна көчле армия Палестина жирендәге һәрбер шәһәр, һәрбер авылны берсе артыннан икенчесен яңадан басып ала, йортларны жимера, халыкны буйсындыру өчен мөмкин булган чараларның барысын да күрергә тырыша. Фәрхан әс-Сәгъди, Мөхәммәд әс-Салих әл- Хәмәд, Габдеррахим әл-Хаж Мөхәммәд, Йосыф Әбу Дураһ кебек күренекле Палестина лидерлары шәһид китә. Шулай итеп, революция, кызганычка каршы, үзенең максатына ирешә алмыйча 1939 нчы елның жәендә тәмамлана. [59]

Революцияне рәхимсез бастырган вакытта Британия, шулай да, Палестинадагы бу авыр ситуациядән тыныч сәяси чыгу юлы эзләргә тырыша: Палестинаны бүлү проектын гамәлдән чыгара, Сейшельс утравындагы тоткыннарны азат итә һәм килеп туган кризизны бергәләп тикшереп, аннан чыгу юлын эзләү өчен 1939 нчы елның февралендә Лондонда Түгәрәк Өстәл Конференциясе жыя. Бу җыенда гарәп, Палестина һәм яһуд делегатлары катнаша, ләкин алар конкрет нәтиҗәгә килә алмыйлар. Шуннан соң

Британия үзе бу кризистан чыгу юлы тәкъдим итеп, 1939 нчы елның маенда "Ак Китап" чыгара. Мәсьәләнен бу рәвешле чишелеше Палестиналылар өчен зур саяси жицү була, чөнки бу китап-программада Британия үзенең Палестинада бернинди дә яшерен яһуд дәүләте төзергә планы юклыгын, бәлки киресенчә, алдагы ун ел эчендә гарәпләр һәм яһудләр тигез хокукка ия булачак мөстәкыйль Палестина дәүләте төзергә нияте булуын ачык итеп әйтә. "Ак Китап"та язылганча, алдагы биш ел эчендә яһүдләрнең Палестинага иммиграциясе җитмеш биш меннән артмаска тиеш, шуннан соң иммиграция бөтенләй туктатылып, алга таба бары тик гарәпләр ризалыгы белән генә тормышка ашырыла ала. Шулай ук Палестинаның кайбер өлешләрендә яһүдләрнең жир сатып алулары бөтенләй тыела, а илнең калган өлешләрендә исә мөмкин кадәр чикләнелә.[60]

Шулай да Палестина житәкчелеге бу Британия схемасын ике куллап кабул итәргә ашыкмый, кайбер җитәкчеләр исә аны бөтенләй кире кага, чөнки бу схема Палестина азатлыгын яһүдләр белән бергә бәйләп карый. Гарәпләр, гомумән, Британия биргән вәгъдәләргә бөтенләй ышанмый башлаган булалар. Шуңа өстәп, бу план Палестина активистларының барысына да амнистия бирми, шул исәптән Палестиналыларның илдән куылган лидерлары әл-Хаж Әмингә дә амнистия каралмый. Әлбәттә, инде Британия гамәлгә кертергә вәгъдә биргән бу схеманы алдан ук бернәрсә дә уйламыйча кабул итү зур акылсызлык булыр иде. "Сабыр итеп көт һәм нәтиҗәсен күрерсен" политикасы бу вакыйгага мөнәсәбәттә Британиянең ышанычлылыгын сынарга бик яхшы шанс бирә. Яһүдләр, икенче яктан, Британиянең бу план-схемасын бертавыштан бөтенләй кире кагалар.[61]

**1939-1947 нче еллар аралыгында булып үткән сәяси вакыйгалар:**

Икенче Бөтендөнья сугышы чоры (1939-1945) Пале- стиналыларга һәм аларның проблемаларын хәл итү эшчәнлегенә катастрофик фаҗигаләр һәм бәлалар алып килә. Бу еллар аралыгында Палестина милли хәрәкәтенең хәрби мөмкин- челекләре һәм сәяси көче бик нык зәгыйфьләнә; көрәш

лидерлары, бигрәк тә әл-Хаж Әмин, үзенә ышанычлы урын эзләп, илдән илгә йөрергә мәҗбүр була. Ул башта Либнаннан Гыйракка иммиграция ясый. Монда исә әл-Хаж Әмин анти- Британия Милли Идарә оештыруны башлап җибәрүдә катнаша. Ләкин бу идарә бик тиз арада тар-мар ителеп, әл-Хаж Әмин Иранга китәргә мәҗбүр була, аннан Төркиягә хиҗрат кыла, 1941 нче елның ноябрендә исә Германиягә барып житә. Шулай итеп, икейөзле Британиянең дошманлыгы һәм ялганга корылган сәясәт алып баруы әл-Хаж Әмингә фашист Германиясеннән ярдәм өмет итүдән башка чара калдырмый. Германия исә үзенең союзнигы Италия белән берлектә Палестина мәсьәләсе буенча декларация әзерләп, бу декларациядә "Яһүд Милли Ватаны" төшенчәсен бөтенләй юкка чыгарырга һәм Британия астындагы бөтен гарәп илләренә азатлык алырга ярдәм итүдә кулларыннан килгәннен барысын да эшләргә тәкъдим итә. Германия бу декларацияне гаскәрләре Кавказ регионына барып җиткәнче гамәлгә кертергә ашыкмаса да, әл-Хаж Әмин үзенең Германиядә булуыннан файдаланып, 1943 нче елның икенче ноябрендә германнар тарафыннан өйрәтелүче Рәсми Гарәп армиясе төзүгә ирешә. Йөзләгән гарәп яшьләре бу армиягә алына, Германия исә аларны кирәкле корал белән тәэмин итә, хәтта Либия жиренә киләчәктә куллану өчен утыз мен винтовка яшерелә.[62] Ләкин сугышта нәкъ мена Британиянен жинеп чыгуы Палестиналыларны һәм аларның җитәкчеләрен бик кискен хәлгә куя. Франция әл-Хаж Әминне кулга ала, ләкин 1946 нчы елның июнендә әл-Хаж Әмингә Мисырга качарга насыйп була. Аның яңадан иректә һәм имин жирдә булуы Палестинада киң күләмдә һәм горурлык белән бәйрәм ителә. Менә шушы вакыйга үзе генә дә мөфтинен Палестина халкы арасында ни дәрәҗәдә мәшһүр булуын бик ачык күрсәтеп тора.[63]

1946 нчы елның июнендә Гарәп Лигасы әл-Хаж Әмин президентлыгы астында Палестина жире буенча Югары Гарәп Идарәсе оештыра. Ләкин әл-Хаж Әминнен Иордания һәм Гыйрак хөкүмәтләре белән мөнәсәбәте бик кискен булу, шулай ук анын Британия контроле астындагы Мисырда булуы Палестина проблемасын хәл итүне алга жибәрергә, бу мәсьәлә буенча йөрергә, эш алып барырга уңай шартлар тудыра алмый.

Яһудләр исә Германиядән һәм Көнчыгыш Европадан куылуларын башкаларда, бигрәк тә шул чорның көчле тәэсиргә ия шәхесләрендә үзләренә карата симпатия тудыру өчен куллана башлыйлар. Шуңа өстәп, яһүдләр, бу килеп туган шартларны үзләре өчен бик оста файдаланып, иминлеккә бары тик үзләренә Палестина жирендә Милли Ватан төзеп кенә ирешә алачакларына мөмкин кадәр ныграк басым ясарга тырышалар. Аларның лоббие, бигрәк тә Америкада уңышка ирешә, 1942 нче елдагы Бальтимур (Блитморе) Конференциясендә яһудлар Республикачылар һәм Демократларның икесен дә 1939 нчы елда кабул ителгән "Ак Китапны гамәлдән чыгарылган дип кабул итәргә ризалаталар. Яһүдләрнең Америкадагы һәм гомумән бөтен дөньядагы көче вә тәэсире алга таба про-сионист Труманның АКШ пре- зидентлыгына үтеп керүе белән тагын да ныгый. 1945 нче елның 31 нче августында Труман, Британиянен Премьер Министры Эттлига рәсми рәвештә мөрәҗәгать итеп, аннан йөз мен яһудкә Палестина жиренә иммиграция ясарга рөхсәт итүен сорый. Авыр сугыш шартларыннан оста файдаланып калып, бу елларда яһүдләр үзләрен тәртипкә кертергә, шулай ук хәрби һәм сәяси яктан көчәеп калырга өлгерәләр. Башлыча "Хаган" организациясе әгъзаләре булган егерме алты мең Палестина яһуде Британия армиясенең яһүд хәрби частьларына кушылалар, бу частьлар исә алга таба барлыкка киләчәк Яһүд дәүләте хәрби көченең үзәк тешен тәшкил итәләр. Яһүдләрнең Палестинага иммиграциясе сугыш елларында һәм сугыштан соңгы чорда бик кискен арта: 1939-1945 нче еллар аралыгында туксан ике мен, а 1946-1948 нче еллар аралыгында исә алтмыш бер мен яһуд Палестинага күчеп килә. Алар шулай ук 1939-1947 нче еллар аралыгында ике йөз житмеш мен донум Палестина жҗиренә хужа булырга өлгерәләр, шуна өстәп, 1940-1948 нче еллар аралыгындагы сигез ел эчендә житмеш өч колония төзүгә ирешәләр. Американың бик көчле тәэсире астында булган Британия Тышкы Эшләр министры Эрнест Бевин 1945 нче елның 14 нче ноябрендә үз дәүләтенең "Ак Китап"та (1939) язылган карарлардан баш тартуын ресми рәвештә игълан итә. Ул шулай ук Палестина проблемасын тикшерү һәм хәл итү өчен Англо-Америка Комитеты төзергә киңәш бирә. Мәсьәләгә шул рәвешле про-сионист АКШнын да катнаша башлавы Палестиналыларның киләчәкләре ечен катастрофик зур фаҗига була. Бу комитет мәсьәләгә бөтенләй

объектив карамыйча, 1946 нчы елда йөз мең яһудка Палестинага күчеп килергә һәм җирне яһүдләргә сатуны ирекле итәргә рөхсәт бирә.[64]

Британия Палестина проблемасына чишелеш табуны Берләшкән Милләтләр Оешмасының көн тәртибенә куюны сорап рәсми рәвештә таләп белән чыккач, Палестина мәсьәләсе, 1947 нче елның 2 нче апреленнән башлап, дөньякүләм төс ала. Бу проблеманы мөмкин кадәр тиз арада өйрәнеп отчёт биру өчен Халыкара Комитет төзелә (UNSCOP). Ләкин бу комитет та мәсьәләгә гадел якын килмичә, Палестина территориясен яһуд һәм гарәп мөстәкыйль дәүләтләренә бүләргә, ә Иерусалемга исә Халыкара статус бирергә дигән кырыс тәкъдим белән чыга. [65]

Бу гаделсезлектән һәм кимсетелүдән ярсыган Гарәп Лигасы тиз арада ике конференция жыя: 1947 нче елның 6 нчы сентябрендә Суфар конференциясе һәм шушы ук елның 7-15 нче октябрендә Гәләйһ конференцияләре булып уза. Бу конфе- ренцияләрдә Гарәп Лигасы БМОның Палестинаны икегә бүләргә дигән рекомендациясен бөтенләй кире кага һәм Палести- налыларга кичектергесез рәвештә армия жыярга һәм корал әзерләргә тәкъдим итә.

1947 нче елның 29 нчы ноябрендә Берләшкән Милләтләр Оешмасының Гомуми Ассамблеясе, АКІШ һәм Советлар Союзының көчле басымы астында, тавышның 2/3е белән, Палестинаны Гарәп һәм Яһүд дәүләтләренә бүләргә дигән коточкыч карар чыгара. Бу урында шунысын әйтеп үтәргә кирәк: беренчедән, БМОның Гомуми Ассамблеясе эшчәнлеге, гомумән алганда, карарлар кабул итүне түгел, бәлки тәкъдим ясауны гына үз эченә алырга тиеш була; икенчедән, анын тарафыннан кабул ителгән бу карар үзе үк бу Ассамблеяне барлыкка китергән, шулай ук үзе якларга һәм сакларга тиеш булып торган "азатлыкка хокук" һәм "һәр милләтнең үз киләчәген үзе хал итәргә хакы булуы" кебек асыл принципларга каршы чыга. Бу гаделсез карар Палестинаның 54% ын, жирнең төп халкы кулыннан тартып алып, сукбай яһудләргә бирә, ә бит ул чорда яһудләр барлык Палестина жиренең 6.5% ына гына ия булып, илдәге халык санының 31.7% ын гына тәшкил иткән булалар.

**Британия оккупациясе вакытында Палестинадагы халык саны:**

| Ел | Гарәпләр | | Яһүдләр | |
|---|---|---|---|---|
| | Процент | Сан | Процент | Сан |
| 1918 | 91.6% | 600.000 | 8.4% | 55.000 |
| 1948 | 68.3% | 1.390.000 | 31.7% | 646.000 |

**Британия оккупациясе чорында Палестинада жиргэ хужа булу:**

| Ел | Гарәпләр | Яһүдләр |
|---|---|---|
| 1918 | 98% | 2% |
| 1948 | 93.5% | 6.5% |

**1948 нче елгы сугыш һәм аның нәтиҗәләре:**

1948 нче елгы гарәп-сионист сугышы Палестина жирен икегә бүлү турында указ кабул ителү нәтиҗәсендә башланып китә. Аз сандагы мөселман һәм гарәп ирекле көрәшчеләреннән (волонтерлар) торган "Жәйш әл-Инказ" ("Коткару Армиясе") армиясен исәпкә алмаганда, беренче алты айда сугышның бөтен авырлыгы "әл-Жиһад әл-Мекаддәс" ("Изге көрәш") исемендәге Палестина армиясе җилкәсенә төшә. Гарәп илләреннән җыелган бик начар һәм сыйфатсыз коралларга гына ия булуларына карамастан, бу армия сугыш серләрен яхшылап өйрәнгән һәм Британиянең көчле ярдәме астында булган яһүд армиясе белән шактый вакыт бик кыю сугыша. Хакыйкатьтә, армия Палестина жиренең 82% ын саклап кала ала, яһудләрне зур югалтуларга дучар итә. Нәтиҗәдә, кырык сигезнең мартында АКШ бүленеш планыннан чигенергә мәҗбүр була һәм алга таба яһүдләргә ярдәм итү юллары хакында житди рәвештә уйлана башлый.

Кызганычка каршы, жиде гарәп иленнән ярдәм итеп жибәрелгән гарәп армиясенең сугышка керүе вакыйгаларны тамырдан үзгәртә. 24 мен солдаттан торган бу армия, әлбәттә, 70 мен яхшы коралланган яһуд гангстерларына каршы тора алмый. Бу урында шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: гарәп армиясе солдатларынын сугыш тактикасы буенча белемнәре юк

дәрәҗәсендә булып, шуның өстенә отрядлар арасындагы координация да түбән дәрәҗәдә була; иске һәм начар корал, профессиональ булмаган җитәкчелек — болар барысы да армиянең җиңелүендәге төп сәбәпләре булып торалар. Ин аянычы, бу армиядәге илле югары чиндагы командирның кырык бише британлылар була, менә шуңа күрә дә яһудләр белән сугышырга тиешле бу үзешчән армия үз вакытын Палестинаның ирекле көрәшчеләрен — коралсызландыруга кораллландыру түгел! — сарыф итә. Бу кимчелекләр барысы да гарәп илләренен үз эчләрендәге саяси каршылыкны һәм аларның империалистик Британия гегемониясе астында булулары дәвам итүен бик ачык күрсәтеп тора.[66]

Палестиналыларның һәм шулай ук гарәп-мөселман дөньясы халкының энтузиазмы һәм изге җиһадка бирелгәнлеге, шул рәвешле, сәяси һәм хәрби житәкчелек тарафыннан юкка чыгарыла. Мисал өчен, Мисырның "Җәмәгать әл-Ихван әл- Мөслимин" ("Мөселман Туганнар Җәмгыяте") Палестинаны коткарып калу өчен булдыра алганча көрәш алып бара. Лидерлары шәһид Хәссан әл-Бәнна 1948 нче елның октябренда беренче ун мен мөҗәһидне сугышка җибәрергә әзерли. Ләкин Мисыр хөкүмәте тарафыннан аларга илдән чыгып китү тыелып, бары тик аз сандагы көрәшчеләргә генә жиһадка китәргә мөмкин була. Алары да илгә кире кайтканда үз хөкүмәтләре тарафыннан кулга алынып төрмәләргә ябылалар. Җәмгыять үзе дә хөкүмәт тарафыннан таркатыла, җитәкчеләре әл-Бәнна исә 1949 нчы елның 11 нче февралендә, нәкъ менә сионист берләшмәсе Израил төзелүгә кул куелган чорда үтерелә.

Шулай ук Иордания, Сирия, Гыйрактан да мөселман һәм гарәпләр, шул исәптән 250 босняк та үз теләкләре белән Палестина азатлыгы өчен көрәш юлына басалар. Бу сугышта Палестиналыларга иң зур зыян салган нәрсә — аларның гарәп армиясе тарафыннан коралсызландырылулары булса, гарәп солдатлары исә коралларының искереп беткән һәм эшкә яраксыз булуыннан жәфа чигәләр, бу иске кораллар, солдатлар дошманга атам дигәндә генә, кайчак аларның үз кулларында шартлый торган була.

Гарәп армиясенең жинелүе нәтиҗәсендә Палестина жиренең 78% ы конфискацияләнә һәм 1948 нче елның 14 нче маенда яһүдләр үзләренең дәүләтләре Израилне рәсми рәвештә игълан итәләр. Палестиналылар исә үз чиратларында, 1948 нче елның октябрендә булып узган Газа конференциясендә бөтен тарихи Палестина жирен дә үз эченә алучы Бетен Палестина хөкүмәтен игълан итәләр. Ләкин Палестина жирендәге гарәп армияләре бу карарны тормышка ашыруга тоткарлык ясыйлар, ә әл-Хаж Әмин әл-Хөсәйнине исә "персона нон грата" рәвешендә Газадан Мисырга сөргенгә сөрәләр.

1948 нче елгы сугышның нәтиҗәләре бик тиз күренә башлый: яһуди-сионист бандалары 60% Палестина халкын (бөтен Палестинадагы 1 390 000 кешенең якынча 800 000е) яшәгән йортларыннан куып чыгарып читкә китәргә мәҗбүр итәләр, шуна өстәп, басып алынган җирләрдәге 30 000 халыкны Палестинаның кеше яшәми яисә яшәү яклары бик авыр булган башка ерак урыннарына күчерәләр. Рәхимсез сионистлар 1948 нче елгы сугышка кадәр булган 585 Палестина авылының 478ен жимерәләр, 1948 нче елгы сугыш вакытында утыз дүрт тапкыр тыныч тормыш халкын массакүләм үтерү оештыралар. Бу кешелек каршындагы җинаятьләрнең иң коточкычы — 1948 нче елның 10 нчы апрелендә булган Дәйр Ясиндәге варварлык вакыйгасы була. Яһүдләрнең үз чыганаклары буенча, монда 254 ир-ат, хатын-кыз һәм балаларның каны коела.[67] Шушы вакыйга үзе генә дә сионистлар һәм аларның Көнбатыш "агалары" мактанырга ярата торган үзләре алып баручы "цивилизацияләү миссиясенең төп асылын бик ачык күрсәтеп тора!

1948 нче елгы сугыш Палестина халкының социаль- экономик яшәеш тукымасын төптән җимерә, алар 4500 ел буе гомер иткән, каннары береккән туган жирләреннән бик тиз вакыт эчендә чит җирләргә чыгып китәргә мәҗбүр булалар. Башка халыклар, төбәп әйткәндә нацист Германия һәм "анти семитик" Рәсәй тарафыннан яһудләрне Европадан куып чыгару хатасы өчен түләүне монда бернинди катнашы булмаган мөселман кешеләре жилкәсенә салу һәм аларны про-сионист империалистик көчләр белән берлектә үз өйләреннән куып чыгару — бу, әлбәттә, иң зур гаделсезлек, кешелексезлек һәм

мөселманнарны кимсетү булып тора. Яһүдләр, үзләренең Европадан куылуларын файдаланып, бернинди кызгану һәм гаеплелек хисе кичермичә, оятсыз рәвештә Палестинаның жирле халкы каны өстеннән юл салып, үзләренә "сукбай" Ватан төзиләр. Дөрестән дә, яһүдләрнең үз армия командирлары, соңыннан Оборона Министры дәрәҗәсенә ирешкән (шулай ук танылган археолог буларак та билгеле) Муше Даян бу жинаятьне түбәндәге сүзләр белән бик ачык итеп әйтте: "Мондагы һәрбер яһүд авылы Палестина авылы харәбәсе урынына төзелгән".[68] Бу мәсьәлә турыдан-туры булмаса да, БМОның кабатланган резолюцияләрендә дә еш телгә алынып (2000 нче елга кадәр бу хакта 110 резолюция кабул ителгән), төрле җирләргә таралырга мәжбүр булган 4.7 миллион Палестина качакларына үзләренең туган туфракларына әйләнеп кайтырга мөмкинчелек бирү хакында еш сүз кузгатыла. Бу санга өстәп тагын Көнбатыш Яр буе (West Bank) һәм Газа Полосасында (Gaza Strip) яшәүче 1.6 миллион кеше дә үз өйләреннән куып чыгарылып, гаиләләреннән аерылган икәнлеген онытмаска кирәк (2000 нче елгы статистик мәгълүмәтләр буенча).

# ӨЧЕНЧЕ ФАСЫЛ

## Палестина мәсьәләсе 1949-1967 нче еллар аралыгында

1948 нче елгы сугышта жиңелу фаҗигасе Палестиналылар, гарәпләр һәм гомумән бөтен мөселман халкы күңелендә михнәт, Өметсезлек, сызлану һәм түбәнсетелү кебек хисләр тудыра. Палестина халкы үз тарихларында беренче тапкыр каннары береккән җирләреннән тамырлары өзелеп, аларның кеше буларак хокукларын танымаган варвар режим астында кала; шуңа да алар һәм азатлыкка ирешү, кеше буларак хокукларын мөстәкыйльлекләрен яулап алу өчен сәяси һәм хәрби жиһад организацияләре оештыру эшен башлап җибәрәләр. Шулай итеп, бу талантлы һәм зирәк халык илдә килеп туган коточкыч шартларда да югалып калмый, авыр хәлләренә бик тиз яраклашып, бөтен көчләрен киләчәктә булачак авырлыкларга каршы тора алырлык ин кирәкле корал — белем белән кораллануга сарыф итә башлый. Дөрестән дә, хәзерге көндәге Палестиналылар, үзләренең башка гарәп илләрендәге туганнары белән чагыштырганда, күпкә укымышлырак саналалар.

**Гарәп илләре һәм Палестина:**

1949-1967 нче еллар аралыгында күп гарәп-мөселман илләрендә империализмның физик формасы бетерелеп, ул прогрессив рәвештә колония булып калуның икенче формасы — Көнбатыш культурасының чын колына әйләнеп, "мөстәкыйль гражданнар" идеясен һәм хәрби режимнарны (либераль, социалистик, яисә консерватив булсын) үзләренә турыдан-туры елге итеп алу белән алышына. Гарәп илләренең бу яна хакимиятләре секуляр ориентацияле, бөтен көчләрен үз хакимлекләрен саклау өчен сарыф итүче һәм милләтчелек хисләрен өммәт (бөтен мөселманнарнын бер милләттән һәм бер туганнар булуы-Э.А.) хисләреннән өстен куючы режимнар булалар. Бөтен гарәп илләренә дә хас булган бу мохит, сәяси аренада "Гарәп милли сугышы" төшенчәсен дөрес аңламаган рәвештә кирәгеннән артык пропагандаласа да (бу бигрәк тә Мисырдагы Жәмәл Габденнәсыйр вакытында еш күзәтелә), шул чордагы гарәп дөньясының кызганыч бер фрагментын бик ачык

күрсәтеп тора. Палестиналылар исә, искиткеч матур девиз кулланып, сезне коткарабыз, дип ялган вәгъдәләр бирү белән мавыккан бозык гарәп режимнарының аларны сионистлар кулыннан коткара алуларына өметләрен тәмам өзәләр.

Гел кабатлана торган "Азатлык юлы — берләшүлә" дигән коры девиз еш кына кайбер сәләтсез гарәп җитәкчеләренең "черегон саясәтләре"н каплау өчен бик уңайлы маска ролен үти. Ләкин берләшү генә азатлык китермәгәч, ачык итеп әйткәндә, 1958-1961 нче еллардагы Мисыр-Сирия Берләшүе унышсызлыкка очрагач һәм иң әһәмиятлесе — 1967 нче елгы Гарәп-Израил сугышы гарәпләргә катастрофик җинелу китереп, Палестинанын калган өлешен, Синайны һәм Голан Биеклеген (Golan Heights) сионистларга югалткач, халык массасы арасында төшенкелек һәм Өметсезлек рухы тагын да арта. Шуна өстәп, ислам хәрәкәтләре эшчәнлеге Мисыр җитәкчесе Жәмәл Габденнасыйр һәм анын тарафдарлары тарафыннан күп газаплар кичергән бу чорда национализм, радикализм кебек гарәп дөньясы өчен бөтенләй ят булган идеяләр бик кин таралырга өлгерә.

Әлбәттә, гарәп режимнары Палестинаны азат итәр өчен артык йомшак һәм өметсез булалар. Палестиналыларга ярдәм итәсе урында, алар алга таба үзләрен саклап калу өчен сионистлар берләшмәсе белән яшерен килешү эшчәнлеге алып баралар. Үз кабыкларын саклауны төп максат итеп куйган бу житәкчеләргә, моны ачык рәвештә публикага чыгарырга кыймау сәбәпле, Изге Палестинаны якларга ыргылган халыкның эчке дөньясы белән уйнап, әле киләчәктә "азатлык сугышы" булачак дип, халык массасын ышандырып яшәргә туры килә. Гарәп дөньясында шушы ялганга корылган сериаллар дәвам иткән чорда, яна яһуд дәүләте үзенең көчен ныгытырга өлгереп, бик кызу рәвештә Палестина өстенә тагын да жәелә бара.

Шулай ук гарәп режимнары, үз хакимлекләрен дәвам итү һәм ныгыту максатыннан, Палестинадагы каршылык хәрәкәтен мөмкин кадәр үз кулларында тотарга тырышалар. Бу "икейөзле" дәүләтләргә ике сәяси фронтта эшләргә туры килә. Беренчедән, гарәп режимнары, үз хакимлекләрен сионист үч алу атакаларыннан саклап калу һәм, гомумән, иминлектә калу өчен

Палестина каршылык көрәшен булдыра алганча үз контрольләре астына алалар, үз илләре чикләрендә хәрби һәм партизан операцияләрен булдырмый калу өчен кулларыннан килгәннен барысын да эшлиләр. Шунысын да әйтергә кирәк, бу сәясәт Израилгә чиктәш булган гарәп дәүләтләрендә бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Икенчедән, бу гарәп режимнары, сәяси отышка ирешү яисә эчке дистабилизация һәм илдә сәяси переворотлар булдырмый калу өчен, үз территорияләрендәге хәрби каршылыкларга ирек бирәләр. Гомумән алганда, ике фронтта эш алып баручы бу дәүләтләр Палестина халкының сионистларга каршы алып барган революцион көрәшенә соңгы илле ел буена зарар салалар. Шулай да Либнан, хакимлек элитасы революцион дулкынга каршы тора алмаслык дәрәҗәдә артык йомшак булу сәбәпле, бу гомуми кагыйдәдән чыгарылма булып тора, шуңа да 1967-1982 нче еллар аралыгында монда бик көчле каршылык көрәше базасы урнашкан була.

**Палестина милли көрәше:**

Көрәш юлында килеп туган каршылыклар һәм төрле чикләүләргә карамастан, Палестина халкы үз хокукларын даулау юлыннан баруын дәвам итә. Гомумән алганда, бу чордагы азатлык көрәше эшчәнлегенә түбәндәге үзенчәлекләр хас була:

- Палестина мәсьәләсе буенча дөньякүләм барган вакыйгаларга җавап буларак килеп туган шок хәленнән чыгып, яңа шартларга ияләшү, төп игътибарны яңа буынга белем бирү өлкәсенә юнәлтү.
- Милләтче, националист, шулай ук ислам партияләрен һәм башка сәяси группаларны бер фронтка берләштереп, бергәләп уртак дошманга каршы көрәш алып барырга әзерләнү.
- Палестина милләтен формалаштыру һәм халыкта милли хисләр ояту юнәлешендә, бу кайбер сул партияләр эшчәнлегенә каршылык тудыруга карамастан, актив эш алып бару. Нәтиҗәдә "Фәтәх" хәрәкәте һәм Палестина Азатлык Организациясе-ПАО- (инглиз телендәге варианты: Palestinian Liberation Organization-PLO) барлыкка килә.

• Палестиналыларның тормыш алып бару һәм ачтан үлмәү өчен эш эзләп Иордания елгасының көнчыгыш ярына һәм Хәлиж илләренә, бигрәк тә Согуд Гарәпстаны һәм Кувайтка массакүләм күчеп китүләре.

• Әл-Хаж Әмин әл-Хөсәйнинен лидер буларак роле акрынлап киму.

Палестинаның кайбер атаклы шәхесләре, 1949 нчы елның декабренда Жерико (Иерихон) конференциясенә җыелып, Иордания хөкүмәте инициативасы белән шушы илнең короле Габдуллаһ ибн әл-Хөсәйнне Палестина жиренең короле дип игълан итәләр. Бу исә сакланып калынган Палестина жиренең ин зур өлеше булган Көнбатыш Яр Буе (West Bank) территориясен (5878 кв.км, ягъни бөтен Палестина жиренең 21.77% ы) рәсми рәвештә Иорданиягә кушуга китерә, ә инде 1950 нче елның апрелендә Иордания елгасының Көнбатыш һәм Көнчыгыш Яр Буе территорияләрен бергә кушу турындагы декларация кабул ителә. Мисыр хөкүмәте исә, үз чиратында, сионист оккупациясеннән сакланып калынган Газа Полосасын (Gaza Strip) үзенең административ контроле астына ала (363 кв.км, бөтен Палестина жиренең 1.34% ы).

Әл-Хаж Әмин әл-Хөсәйни һәм шулай ук анын Югары Гарәп Идарә Советындагы коллегалары Палестинаның Көнбатыш Яр Буе һәм Газа өлешләрендә яшәүдән вә сәяси активлык алып барудан кискен рәвештә тыелалар. Әл-Хаж Әмин үзе Мисырда тоткын хәлендә яшәп, 1958 нче елда Либнанга китәргә мәжбүр була, аның "Совет"ы һәм "Хөкүмәте исә бернинди тәэсир көченә ия булмаган күрсәтмә әсбап булып кала. Шул рәвешле, әл-Хаж Әмин җитәкчелегендәге Палестина хөкүмәте, 1952 нче елдан башлап, Гарәп Лигасы өчен символик әсбап ролен ути башлый. Әл-Хаж Әминнен Палестина азатлык көрәшендәге гомуми роленә килгәндә исә, ул төрлечә бәяләнә. Күпләр аны 1950 нче еллар уртасына кадәр җиңелү белмәгән Палестина лидеры буларак алкышласа, кайберәүләр барыбер, Палестинаны югалту фаҗигасендә турыдан-туры аны гаепли. Турысын әйткәндә, бу шәхес ихлас күңелле һәм тәвәккәл була, нәрсә әйтсәк тә, Палестина милли көрәшендә утыз елдан артык әйдәп баручы житәкче ролен нәкъ менә шушы легендар шәхес башкара.

1949-1954 нче еллар аралыгында Мисыр һәм Иордания территорияләрендә чагыштырмача ирекле рәвештә эш алып бара алган "Ихвән әл-Мөслимин" хәрәкәте, 1948 нче елгы сугышта биргән корбаннары һәм мактауга лаек Ислам Милли Программасы сәбәпле, Палестинаның Көнбатыш Яр Буе һәм Газа өлешендә зур популярлык казана. Халифат байрагын күтәргән "Хизб Тахрир әл-Исләми" партиясе дә илленче еллар уртасында Иорданиядә бик көчле тәэсиргә ия була. Коммунист партияләренең студент һәм профессионалларны үзләренә җәлеп итү өчен купшы бизәкле лозунглар куллануылары, бигрәк тә идарә итүче элитаны сатлык жан, агент итеп күрсәтүдәге осталыклары да ислам хәрәкәте үсешенә артык зыян сала алмый. Ләкин исламчылар" Ихвән әл-Мөслимин"гә каршы Габденнасыйр алып барган үтерү һәм яла ягу кампанияләреннән күп җәфалар чигәләр. Шуна да "Ихвән әл-Мөслимин" әгъзалары бөтен энергияләрен көрәш юлына түгел, бәлки үзләренең жаннарын саклау юлына исраф итәргә һәм үзләре күтәргән теп лозунглардан вакытлыча баш тартырга мәжбүр булалар. Килеп туган авыр шартларга карамастан, исламчылар Палестина халкы арасында илленче еллар азагына кадәр популяр булып калалар, моны Мисырда урын алган Палестина Студентлары Ассоциясендә исламчыларның 1957 нче елга кадәр өстенлек итүләре дә ачык күрсәтеп тора, про-"Ихвән әл-Мөслимин" Ясир Арафат исә бу организациянең президенты булып торган.

Палестина каршылык көрәше бу авыр чорда, котылгысыз рәвештә, яралгы хәлендә була. Илленче елларның беренче яртысында ул күпкырлы, ләкин бер-берсе белән бөтенләй бәйләнештә булмаган күп сандагы кечкенә группалар формасын ала, шулай ук тышкы дөньядан изоляцияләнгән хәлдә булуын дәвам итә. Гомумән алганда, бу бәләкәй группалар Палестина жирен кире кайтарып алу өчен һөҗүм итү һәм атакалардан качу, яисә сионистларга каршы турыдан-туры кыю бәләкәй ударлар ясау белән мәшгуль була. "Ихван әл-Мөслимин" Газа территориясендә яшерен хәрби организация барлыкка китереп, бу оешма эн-Нәкаб бәдәвиләре белән берлектә һәм Газа Полосасында көн күрүче Мисыр армиясе офицеры Габдел Меним Габдеррәуфнең турыдан-туры ярдәме белән берничә хәрби операцияләр оештыруга ирешә. Кайбер дәлилләр буенча, 1954

нче елның 17 нче мартында булыш узган Израил автобусына һөҗүм итү нәкъ менә шушы оешма планы буенча эшләнә. Бир Шееба янында оештырылган бу операциядә унбер сионист үтерелгән була.[69]

Үзләренә каршы оештырылган бу һөҗүмнәргә сионистлар Көнбатыш Яр Буе һәм Газа территорияләренең икесендә дә Палестина халкыннан бик рәхимсез һәм кансыз үч алулар белән җавап бирәләр. Алар берничә тапкыр гаепсез кешеләрне массакүләм үтерү оештыралар, мәсәлән 1953 нче елның 14-15 нче октябрендә Кыйбья массакүләм үч алу вакытында 67 тыныч тормыш гражданының каны коела,[70] аннан соң 1955 нче елның 28 нче февралендә Газада 39 кеше гаепсезгә үтерелә, 33 кеше яралана. Бу трагедиядән соң Мисыр хөкүмәте, халыкның көчле басымы астында, Палестинада чикләнгән күләмдә көрәш алып барырга рөхсәт итәргә мәҗбүр булып, бу эш белән җитәкчелек итүне легендар Мисыр офицеры Мостафа Хафизга тапшыра. 1955-1956 нчы еллар аралыгында сионистларга каршы оештырылган тагын берничә зур һәм кечкенә операцияләр уңышлы тәмамлана.[71]

1956 нчы елның 29 нчы октябрендә Өчлек Союзы (Британия-Франция-Израил) Мисырга каршы үзенең агрессив һөҗүмен башлап җибәрә. Бу операциядә сионистлар түбәндәге максатларга ирешүне күз алдында тотып катнашалар: Газа Полосасындагы Палестина революцион каршылыгын тар-мар итәргә, шулай ук Израил теплоходларына Кызыл диңгездә йөрергә юл ачарга һәм ниһаять, үзләренең империалистик киңәю планнарын дәвам итәргә. Британия исә, үз чиратында, Нәсыйрның кыю рәвештә Суез каналын үз милләте милкенә әверелдерүенә чик куеп, озак еллар буе бары тик Британиянеке генә булып торган бу су юлына яңадан бердәнбер хуҗа булырга тели. Ә Франция исә, Алжир революциясенә ярдәм күрсәткән Мисырдан, чын мәгънәсендә үч алырга ашкына. Бу Өчлек Союзы һөҗүме нәтиҗәсендә Мисырның һава һәм диңгез портлары Британия һәм Франция тарафыннан җимерелә, ә Израил исә Газа Полосасы һәм Синайны тиз арада басып ала. Әлбәттә, бу вакыйгалар Мисырның хәрби көчләре һәм сәяси җитәкчелегенең ни дәрәҗәдә зәгыйфь хәлдә булуын бик ачык күрсәтеп тора.

Шуңа өстәп, хөкүмәт контроле астында булган информация чаралары бу скандалны бөтенләй башка яктан яктыртып, халык оцияләре белән бик оста уйныйлар. Басып алучылар Америка басымы астында 1957 нче елның 6 нчы мартында илдән чыгып китәргә мәҗбүр ителгәч, Насыйр бу сугышта җиңелгән түгел, бәлки нәкъ менә җиңүче итеп күрсәтелеп, бу шәхес тагын бер тапкыр ялганга корылган алкышларга күмелә.

**"Фәтәх" хәрәкәте барлыкка килү:**

яктан милли тышкы Бу чорда гарәп илләрендә, бигрәк тә Мисыр һәм Газа территориясендә ислам хәрәкәтләрен эзәрлекләү һәм аларны юкка чыгару өчен көрәш алып бару киң урын ала. Ин әһәмиятлесе, бу тискәре күренеш уңай нәтиҗәләр биреп, Палестина яшьләре илләрен азат итү өчен хакыйкый һәм житди юллар эзли башлыйлар. Төп игътибарны сакчыл эш итү, халыкка белем һәм дини тәрбия бирүгә юнәлткән бу чорда, бер төркем кабыкка төренгән, ләкин хәрбиләр чынбарлыкта исә эчке яктан исламча булган хәрби оешма төзергә карар кылалар; бу юнәлештәге организациянең, әлбәттә, яшьләр һам гомуман, бетен саяси катламнар арасында да киңкүләм яклау табарга сәләтле булачак икәнлеге бик ачык аңлашыла. Нәтиҗәдә, 1957 нче елда Күвәйтта "Фәтәх" (Палестина Азатлык Хәрәкәте) барлыкка килә. Алжирдагы күтәрелеш тәжрибәсенә нигезләнгән бу хәрәкәтне төзү идеясе “әл-Ихвән"нен Газа Полосасындагы кайбер әгъзалары тарафыннан да бик жылы каршы алынган була. Мәсәлән, "әл-Ихвән"ле Хәлил әл-Вазир (Әбу Жиһад) "Фотох"не оештыручылар арасында булып, алдагы утыз ел буена "Фәтәх" тә әйдәп баручыларның берсе булып тора. Нигездә ул, "әл- Ихвән"нең Газадагы Югары житәкчелегенә үзенең “әл-Фәтәх"не оештыруы хакында тәкъдим тапшырган булып, бу идея "әл- Ихвәннәрдә кызыксыну уятмаган була. Шуңа да карамастан, әл- Вазир үзенең проектын тормышка ашырырга чынлап торып алына, алга таба "әл-Ихвән" хәрәкәтенең Сәгъд әл-Мезәййин, Галиб әл-Вазир, Сәлим әз-Зәэнүн, Сәләх Халәф, Әсгад эс-Сәфтәви, Мөхәммәд Йосыф эн-Нәжжар, Кәмәл Удвән, Рафикъ эн-Нәтшәһ, Габделфәттах Хәмед һәм Йосыф Әмираһ кебек атаклы әгъзаләре дә "әл-Фәтөх"кә кушылып, җитәкчелек постлары постларын үз кулларына алалар. 1963 нче елга кадәр "әл-

Фотох"сафлары "әл-Ихвән"леләр хисабына тулыланып торса да, алга таба, бигрәк тә "ал-Ихван" үз әгъзаләренә берьюлы ике оешма члены булып саналуны тыйгач, "әл-Фәтәх" үзенең ишекләрен башка хәрәкәт әһелләрена да ача.[72] Менә шушы вакыттан башлап "әл-Фәтәх" секуляр һәм милли ориентацияле хәрәкәткә әверелә һәм бүгенге көнгә кадәр шушы юнәлештә эш алып баруын дәвам итә. 1965 нче елның беренче январенда "әл- Фәтәх" нең хәрби канаты булган “әл-Гасыйфәһ" (Давыл, Шторм) үзенең хәрби каршылык көрәшен башлап җибәреп, шул көннән алып 1967 нен Июнь сугышына кадәрге чорда сионистларга каршы ике йөзләп хәрби операция оештыруга ирешә.[73]

50 нче еллар уртасында барлыкка килгән икенче бер организация – "Гарәп Милли Хәрәкәте"н ("әл-Каумийййүн ал- Гарәп") нигезләүчеләрнең күбесе Бәйрутта урнашкан Америка университеты студентлары булалар, Джордж Хәбәш исә алар арасында башлап йөрүчеләрдән санала. Бу хәрәкәт "Гарәпләр Берлеге" һәм "Палестина Азатлыгы" идеяләрен күтәра, Насыйр сәясәтен киң күләмдә яклый, 1958 нче елда исә Палестина Комитетын оештыруга ирешә. Ә инде Мисыр-Сирия Берләшүе унышсызлыкка ирешкәч, токтан кыйбласын тамырдан үзгәртеп, социалистик көрәш идеяләрен кабул итә. 1964 нче елның маенда "Палестинаны азат итү буенча милли хәрәкәт" һәм аның хәрби канаты булган "Шәбаб әс-Саэр" ("Үч алучы яшь буын") хәрәкәтен оештыра. Бу хәрәкәт 1966 нчы елда марксизм идеяләрен кабул итеп, 1967 нче елның декабрендa башка көчләр белән берлектә "Палестина азатлыгы өчен Халык Фронты"н оештыруга ирешә. [74]

**Палестина Азатлык Организациясе (ПАО) төзелү:**

Палестинада яшерен хәрби хәрәкәтнең һәм сәяси актив- лыкның кызу темплар белән көннән-көн үсә баруы күрше гарәп режимнарында көчле курку уята; дөрестән дә, әгәр дә Палес- тинадагы активлык югары ноктага җитәргә өлгерә икән, бу алга таба сионистларның йомшак гарәп хөкүмәтләренә һөҗүме белән тәмамлануга китерергә мөмкин дигән сүз иде. Гарәп илләре житәкчеләре, бигрәк тә Мисырдагы Нәсыйр хакимияте, үзләренә янаган бу куркынычтан саклану максатында рәсми булган Палестина хөкүмәте төзеп, аның бөтен эшчәнлеген үз контрольләре

астына алырга карар кылалар. Нәтиҗәдә 1959 нчы елны Гарәп Лигасы Палестиналыларны аларның рәсми вәкилләре булачак бер идарәгә берләштерү турында карар кабул итә. Ләкин бу карар көткән нәтиҗәләрне бирми, шулай да Гарәп Лигасында Па- лестинаның рәсми вәкиле булып торучы Әхмәд Хилми Габдел- бәкыйның 1963 нче елда вафат булуы белән вакыйгалар төптән үзгәрә.

Әхмәд Хилми урынына Нәсыйрның турыдан-туры ярдәме белән Әхмәд әш-Шукәйри сайлана, ул 1964 нче елның 13 нче гыйнварында Каһира Бөтенгарәп конференциясендә Палестина хал- кына азатлык һәм үзидарә ирегe өчен көрәшергә ирек бирүләрен сорап доклад белән чыга. Төрле интригалар һәм Лиганың үз эчендәге төрле каршылыклы интереслар белән яхшы таныш булган әш-Шүкәйри, ниһаять, Мисырның актив ярдәме белән Палестина Азатлык Организациясен (ПАО; Palestinian Liberation Organization-PLO) төзүгә ирешә. 1964 нче елның 28 нче маенда Иордания короле Хөсәен ярдәме белән Иерусалемда Беренче Палестина Милли Конгрессы булып уза. Бу мәжлестә 422 Палестиналы вәкил җыелып, алар әш-Шукәйри президентлыгы астында ПАО ны рәсми рәвештә оештыруга ирешәләр. Бу организация алга таба Палестина милли декларациясе (хартия) кабул итеп, Бөтен Палестина җирен азат итү өчен көрәш алып баруны яклаучы һәм бу изге җирнең бер генә кисәген дә башкаларга бирүдән баш тартучы идеяләрне яктырткан хәрәкәткә әйләнә. Алга таба "Палестина Азатлык Армиясе" исеме астында үзенең яңа хәрби канатын формалаштыруга ирешә, яхшы планлаштырылган информация чаралары аркылы үзен рекламалый. Гомумән алганда, Палестина халкы ПАОны бик җылы каршы ала, аңа үзләренең илләрен азат итүдә һәм милли ватаннарын булдыруда умыртка сөяге ролен үтәүче итеп карый. Ә инде "Фәтәх" хәрәкәтенең популярлык мәсьәләсенә килгәндә, аның яшерен мотивлары һәм кабул иткән максатларына ирешүгә мөмкинчелеге халык арасында шик астына алынган була.[75]

**1967 нче елгы Июнь сугышы һәм аның нәтиҗәләре:**

Жәмәл Габденнәсыйрның вакыт-вакыт хәлләрне кискен- ләштерергә ярата торган гадәте була. 1967 нче елның май азагында

исә ул хәлләрне бөтенләй сонгы чиккә житкерә: Кызыл дингездәге Тиран бугазын яба, шуңа өстәп, БМО тынычлык сакчыларының Мисыр чигеннән китүләрен таләп итә. Гарәп хөкүмәтләре бу "озак көтелгән" Палестинаны азат итү көрәшенә үзләренең әзерлекләрен белдерәләр. 5 нче июньдә исә Израил көчләре Мисыр, Иордания һәм Сирия һава көчләренә көтелмәгән һөҗүм ясап, аларны бөтенләй гамәлдән чыгара. Шулай итеп, Июнь сугышы башланып китә. Сионистлар алты көн эчендә Палестинанын оккупацияләнүдән сакланып калынган өлешен (Көнбатыш Яр Буе — 5878 кв.км һәм Газа өлеше — 363 кв.км), шулай ук Мисырның Синай сахрасын (61198 кв.км) һәм Сирия Голан Биеклеген (1150 кв.км) басып алалар. Мисыр коралларының һәм хәрби көчләренең 80% ы җимерелә, ун мен Мисырлы, алты мең туксан дүрт Иорданияле һәм бер мен Сирияле үтерелә, өч йөз утыз мен Палестиналы үз илләреннән куып чыгарыла. Иң аянычы: сионист солдатлар, Иерусалем территориясе һәм әл-Әкъса мәчетенә кергәч, истерика белән: "Мөхәммәд дине тарихта калды..", "Мөхәммәд үлде... үзеннән соң хатын-кызлар гына калдырды..", "Хәйбәр өчен үчебез!.." кебек сүзләр кычкыралар... Бу аңлатып булмаслык зур фаҗига гарәп массаларын танга калдыра. Унтугыз ел буе хөкүмәтләре тарафыннан барлыкка китерелгән иллюзияләр белән яшәгән халык, ниһаять, идарә элитасының ни дәрәҗәдә куркак, ике Йөзле булуын һәм ялганчылыгын аңлый, ә инде Җәмәл Габденнәсыйрның популярлыгы исә эреп парга әйләнә. Шул рәвешле, бу вакыйгалардан гаҗиз калган гарәп массалары үз хөкүмәтләренә ышанычларын бөтенләй югалталар.

Палестина халкы азатлык көрәше инициативасын бик тиз арада үз кулына алырга өлгерә, Палестинада милли хәрәкәтләр прогрессив рәвештә үсеп китә. Ләкин бу вакыйгалар арасында ин кызганычы шул була — гарәп режимнары да, шул исәптән ПАО да алга таба көрәш юлында бөтен игътибарларын 1967 нче елда басып алынган Палестина җирен азат итүгә бирәләр (монда сүз Көнбатыш Яр Буе һәм Газа өлеше, ягъни бөтен Палестина җиренең 23% ы хакында гына бара), а инде 1948 нче елда сионист басып алучы- ларына югалтылган Палестина җире хакында бөтенләй дәшмиләр. Ә бит төп көрәш һәм халык хәрәкәтләре нәкъ менә шушы җирне азат итү өчен башланган булып, бу изге җир хакына күпме тырышлык сарыф ителә һәм шәһидләрнең күпме каны коела...

# ДУРТЕНЧЕ ФАСЫЛ

## Палестина мәсьәләсе 1967-1987 нче еллар аралыгында

### Палестина милли үзаңы (самосознание) барлыкка килү:

Сугыштан соңгы елларда халык арасында киң таралган ризасызлык, төшенкелек һәм апатия хисләренең тагын да ныграк үсешеннән саклану өчен гарәп режимнары халыкка партизан хәрәкәте башлап җибәрүне рөхсәт итәргә мәҗбүр булалар, алга таба бу ирекле көрәш эшчәнлеге Иордания һәм Либнанда бик югары дәрәҗәгә җитүгә ирешә. "Фәтәх" житәкчелегендәге партизан организацияләре Палестина азатлык көрәшендә моңарчы ПАО үтәп килгән җитәкчелек һәм лидерлык вазифасын үз кулларына алып, сионистларга каршы чын мәгънәсендә кораллы каршылык көрәше башлап җибәрәләр. Ясир Арафат житәкчелегендәге ПАО ның азатлык көрәшендә алга таба торткан урынына килгәндә исә, бу организация 1974 нче елның октябренда Рабатта булып узган конференциядә гарәп дәүләтләре тарафыннан Палестина халкының бердәнбер рәсми житәкчелеге итеп танылa. Шушы ук елның ноябрендә исә ПАО икенче сәяси жиңүгә ирешә: Ясир Арафатның БМО Гомуми Ассамблеясына мөрәҗәгате организациягә "БМОның күзәтүчесе" статусы бирелү белән тәмамлана. Үткәндә булганнардан аермалы буларак, БМО хәзер Палестина мәсьәләсен бары тик качаклар проблемасы итеп кенә карап калмый, бәлки 1969 нчы елның декабреннән башлап, Палестинаны **МИЛЛӘТ** һәм **ДӘҮЛӘТ** буларак таный башлый. Мәсәлән, җитмешенче елларда бу оешма Палестина халкының үзидарәгә хакларын яклаган берничә резолюция кабул итә, аларның кануни хокукларына ирешү өчен көрәшләрен — хәтта төрле средстволар, шул исәптән кораллы көрәш кулланып булсын — яклый.

1974 нче елдан башлап, Палестина проблемасы БМОның көн тәртибендә мөстәкыйль тема буларак еш кабатлана башлый. 1975 нче елның 22 нче ноябрендә чыккан 3236 нчы номерлы "Палестина халкының хокуклары" исемле резолюциядә түбәндәгеләр әйтелә:

**Палестина халкынын:**

**— тышкы тәэсирләрдән һәм катнашулардан азат бул- ган рәвештә үзидарәгә,**

**— мөстәкыйльлеккә һәм милли суверин нетитка ирешү өчен көрәшерга,**

**— туган җирләренә әйләнеп кайтырга,**

**— БМО конституциясенә туры китереп төрле чаралар белән үз хокукларын саклау өчен көрәшергә — ХАКЛАРЫ БАР!!!**

Югарыда телгә алынган бу резолюция һәм шулай ук ана аваздаш булып яңгыраган башкалары да Израилне бик ныклап почмакка кыса, 1975 нче елда БМО сионизмны хәтта "апартеид", ягъни расачылык дип атауга кадәр барып жита. АКШ бу резолюцияләргә вето куярга ирешсә дә,[76] Палестина коралллы каршылыгы бөтендөнья җәмгыятен үзләренә игътибар иттерүгә һәм Палестина тавышына колак салырга тиешлеккә инандыруга ирешә. Әлбәттә, әгәр дә хыянәтләр сәбәпле каршылык көрәшенә төрле яктан тоткарлыклар тумаса һәм шулай ук гарәп-мөселман дөньясы шул дәрәжәгә җитеп таркалган булмаса – бу халыкара комитетның мактауга лаеклы ярдәме Палестина мәсьәләсен уңай якка хәл итүгә алга таба тагын да эффективрак файда китерә алган булыр иде.

Палестиналылар, шулай итеп, 1967-1987 нче еллар аралыгында халыкара һәм региональ фронтларда әһәмиятле сәяси жиңүләргә ирешә алалар. Шуна өстәп, бу периоднын беренче яртысында күзөтелгән гарәпләрнең нәтиҗәле ярдәме партизан хәрәкәтләренең нык үсеш алуына сәбәп булып торса, икенче яртыда исә бу ярдәм бик нык кимү сәбәпле, ирешелгән сәяси жиңүләрнең саны да азаю күзәтелә.

**Палестина коралллы көрәше:**

1967-1970 нче еллар аралыгындагы өч ел вакыт Палестина коралллы каршылык көрәше өчен алтын чор булып тора: басып алынган Палестина жире белән чиктеш булган Иорданиянең (360 км) һәм Либнанның (79 км) чикләре ирекле халык көрәше алып

бару өчен ачыла. 1968 нче елның 21 нче мартында урын алган Карама сугышы исә сионистларга бик кыйммәткә төшә, ә инде Палестина каршылык көрәше өчен бу вакыйга бөек хәрби һәм мәгънәви җиңү булып тора. Бу җиңү белән рухланган күпләр ирекле рәвештә армия сафларына кушылырга ашыга. Айлык партизан операцияләренең үсешенә игътибар итсәк, 1967 нче елда бер айга 12 хәрби операция туры килсә, 1968 нче елда исә бу сан 52 гә күтәрелә, 1969 нчы елда бер айга 199 операция туры килә, ә 1970 нче елда исә бу күрсәткеч 279 га җитә.[77]

Ләкин Палестина каршылык көрәше 1970 нче елның сентябрендә һәм 1971 нче елның июлендә Иордания армиясе белән ике арада булган канлы бәрелештә җинелүгә дучар була. Палестина каршылык көрәше Иордания чикләрендә эш алып барудан тыелып, бу җирләрдән бөтенләй куып чыгарыла, шул рәвешле ул алга таба көрәш алып барырга мөмкинчелек бирүче унай шартлардан бөтенләй мәхрүм кала, нәтиҗәдә каршылык көрәше эшчәнлегенә зур зыян килә. Шуна да карамастан, 1969 нчы елгы Каһира Килешүендә Палестина каршылык хәрәкәтенә Либнан чикләрендә эш алып барырга ирек бирелә, ләкин Либнандагы озакка сузылган гражданнар сугышы нәтиҗәсендә аңа көрәш алып барырга авырлыклар туа. 1975 нче елны исә Либнан христиан маронитларының әл-Кәтәиб партиясе һәм аларның союздашлары илдә Палестиналылар булуга кискен каршы чыгып, аларга каршы көрәш алып бара башлыйлар. Бу сектага каршы озакка сузылган көрәш алып бару, шуна өстәп, Әмәл хәрәкәте тарафыннан ике елдан артык (1985-1987) блокада хәлендә яшәргә мәҗбүр булу һәм эчке проблемалар Палестина каршылык көрәше сафларының хәлен икеләйтә авырайта. Нәтиҗәдә сионистларга каршы көрәш алып баруга теп игътибарны бирү бөтенләй авырая. Эмма каршылык көрәшенен эшен сонгы чиккә җиткереп начарландырган хәл Мисыр һәм Сирия чикләренең Палестина каршылык көрәше өчен ябылуы була. Менә шуңа күрә дә бу периодның икенче яртысында партизан хәрәкәтен илнең тышкы ягыннан алып бару бөтенләй мөмкин булмаган эшкә әйләнә.

Мәсьәләгә икенче яктан Якын килгәндә, сионистлар Палестина партизан хәрәкәтенә ярдәм иткән яисә аларны яшереп

тоткан Иордания һәм Либнан кешеләренә ка Сионистлар оннорар карата варварларча истлар бер гаепсез тыныч фабрика, күпер, электр руктураларны кылуда жимеру, инфраструктураларны рәхимсез чар аралар кулланалар. тормыш кешел станцияләре кебек пеләрен рәхимсез үтерү. яисә унышларны яндыру кеб жинаятьл ьләр кылудан бер дә аралыгында сионистлар анияләре рәше пер. чирканмыйлар. 1970-1972 нче еллар аралыгъ Либнанның әл-Әркуб районында үч алу кампані оештыралар, ә 1973 нче елда монда Палестина каршылык кере хәрәкәтендә башлап йөргән өч житәкчене үтерүгә ирешәләр 1978 нче елның мартында исә, Либнаннын эченә үтеп кереп, Көньяк Либнан территориясенең армия житәкчесе Сәэд Хәддал белән якын хезмәттәшлек оештыруга ирешәләр һәм аның белән берлектә Либнан территориясендә "иминлек зонасы" төзиләр. Бу Либнан армиясен финанслау һәм хәрби яктан өйрәтүне сионистлар уз өсләренә алып, алга таба аны бөтенләй үз контрольләре астына алуга ирешәләр.

Палестина каршылык көрәше 1980 нче елның августында булып узган әш-Шәкыйфь сугышында югары дәрәҗәдә заманча коралланган сионист армиясен жинүгә ирешә, ләкин 1982 нче елның июнендә икенче зур сандагы һәм тагын да рәхимсезрәк Израил дулкыны көньяк Либнанга үтеп кереп, тиз арада Бәйрутка кадәр барып житә. Ләкин бу дулкын Палестина каршылык хәрәкәте һәм аларнын союздашларынын сиксән көнгә сузылган кыю каршылыкларыннан соң шушы урында туктап калырга мәжбүр була. Шул заманның хәлсез гарәп-мөселман дөньясы һам, гомумән, бөтен кешелек җәмгыяте бу трагик үсешләр алдында битараф калып, мазлумнарга ярдәм кулы сузмыйча, бары тик читтән күзәтүче тамашачы ролен генә үтәүләрен дәвам итәләр. Сионистлар, ниһаять, Палестина каршылык көрәшенең матди-техник тәэминатен тар-мар итүгә, шулай ук "утны сүдеру" килешүе сәбәпле, алты мен сандагы Палестина сугышчысын мәжбүри рәвештә Йемен, Тунис, Алжир һәм Судандагы ерак лагерьларга жибәрүгә ирешәләр. Шушы вакыттан алып сионистлар тышкы Палестина каршылык көрәшен контрольгә алалар, ләкин шулай да аны бөтенләй юкка чыгаруга ирешә алмыйлар.

Алда санап үткән бу вакыйгалар нәтиҗәсендә, тышкы партизан хәрәкәте сиксәненче елларда бик көчсезләнә, шулай да истә калырдай һәм күпләрнен игътибарын үзенә җәлеп иткән берничә хәрби операция булдыруга ирешә. Мәсәлән, бу урында "Фатах" хәрәкәте оештырган ике һөҗүмне телгә алып киту бик урынлы булыр иде: аларның беренчесе Тил-Авивта 1975 нче елның 6 нчы мартында оештырылган Савой операциясе булса, икенчесе исә 1978 нче елның 11 нче мартында оештырылган Камал Удвән операциясе була. Аларның беренчесендә 50 сионист үтерелеп, тагын 50 яраланса, икенче һөҗүмдә исә 37 сионист үтерелеп, 82 яһуд яралана. Шулай ук "Палестинаны Азат итү өчен Халыклар Фронты" житмешенче елларда аэропортларга атака ясауда һәм самолётларны кулга төшерүдә бик актив була, мәсәлән, 1972 нче елның 30 нчы маенда алар тарафыннан Лод (Лудда) аэропортына атака оештырылып, 31 сионист үтерелә һәм 80е яралана. Бу оешманың Генераль Штабы исә 1974 нче елның 11 нче апрелендә булган әл-Халисәһ операциясе[78] һәм шулай ук 1987 нче елның ноябрендәге "аэроплан операциясе" авторлыгы жаваплылыгын үз өстенә ала.

1982 нче елдан башлап, ПАОның хәрби көрәштәге активлыгы бик сүлпәнәя, бигрәк тә 1983-1987 нче авыр еллар аның сафларын сизелерлек көчсезләндерә, шулай ук аның гарәп илләренә булган сәяси тәэсире дә бик нык кими. Нәтиҗәдә бу хәрәкәт акрынлап тыныч тормыш идеясен күтәрә башлый. Шулай итеп, бу организация үзенең асыл һәм нигез девизы булган "ботен Палестинаны корал кулланып азат иту" идеясеннән кире кайта. Бу үзгәрешләрнең беренче очкыннары, фактта, алтмышынчы еллар ахырында ук күренә башлый. Мәсәлән, бу чорда ПАО халыкны гарәп һәм яһудләр өчен уртак булган бер секуляр дәүләт төзергә чакыра башлый. Бу чакыру, әлбәттә, ПАОның бөтен яһүдләрне кайсы илдән килгән булсалар, яңадан шунда кайтарырга дигән элеккеге таләбеннән ваз кичүен бик ачык күрсәтеп тора. 1974 нче елда исә ПАО Палестинаны азат итү буенча "азлап-азлап" (шаг за шагом) сәясәтен куллану турында ун пункттан торган программа кабул итеп, Палестина дәүләтен теләсә кайсы азат ителгән яисә сакланып калынган элеккеге Палестина жирендә төзергә тәкъдим итә. Организация 1982 нче елда төзегән Фәз-Гарәп тынычлык проектына килгәндә

исә, ул бу илнен жирендә яшәгән һәркемгә тыныч яшәргә хак биро, шулай итеп, бу документ ПАОның 1948 нче елда Палестина жирләрендә төзелгән Сионист берләшмәсен тануын ачык күрсәтеп тора. Алга таба ПАО саяси тыныч тормышка күчү проектын төзүгә рәсми рәвештә керешергә ризалык бира.[79]

**Гарэн хөкүмәтләре һәм Палестина мәсьәләсе:**

ПАОның халыкара аренада Палестина миллотенен бердәнбер законлы вәкиле итеп танылуы гарәп режимнары өчен бик кулай була. Шушы вакыттан башлап, гарәп хөкүмәтләре ПАОны Палестиналыларның хокукларына ирешүдә эш алып барырга тиешле бердәнбер жаваплы организация итеп күрсәтә башлыйлар. Шулай итеп, алар Палестиналыларга булышуда тиеш булган хәрби жаваплылыкны һәм сионистлар белән турыдан- туры каршылык алып бару вазифасын үзләренең җилкәләреннән төшерәләр. Алга таба гарәп дәүләтләре, бигрәк тә 1973 нче елдан сон, үзләренең Палестинаны азат итү өчен көрәш юлындагы жаваплылыклары чикләнгән булуга басым ясап, аны бары тик ПАОга саяси һәм экономик яктан ярдәм итүгә генә кайтарып калдыралар һәм соңрак, 1980 нче елдан алып, нефтьнең бәясе кискен төшү сәбәпле, экономик ярдәм итү дә кискен рәвештә кими. Бу периодта ПАО үзе дә Иордания, Либнан, Сирия һәм Мисыр гарәп хөкүмәтләре белән ике арадагы каршылыклар һәм тоткан кыйбладагы аермалыклар нәтиҗәсендә бик көчсезләнә. 1983 нче елда Ясир Арафат Сириядән чыгарыла, шул ук елда аның тарафдарларын да төньяк Либнаннан, төбәп әйткәндә "Нахр әл-Бәрид" һәм “әл-Бәдәви" лагерьларыннан чыгарырга тырышалар. Мисыр житәкчесе Әнвәр Садатнын 1978 нче елның сентябренда Кэмп-Дэвид Тынычлык килешүенә кул куюы исә гарәп илләре арасында иң көчле булган Мисырның ПАОга ярдәмен бөтенләй туктатуын бик ачык исбатлап тора. Шулай ук икенче көчле гарәп иле Гыйрак та, Иран белән сугыш (1980-1988) алып бару сәбәпле, Палестина көрәшенә бернинди дә хакыйкый ярдәм күрсәтә алмый.

Билгеле булганча, бу периодның башлангыч чорында гарәп илләре Палестинадагы каршылык көрәшен дәвам итәргә дип карар чыгарган булалар. 1967 нче елдагы Нәкбәһтен (бөек

катастрофа) сон гарәп илләре җитәкчеләре шушы ук елның июль аенда Хартум Конференциясенә җыелып, өч "**ЮК**" кабул иткән булалар: тынычлыкка — **ЮК**, килешүләргә — **ЮК**, сио- нистларга баш бирергә — **ЮК**. Шушы карар нигезендә Сирия һәм Мисыр хөкүмәтләре сионистларга каршы үзләре өчен бик кыйммәткә төшкән сугыш алып баралар. 1973 нче елның 6 нчы октябрендә Өченче гарәп-Израил сугышы кабынып китә. Сугышның башында Сирия һәм Мисыр кебек көчле гарәп илләре кайбер кечкенә җиңүләргә дә ирешәләр: Мисырлылар Суез каналының көнчыгыш ярындагы Синай сахрасына кадәрге өлешне ала алсалар, Сирия армиясе исә Голан Биеклегенә үтеп керүгә ирешә. Ләкин сионистлар Американың һава юллары хәрби көчләренең аларга булган ныклы ярдәме нәтиҗәсендә сугыштагы инициативаны тиз арада үз кулларына алуга ирешәләр: Суез каналының көнбатыш ярында урнашкан әд- Дифрисвәр янында Мисыр армиясен тар-мар итүгә ирешәләр. алга таба Голан Биеклегендә вакытлыча югалткан территорияләрне һәм тагын өстәмә утыз тугыз башка Сирия авылларын да басып алалар. Шулай да бу сугыш, гомумән алганда, гарәп армияләрендә бераз алга китеш булу һәм сионистларның октябрьда зур югалтулар кичерүләре сәбәпле, инде халык арасында нык урнашырга өлгергән "җинелү белмәс Израил армиясе" хакындагы мифның юкка чыгуы белән тәмамлана.

Гарәп армияләренең бу октябрь аенда ирешкән чикләнгән уңышлары, шулай да, гарәп медиасында зур җину итеп кабартылып бирелә һәм Мисыр, Сирия җитәкчеләре, бигрәк тә Садат милли геройлар итеп сурәтләнә. Иң мөһиме, бу чикләнгән уңышлар Садатның үзе тарафыннан да бик яхшы кулланыла, ул Мисыр хөкүмәте Палестина өчен тиеш булганның барысын да эшләде дип исбатлый һәм шуннан соң тынычлык сәясәте идеясен күтәрә башлый. Садат үзенең 1977 нче елның ноябрендә Израилгә ясаган сюрприз визиты белән бөтен гарәп-мөселман дөньясын шаккатыра. Визит нәтиҗәсендә 1978 нче елда Мисыр һәм Израил арасында Кэмп-Дэвид Тынычлык килешүенә кул куела. Бу килешү буенча ике ил түбәндәге нәтиҗәләргә килә: Мисыр сионист берләшмәсе белән сугышуын туктатачак һәм Израил шуның бәрабәренә Синай сахрасын кире Мисырга

бирәчәк. Бу чордагы гарәп илләре арасында иң көчлесе булган Мисырның шушы рәвешле сионистларга каршы көрәштән баш тартып сугыш кырыннан чыгуы киләчәктә Израил белән хәрби көрәшнең нәтиҗәле булачагына сонгы өметләрне дә сүндерә.

Бу чорда гарәп дөньясы сәясәтендә тагын бер мөһим вакыйга булып узуын бу урында әйтми китү мөмкин түгел. 1969 нчы елның 21 нче августында сионистларның изге әл- Экъса мәчетен яндыруларыннан соң гарәп-мөселман дөньясында жанлану булып ала, сентябрь аенда исә Ислам Конференциясе Организациясе (Organisation of Islamic Conference-OIC) оеша. Бөтен мөселман илләре әгъза булып торган бу организация күп жыелышлар жыя һәм Палестина көрәшен сәяси, финанс һәм экономик яктан тәэмин итү буенча күп сандагы карарлар кабул итә. Ләкин бу ялтыравыклы вәгъдәләрдән сизелерлек бер файда да чыкмый. Шулай итеп, Палестиналылар азатлык көрәшенен авыр йөген үз жилкәләрендә күтәреп барырга Ялгыз калдырылалар.

Шуның өстенә Төркия кебек кайбер мөселман илләре, хәтта сионист берләшмәсе белән көчле мөнәсәбәтләр урнаштырудан да тартынмыйлар; икенчеләр исә Палестина көрәшенә турыдан- туры каршылык күрсәтәләр; башкаларга килгәндә, алар Палестина проблемасын хәл итүгә булышасы урында, үзләре алып барган мөселман-мөселман сугышлары белән мәшгуль булалар (Гыйрак Иран сугышы: 1980-1988); калганнар исә Палестина көрәшенда жинү теләп дога кылып утырудан уза алмыйлар. Шулай итеп, бу конфликт Палестинаның милли- проблемасы дәрәҗәсенә калдырып кечерәйтелеп, алга таба гарәп дөньясы өчен әһәмиятен бөтенләй югалта.

**Палестина азатлык көрәшендә ислам юнәлеше (тенден- циясе) барлыкка килү:**

Милли, секуляр һәм радикаль идеологияләрнең Палестина мәсьәләсен хәл итүдә уңышсызлыкка очравы прогрессив рәвештә Палестиналылар арасында исламга тартылу һәм бу проблемага ислам күзлегеннән карап чишелеш эзләргә омтылыш тудырды. Бу янарыш хәрәкәтенең беренче яралгылары "әл-

Ихваннар"ның "Шәехләр лагере "нда алып барган эшчәнлекләрендә дә бик ачык күренә: алар "Фәтәх" белән берлектә, 1968-1970 нче еллар аралыгында өч йөз ир-атны хәрби өйрәтелүләргә алып, аларны җиде партизан лагерьларына тараталар, алга таба бу көрәшчеләр берничә хәрби операцияләрдә бик уңышлы катнашалар. Икенче бер ислам организациясе "Усрат әл- Жиһад" ("Жиһад гаиләсе") 1948 нче елларда басып алынган җирләрдә берничә кыю операция оештырырга өлгерә, ләкин 1980 нче елда фаш ителеп, алтмыш әгъзасы кулга алына. 1984 нче елда бер мәчеттә утлы кораллар табылгач, кулга алынулар тагын да дәвам итә, ә Шәех Әхмәд Ясин һәм анын берничә коллегасы сионистларга каршы жиһади организация төзергә омтылуда гаепләнә. Икенче бер оешма "Ислам Жиһад хәрәкәте" исә 1980 нче елда төзелә, бу организацияне оештыручыларның күбесе “әл-Ихвән" хәрәкәтенең элеккеге әгъзалары булалар, бу хәрәкәт сионистларга каршы көтелмәгән берничә һөҗүм оештыра. Тулаем алганда, бу периодтагы ислам хәрби активлыгы "Фәтәх" кебек әйдәп баручы башка Палестина организацияләре каршылык белән чагыштырганда бик артык күзгә ташланмаса да, басып алынган Палестина территорияләрендә, Иордания, Күвәйт, Либнан һәм башка илләрдә алга таба исламчыларның рольләре популярлашуга бик яхшы җирлек нәкъ менә шушы чорда салына да инде. Житмешенче елларның азагында исламчылар акрынлап сәүдә өлкәсендә җитәкчелек итүне, шулай ук Иордания һәм Палестина университетларындагы (мәсәлән Нәблустагы эн- Нәҗәһ һәм Газадагы Ислам университетлары) студентлар жәмгыятьләрен үз кулларына ала башлыйлар. Алар шулай ук жәмгыяви, мәгариф һәм филантропик эшчәнлектә дә сизелерлек уңышларга ирешәләр. Шул рәвешле, исламчылар үзләренә киләчәктә халык арасында таралу һәм популярлашу өчен ныклы жирлек төзүгә ирешәләр. Сонрак ислам хәрәкәте, дөресрәге "әл- Ихвән әл-мөслимин" оешмасы ПАОның үзәк өлеше булып торган "Фатех" хәрәкәтенә төп конкурент булырлык дәрәҗәгә күтәрелә ала.[80]

## БИШЕНЧЕ ФАСЫЛ

### Палестина мәсьәләсе 1987-2001 нче еллар аралыгында:

Сионистлар тарафыннан басып алынган жирләрдә яшәүче Палестиналылар дошманга каршы зур тәвәкәллек һәм куркусызлык белән "Интифада әл-хижараһ" (ташлар баш күтәрүе) башлап җибәргән вакытта шаккаткыч хәл була: Ослода Тынычлык килешүенә кул куела. Алга таба Палестина житәкчелеге азатлык көрәшенә каршы репрессия сәясәте алып бара башлый һәм нәтиҗәдә интифадаһ бик зур зыян күрә. Бергә җыеп әйткәндә, бу чорда түбәндәге әһәмиятле вакыйгалар була:

- Интифадаһ башланып киту һәм хәрби мөселман көрәш хәрәкәте барлыкка килү.
- 1993 нче елда Палестина халкының киләчәгенә катастрофик фажигаләр китерүче Осло Тынычлык килешүенә кул куелу.
- Гарәп илләренең үз араларында конфликтлар көчәю, мәсәлән Гыйракның Күвәйтне басып алуы. Шулай ук Иордания һәм сионист берләшмәсе арасында тынычлык килешүе төзелү.
- Советлар Союзы таркалу нәтиҗәсендә күп санлы яһүдләрнең Палестинага күчеп килүе; АКШнын бердәнбер көчле держава булып калып, бөтендөнья жандармы ролен кабул итүе.

**Изге Интифадаһ:**

1987 нче елның 8 нче декабрендәге сионистлар тарафыннан алдан планлаштырган машина авариясендә дүрт Палестина эшчесенең үлүе нәтиҗәсендә шушы ук көнне Изге Интифадаһ башланып китә һәм бу хәрәкәт алдагы алты ел буена (1987-1993) дәвам итеп, Көнбатыш Яр Буе һәм Газа Полосасындагы сионист империализмының төп нигезен сизелерлек какшатуга ирешә. Ислам хәрәкәтләре шунда ук бу халык баш күтәрүләренә кушылып китәләр һәм 9 нчы декабрьдә Жәбәлья мәчетендә иртәнге намаздан соң демонстрация оештыруда башлап йөриләр. Хотим Әбу Сис һәм Рәид Шәһәдәләр исә Изге Интифадаһтагы беренче шәһидләр булалар. Соңрак демонстрация Көнбатыш Яр

Буе һәм Газаның бөтен өлешләренә дә таралырга өлгерә. Жыеп әйткәндә, Интифадаһ моңарчы урын алган Палестина каршылык көрәшеннән үзенә генә хас дүрт сыйфаты белән аерылып тора:

1) Моңа кадәр булып узган рәсми Палестина каршылык кораше илнең "Тышкы ягы" тарафыннан алдан планлаштырылган һom житәкчелек ителгән булса, интифадаһ исә илнен "эчтәге", ягъни Көнбатыш Яр Буе һәм Газа халкының үзе тарафыннан барлыкка китерелә һәм алга таба житәкчелек ителә.

2) Бу баш күтәрүнең нигезендә ислам тенденциясе ята, шуна да ислам рухы бу көрәшне илнең бөтен өлешләрендә дә бердәм рәвештә кабызып җибәрүче төп көч булып тора.

3) Палестина халкы, үзләренең яшьләре һәм саяси карашларында чагылган аермалыкларга карамастан, барысы да бергә берләшеп бу интифадаһта курку белми көрәшәләр.

4) Интифадаһта Палестина балалары ("Әтфаль әл- хижараһ" — "таш балалары") һәм хәтта хатын-кызлар да бик актив катнашалар. Ил халкының бу рәвешле бергәләшеп көрәшүе бер яктан бердәмлек, минминлектән азат булу һәм кин күңеллелек кебек асыл сыйфатларны барлыкка китерсә, икенче яктан жәмгыятьтә урын алган коррупция, бозыклык һәм хыянәт кебек көрәшкә зыян китерүче сыйфатларнын тамырына балта чаба.

Интифадаһның беренче дүрт елы бетен халык катнашындагы бунт күтәрүләр, демонстрацияләр уздыру, сионист мәдәни администрациясенә каршы бойкот белдерү һәм шулай ук җәмгыятьне хыянәт, наркотиклар һәм башка шундый бозыклыклардан чистарту кебек күренешләр белән характерлана. Алга таба, шулай да, халык массасының бу көрәштә тоткан роле кими барып, интифадаһ чын мәгънәсендә сионистларга каршы героик хәрби операцияләр һәм сюрпризлар ясау рәвешен ала. 1993 нче елдагы Осло тынычлык килешүе нигезендә "Фәтәх" һәм аның ПАОдагы фикердәшләре интифадаһның бетүен игълан итәләр. Шулай да "әл-Жиһад" һәм "Хамас" кебек Палестина мөселман организацияләре бу көрәшне алга таба да дәвам итеп, жиһад идеясен тагын да үстерәләр. Ләкин 1994 нче елның маенда басып алынган җирләрдә формалашкан Палестина автономиясе

ил халкының бу көрәштә массакүләм катнаша алу мөмкин- челеген юкка чыгара. Шул вакыттан башлап, сионистларга каршы алып барылучы бу хәрби көрәшнен бөтен авырлыгы ислам җәмгыятьләренең хәрби әгъзалары җилкәсенә төшә.

ПАО биргән статистик мәгълуматләр буенча, алты еллык бу интифалаһ вакытында 1540 Палестиналы шәһид киткән, 130 мен яраланган һәм тагын 116 мең кеше кулга алынган.[81] Бу күрсәткечләр, албатта, бу көрәштә бирелгән корбаннарның саны зур булуын күрсәтеп торса, корбан бирү үзе исә Палестина халкының тәвәккәллеген һәм җиһадка бирелгәнлеген бик ачык итеп исбатлый.

**Хамас:**

"Хамас" – Интифадаһ башлану белән, төгәлрәк әйткәндә, 1987 нче елның 14 нче декабрендә оешкан мөселман каршылык көрәше харакате. Ул нигездә "әл-Ихвән әл-Мөслимин"нен варисы булып тора, шуңа да бу хәрәкәтнең төп идеологиясе, карашлары һәм миссиясенең бердәнбер чыганагы булып ислам дине санала. Хамаснын үз конституциясе игълан иткәнчә, бу хәрәкәтнең төп максаты булып түбәндәге мәсьәләләр тора: халыкка ислам белеме бирү. Палестинаны тулысынча азат итү һәм бу жирдә, чын мәгънәсендә ислам, дәүләте төзүгә ирешү.

Хамас студентлар һәм шулай ук интеллигенция вәкилләре арасында киң күләм популярлык казануга ирешә. Бүгенге көнгә кадәр анын кандидатлары сайлау вакытларында төрле профессиональ җәмгыятьләрдә, Нәжәһ, Газа, әл-Хәлил, Бир Заид, әл-Кудс кебек университет студентлары арасында һәм шулай ук инженерлар, докторлар, фармокологистлар, юристлар, укытучылар һәм сәүдәгәрләр арасында 30-50% тирәсе тавыш жыюга ирешәләр. Секуляр Палестина галиме Хишам Шәрәби әйтүенчә, Хамас каршылык көрәшенең моңарчы күрелмәгән яна бер шәкеле булып тора, бу жәмгыять ПАО һәм анын Фикердәшләре чирек гасыр буена ирешә алмаган җиңүләргә, бигрәк тә Палестина массаларын бердәм, мөстәкыйль һәм дошманга каршы көрәштә инициатива бирүче бер көчле хәрби рамка кысаларына кертә алуга иреште.[82]

Хамаска нигез салучы шәхес гыйлем иясе, инвалид Шоех Әхмәд Ясин була. Габделгазиз әр-Рантиси, Мәхмүд аз-Заххар һам Габдел Фаттах Духәннәр исә аның Газа Полосасындагы топ ярдәмчеләреннән булалар. Хамасның Көнбатыш Яр Буендагы филиалының оештыручы житәкче л әре булып Жәмәл Салим,[83] Хәсән Йосыф һәм Жәмәл әл-Нәтшалар санала. Хамасның Палестинадан читтәге күренекле житәкчеләре, аның саяси бюросының элеккеге һәм хәзерге көндәге президентлары арасыннан Халид Мишьәл һәм Муса Эбү Мәрзукъ, шулай ук хәрәкәтнең рәсми вәк и л е Ибраһим Гушәһ һәм башкаларнын исемнәрен аерып атап үтәргә мөмкин. Сонгы мәгълумәтләр буенча, Хамас интифадаһ башланганнан алып 1996 нчы елга кадер жиде йөз шәһид биргән, шулай ук меңнәр яраланган, кулга алынган. Жиһадның катлаулылыгын һәм аның чикләнгә н сферасын исәпке алганда, бу зур сандагы югалтулар булып исәпләнә.

Әлбәттә, Палестиналыларның сәясәт өлкәсендәге йомшаклыкларыннан, сионистларның бик югары дәрәжәдә яхшы коралланган булуларыннан, гарәп-мөселман дөньясының үзен көчсезләндереп һәм эчтән таркатып торучы төрле каршылык, аерымлыклар белән тулы булуыннан һәм б үгенге көндәге ин көчле дәүләтләрнең сионист берләшмәсен яклавыннан бик яхшы хәбәрдәр булган Хамаслылар туган жирләрен хәзер үк һәм тиз арада азат итәргә мөмкин түгеллеген бик яхшы аңлыйлар. Бу реалистик житәкчелек фикеренчә, бүгенге көндә бара торган суг ы ш -жиһад әле озын булачак, бер буыннан икенчесенә күчәчәк, ләкин менә хәзер иң мөһиме: бу авыр стадияда бары тик бу мәсьәләне дөнья жәмгыятенә гел, березлексез ишеттереп тору да иң хәерле — эшләрдән булачак. Хәзер ин хәерлесе мөжәһидләрнен биргән корбаннары аркылы жиһад рухын киләчәккә саклап алып бару.

Хамаслылар эшне бик жирена житкереп башкаралар, хатта Израил аналитиклары яңа шәһидләрнең жиһадка чын күңелдән бирелгән булуларын “гаҗәеп уникаль калибр" дип атыйлар. Израил экспертлары Хамаска динамизм һәм уйлап табу сыйфатлары хас дисә, Израилның хәрби сугыш разведкасы генералы Ури Саги Хамасны супер организация, гаҗәп дәрәжәдә

яшерен һәм аның хәрби операцияләренә нәтиҗәлелек хас дип белдерә.

Хамас хәрәкәтендәге динамизм аның җитәкчесе кулга алынган яисә үтерелгән кебек критик очракларда бик тиз вакыт эчендә, кыска гына белдерү белән җитәкчелекне алтернатив шәхескә тапшыра алу сәләтендә дә бик ачык күренә. Бу хәлләр 1989 нчы елда Шәех Ясин һәм 1995 нче елда Әбу Мәрзукълар кулга алынганда күзәтелә; шулай ук 1993 нче елда Гимәд Гакыйль, 1996 нчы елда Яхья Гыяш һәм 1998 нче елда Мөхетдин Шәрифләр шәһид киткәндә һәм 2000 нче елның маенда Мөхәммәд әд-Дәйф кулга алынганда кабатлана.

1994 нче елда ПАО белән сионист берләшмәсе арасында килешү-сделка төзелгәннән соң жиһад мөмкин булмаган, дөресрәге рөхсәт ителмәгән нәрсәгә әверелсә дә, Хамас 1994- 1998 нче еллар аралыгында Газа һәм Көнбатыш Яр Буе территорияләрендә үзләре теләгәнчә идарә итүләрен дәвам иткән сионистларга каршы берничә героик операция оештыра. Мәсәлән, 1994 нче елда сионистларның әл-Әкъсада массакүләм үтерүләреннән үч алып оештырылган биш көнлек операция һәм Яхья Эйяш (1996 нчы елның февраль-март айлары периодында берничә хәрби операция оештырып, бу операцияләрдә җитмеш сионистны үтерүгә һәм өч йөз кырыкны яралауга ирешкән шәхес) үтерелгәч жавап йөзеннән оештырылган берничә операция булып уза. һаман да үсә барган бу дулкыннан курка калган Израил һәм аның союзниклары Халыкара конференция оештырып, Палестиналыларның көрәшләрен "терроризм" дип атап, "бу терроризм"га каршы көрәш алып барырга карар кылалар. Конференциядән соң сионист берләшмәсе һәм Палестина житәкчелегенең икесе тарафыннан (шулай ук Америка белән дә берлектә) Палестина жирендәге ислам тенденциясен тамырдан юкка чыгару өчен рәхимсез кампанияләр башланып китә. Хамас бу вакытларда үзе өчен бик авыр булган иң кырык чор кичерә, Палестина житәкчелегенең Тынычлык проекты иса. атаклы Палестина лидеры Сәиб Урайкать сүзләре белән әйтсәк Хамаска иң кырыс, ин миһербансыз һәм иң көчле ударны ясаучы була. Шуңа өстәп, хәрәкәт хәтта илнең тышкы ягында да басым һәм репрессияләргә дучар ителә. Нәтижәдә, Әбү Мәрзукь

Американда кулга алына (1995 нче елның июленнән 1997нен маена кадәр), 1997 нче елның сентябренда Халид Мишьалне үгерергә тырышалар, 1999 нчы елның августында Иорданиядәге Хамас офисларын ябалар һәм мондагы дүрт төп житәкчене шушы ук елның ноябрь аенда Катарга куып, калганнарын исә кыска вакытка төрмәләргә ябалар.

Сионистлар һәм шулай ук үз Палестина житәкчелеге тарафыннан төрле кысуларга дучар ителгән Хамас, чиктән тыш авырлыклар кичерүенә карамастан, барысын да гаҗәпләндереп, һаман да яшәвен дәвам итә. Ул илнең эчендә һәм шулай ук тышкы дөньяда торган саен күбрәк шөһрәт казана, анын һәм интеллигенция кандидатлары сайлауларда студент жәмгыятьләрендә, гадәттә, жиңеп чыгалар, яисә "Фәтәх" белән тигез нәтиҗәләргә ирешәләр.[84]

Икенче бер ислам хәрәкәте "әл-Жиһад әл-Ислами" дә Хамас кебек үк анфагонизм һәм кысулардан газап чиксә дә, сионистларга каршы берничә кыю һәм сыйфатлы операцияләр оештыруга ирешә, мисал итеп 1994 нче елнын ноябрендә Нецаримда, 1995 нче елның гыйнварында Бәйт Лидта, 1996 нчы елның мартында Тел Авивта булып узган операцияләрне китерергә мөмкин. Бу хәрәкәтнең житәкчесе Фәтхи әш-Шикакый 1995 нче елның 26 нчы октябренда сионист Моссад оештырган шпионлык операциясе вакытында үтерелә. Хәрәкәтнең халык арасында популярлык ягына килгәндә, статистик мәгълүмәтләр күрсәтүенчә "ал-Жиһад" хәрәкәте студентлар арасында бары тик 3-5% популярлыкка гына ия.

**ПАО: коралы көрәштән — тынычлык сделкасына:**

ПАОнын хәрби нигезен юкка чыгарырга тырышып эзлекле һәм агрессив рәвештә алып барылган һөҗүмнәр бу оешма рәтләренең сәяси яктан бик нык түбән таба тәгәрәвенә китерә. 1987 нче елның октябренда булып узган Амман Гарәп конференциясендә ПАОның гарәп илләре арасында тәэсире бик нык киму сизелә. Шулай да Изге Интифадаһ ПАОга сәяси аренага чыгарга бик яхшы мөмкинчелек бирә, ул бу мөмкинчелекне акыл һәм зирәклек белән кулланып, үзенен

Палестинадагы җитәкчелек итү ролен яңадан ныгытуга ирешә. Әлбәттә, бу көрәштә "Фатах" һәм башка группалар да актив катнаша, ләкин Интифадаһта берләшкән милли үзәк һәм житәкчелек ролен нәкъ менә ПАО үзе башкара. Бу хәрби каршылыкка каршы сионист берләшмәсе р әхимсез һәм канлы үч алу кампанияләре белән җавап бирә, шушы үч алулар вакытында, тәгәлрәк әйткәндә 1988 нче елның 16 нчы апрелендә ПАОдагы икенче кеше булган ган Әбу Жиһад үтерелә. житәкчелек итүдә Шушы ук елның 31 нче июлендә Иордания хөкүмәте Көнбатыш Я р Буе территориясе белән кануни һәм административ идарә итү жаваплылыгын үз өстеннән төшергән карар кабул итү белән, ПАО инициативаны үз кулына алып, үзен Палестина халкынын бердәнбер вәкиле һәм җитәкче көче дип игълан итә һәм шул рәвешле "Палестинанын тыныч юл белән һөжүме" девизы астында үзенең эшчәнлеген башлап җибәрә.

1988 нче елның 12-15 нче ноябрьләрендә булып узган Унтугызынчы Палестина Милли Советында исә ПАО БМОНЫҢ Палестинаны гарәп һәм яһүд дәүләтләренә бүләргә дигән 1947 нче елдагы 181 нче номерлы резолюциясен үзенә нигез итеп алган Палестина Программасы төзи. Шул рәвешле, бу организация егерме бер ел эчендә беренче тапкыр Иминлек Советының Палестина проблемасын бары тик качаклар проблемасы итеп кенә караган 1967 нче елдагы 242 нче номерлы резолюциясен рәсми рәвештә таный. Бу ачы хакыйкатьне халыкка "баллы" итеп күрсәтү өчен, Палестина Советы Палестинаның "мөстәкыйльлеген" игълан итә. Бу алдавыч игълан, шулай да, халыкара җәмәгатьчелек тарафыннан бик жылы кабул ителә, берничә ай эчендә 120 дәүләт Палестина дәүләтен рәсми рәвештә тануларын игълан итәләр. АКІШ һәм Көнбатыш Европа илләре исә яңа дәүләтне танудан баш тарталар. Бу "мөстәкыйль" яңа дәүләт теориядә һәм исем белән генә булып, практик яктан бернинди күзгә күренгән нәтиҗәга ирешә алмаса да, ул Палестина мәсьәләсең яңадан кабыза, ПАОның бу зур чигенуе һәм аңлаешсыз сәясәт алуына карамастан, оешманың сәяси тәэсирен бик нык арттыра.

Сиксәненче еллар азагы, туксанынчы еллар башында гарәп дөньясының үз эчендә һәм шулай ук халыкара сферада да

шактый фаҗигале вакыйгалар булып уза. 1990 нчы елның 2 нче августында Гыйракның Күвәйтне басып алуы һәм нәтиҗәдә Фарсы Култыгы сугышы булу бу регионга һәм Палестина мәсьәләсенә зур фаҗига алып килеп, үзенең катастрофик тәэсирен хәзерге көнгә кадәр саклап килә: гарәп илләре арасында ачы дошманлык барлыкка килү, аларның байлыклары һәм ресурслары киму, Гыйрак армиясенең нигезе, сәләте һәм мөмкинчелекләре юкка чыгарылу, йөзләгән, хәтта меңләгән Палестиналыларның Күвәйттән куып чыгарылуы, шулай ук гарәпләрнең ПАОга хәрби һәм финанс ягыннан ярдәмнәре тукталу...

Халыкара вакыйгаларга килгәндә исә, бу период Советлар Союзы һәм гомумән социалистик блокның җимерелүе шаһиды булып тора. Көнбатыш дөньясының элеккеге конкуренты һәм дошманы булган бу дәүләтләр, үзләренең килеп туган бу кризис максаты белән АКШ һәм анын хәлләреннән чыгу союзникларыннан финанс ягыннан ярдәм эзли башлыйлар; шул рәвешле, акрынлап бу дәүләтләргә бәйле була баралар, аларның капиталистик-демократик модельләрен үз системаларына шаблон итеп алалар. Бу вакыйгалар, әлбәттә, дөнья сәясәтендә моңарчы хөкем сөргән сәяси балансны житди үзгәртә. Әгәр гарәп илләре һәм Палестиналыларның бу баланс сәясәтен үзләренә кулай итеп файдаланган булуларын исәпкә алсак, бу үзгәрешләрнең Палестина мәсьәләсенә ни дәрәҗәдә зыян салуын аңларга бик жиңел булыр иде.

Шулай итеп, Америка Кушма Штатлары туксанынчы еллар башында дөньядагы бердәнбер көч-куәт иясе булып кала. Ә инде про-Сионист Америка президенты Клинтон идарәсендә яһудләрнең тәэсире үсү вакыйгаларны тагын да начарайта. Бу президент илдәге төп дүрт министрлык постын яһүдләргә бирә: Тышкы Эшләр министрлыгын Мадлен Олбрайтка, Финанс министрлыгын - Роберт Робинга, Оборона министрлыгын Уильям Коxенга һәм Авыл Хуҗалыгы министрлыгын Гликменга. Шуңа өстәп, Милли Иминлек Советының унбер әгъзасының жидесе яһуд милләтеннән була, шулай ук Үзәк Банк президенты Гринспен һәм ЦРУ директоры Джордж Тенетлар да яһуди булалар.

Бердәнбер супер көч булып калган АКШ, актив рәвештә, узенен "яна денья системасы (сәясәте) тәртибе" концептын бөтен денья жәмгыятенә көчләп тага. Ә бу сәясәт исә Палестина эшен ябып читкә алып куя, әлбәттә, АКШның стратегик союзнигы Израил өчен бу бик кулай була. Социалистик блок жимерелгач, Рәсәй һәм Көнчыгыш Европа илләре дә үзләренең Израил белән дипломатик мөнәсәбәтләрен яңарту өлкәсендә ныклап эш алыш бара башлыйлар, шулай ук Палестинага массакүләм яһуд эмиграциясен рөхсәт итәләр. 2000 нче елның 7 нче маенда сионист берләшмәсе 1989 нчы елның сентябреннән алып Рәсәйдән Израилгә эмиграция ясаучыларның саны бер миллионга житүен бәйрәм итә, бу бер миллионынчы эмигрантны сионист берләшмәсенен Премьер Министры үзе кабул итә.[85] Бу эмигрантлар дулкыны белән Израил жиренә туксан ике мен сандагы төрле әһәмиятле һөнәр ияләре дә килә, алар арасында бернича мен атом-төш физикасы экспертлары,[86] күп сандагы югары хәрби офицерлар да була. Нәтиҗәдә, Израил дәүләтенең һәм аның сионист-империалистик проектының бу регион өчен куркынычы тагын да арта.

Сионист берләшмәсе өчен шундый бар яктан да идеаль булган шартлар тудырган бер чорда, АКШ 1991 нче елның октябренда бөтен гарәп илләрен Мадрид Гарәп-Израил Тынычлык конференциясенә жыя. Нәтиҗәдә ике дошман як арасында ике елга сузылган турыдан-туры рәсми килешүләр алып барыла, ләкин "кеше сүзенә колак салмаучы" тәкәббер сионист берләшмәсе үзенең позициясен үзгәртми. Шул ук вакытта, төгәлрәк әйткәндә 1993 нче елның 20 нче январенда, Норвегиянен Осло шәһәрендә Хәйдәр Габделшәриф жи- тәкчелегендәге Палестина делегациясе һәм ПАОның күпчелек лидерлары катнашуында ике дошман як арасында икенче бер яшерен сөйләшүләр алып барыла. Бу сөйләшүләр нәтиҗәсендә 1993 нче елның 19 нчы августында Осло Тынычлык килешүе кабул ителү халык өчен уйга килмәслек шаккаткыч сюрприз вакыйга була. Шул ук елның 13 нче сентябренда бу килешүгә рәсми рәвештә кул куела. АКШ президенты Бил Клинтонның үзе катнашында узган бу вакыйгада Ясир Арафат һәм Израилнен Премьер Министры Ицхак Рабиннар да катнаша. Палестина ягыннан килешүгә кул куючы Мәхмүд Габбас була, сионистлар

ягыннан Израилнең Тышкы Эшләр Министры Шимон Перес кул куя. Америка һәм Рәсәй Тышкы Эшләр министрлары иса шаһидләр буларак кул куялар.

Осло Килешүе[87] теоретик яктан кыска вакытка исәпләнгән, ул Палестиналыларга Газа Полосасында һәм Иерихонда үзидарәләрен булдыруны тәэмин итеп, бу эш киләчәктә Палестинаның җирле халык яшәгән башка өлешләрендә дә дәвам итәргә тиеш була. Бу килешү буенча Палестина хөкүмәтена мәгариф, сәламәтлек, социаль тәэминәт, налог җыю һәм туризм өлкәләре өчен җаваплылык бирелергә тиеш була. Килешүнен авыр проблемаларын хәл итеп, аларга сонгы статус бирү өчен ике ел вакыт бирелә. Сионистлар шушы вакыт белән уйнап, Палестина житәкчелеген алда санап үтелгән җаваплылыклардан мәхрүм итеп калдыру өчен мөмкин булганның барысын да эшләп калырга өлгерәләр. Сионистлар Палестина хөкүмәтенә баштан ук бик оста уйланылган таләп куялар: башта Палестина хөкүмәте Хамас һәм башка каршылык көрәшләрен туктата, менә шуннан соң гына Израил Палестина хөкүмәтенә бу җаваплылыкларны бирәчәк.

Бу сөйләшүләр сионистлар өчен кулай булган берничә килешү төзелү белән тәмамлана: 1994 нче елның 4 нче маенда Каһира килешүе, 1995 нче елның 28 нче сентябренда Таба килешүе, 1998 нче елның 23 нче октябренда Уай Ривер килешүе, 1999 нчы елның 4 нче сентябренда Шәрм Шәех аңлашу меморандумнары... Нәтиҗәдә үзидарә регионнары А һәм Б категорияләренә бүленә. Палестина идарәсе А категориясенә кергән жирнең 17% ында иминлек һәм идарә эше алып барса, Б категориясенә кергән җириен 25% ында административ контрольлек итүгә ия була. Икенче категория жирләрдә иминлек белән идарә итү исә сионистлар белән бергә алып барылырга тиеш була. Ин аянычы, Палестина хөкүмәтенең бүгенге көнгә кадәр төп мәсьәләләр буенча ныклы килешүгә ирешә алганы юк

Гомумән алганда, Осло килешүенен төп хаталарын түбәндәге фикерләргә туплап биреп булыр иде:

1. Палестина мәсьәләсе — бетен мөселман өммәтенең уртак проблемасы. Ул берничек тә бары тик бер партия яисә бер буын проблемасы итеп кенә карала алмый. Һәрбер

мөселманның, ул Палестиналымы юкмы, бу мәсьәләгә катнашырга хокукы бар. Өммәтнең бөтен атаклы голамәләре бу алыш-бирешнең харам икәнен ачык итеп әйттеләр һәм Палестина жирен тулысынча азат иткәнче жиһад алып барырга чакырдылар.

2. ПАО җитәкчелеге, Палестина халкы, алар арасындагы зур күләмле ислам группалары, суллар, милләтчеләр белән киңәшләшүне кирәк тә санамыйча, хәтта үзенең бер өлеше "Фәтәх"ның да сионистлар белән бу түбәнлекле алыш- бирешкә барудан баш тартуын исәпкә алмыйча, бу килешүләрне берүзе үтәде.

3. ПАО, Израилнең "яшәү өчен көрәшергә хакы бар"дип таныл, 1948 нче елда басып алынган 77% Палестина жирен бөтенләйгә югалтты.

4. Бу ике арадагы алыш-бирешь Палестина мәсьәләсенең "ин нечкә яклары"н бөтенләй хәл итми, бәлки ПАО, кодрәтле һәм монополист сионист дәүләтеннән, хәтта бу хакта уйларга да мөмкин булмаган "киң күңеллелек" өмет итеп, мәсьәләнең түбәндәге **иң мөһим** якларын хәл итүне һаман да суза килә:

- Изге шәһәр Кудснын (Иерусалем) киләчәге. Сионистлар аны үз дәүләтләренең мәңгелек башкалалары һәм рухи үзәкләре дип игълан итеп, аның 86% жирен конфискацияләүгә ирештеләр. Үзләренен бу шәһәрне яһүдләштерү максатларына ирешү өчен, шәһәрнен көнчыгыш өлешенә ике йөз меңнән артык яһудне китереп урнаштырдылар.
- Биш миллионнан артык Палестина качакларынын киләчәген хәл итү мәсьәләсе буенча горизонтта бернинди дә нәтиҗәле чишелеш күренми.
- Палестинаның 62% жирен конфискацияләү бәрабәренә төзелгән Көнбатыш Яр Буе регионындагы 160 һәм Газа Полосасындагы 16 яһуд колонияләренең һәм шулай ук аларда яшәүче 200 мең яһуднең киләчәге хакында сионистлар дәшмиләр.

1. Тышкы иминлек һәм чикләр өчен җавап бирү Палестина хөкүмәте жаваплылыгына керми. Шуна өстәп, бу "үзидарә" булган территорияләргә хәрби шәхесләр керү, яисә корал керту, бары тик Израил хөкүмәте рөхсәте белән генә була

ала, шуна өстәп, бу территорияләрдә армия жыярга да рөхсәт ителми.

2. Израил хөкүмәтенә бу көчеш чорында Палестина хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән теләсә нинди карарларга вето куярга хак бирелгән.

3. Гомумән алганда, бу килешүләрдә Палестиналыларның үзидарәгә һәм мөстәкыйль дәүләт төзергә хаклары бар дигән идея бөтенләй күтәрелми, бәлки киресенчә, Көнбатыш Яр Буе һәм Газа жирләре "басып алынган" жирләр итеп түгел, ә бары тик "бәхәсле территорияләр" итеп кенә карала.

4. ПАО, сионист берләшмәсенә каршы бернинди хәрби каршылык көрәше алып бармаска дип килешүе аркасында, үз халкы сионистларга каршы алып барган теләсә кайсы каршылыкны тар-мар итәргә тиешле булып кала. Нәтиҗәдә, ул үзе идарә иткән территорияләрдә Израилнең иминлеген саклау сакчысына әверелә. Үзенең Израил белән ике арадагы бу кыл өстендә торучы килешүен саклауны кайгыртып һәм сионистларга карата яхшы мөгамәлә күрсәтү максатында Палестина идарәсе үз халкы арасындагы оппонентларын кулга алу һәм башка явыз кампанияләр үткәрү белән шөгыльләнергә тиешле булып кала.

ПАОның бу дилеммасы күренекле Палестина язучысы Эдвард Сәгыйд сүзләрендә бик ачык чагыла: "Гарафат үз халкын аннан качарга бөтенләй мөмкин булмаган капкынга кысрыклап кертте".[88] Палестина галиме Хишам Шәраби исә җитәкчелеккә сарказм белән: "Карарга килергә яисә үзидарә урнаштырырга бөтенләй сәләтсез"[89],- дигән бәя бирә.

**Палестина автономиясе һәм хәзерге көндәге ситуация:**

1994 нче елның 18 нче маенда Палестина полициясе Газага керә һәм шушы ук елның 5 нче июлендә яңа җитәкчелек әгъзаләре Гарафат алдында конституцион ант кабул итәләр. Тынычлык килешүе тирәсендә туган шик-шөбһәләрнең күбесе урынлы булуы бик тиз арада исбат ителә. Бу узидаранен вакытлыча гына булуы һәм күп мәсьәләләрнең һаман да уртак чишелеш таба алмавы сәбәпле, Палестина җитәкчелегенә жир

бирү эше бик акрын һәм чиктән тыш чикләнгән күләмдә бара. Бу вакытлыча куелган хөкүмәт, нәтижада, сионист берләшмәсенен тоткыны булып кала, хатта бөтенләй әһәмияте булмаган мәсьәләләргә ирешү өчен дә сионистларның "кин күңеллелегенә" һәм рәхим-шәфкатенә бәйле була. Кырыс сионистлар, үз чиратларында, бу уенда чиктән тыш дәрәжәдә салкын кан белән уйныйлар: килешү дәвамында алар тагын да күбрәк ташламалар сорауны дәвам итәләр, шуңа өстәп, Палестина хөкүмәтеннән хәрби каршылыкны бастыруын һәм хәтта бөтенләй юкка чыгаруын таләп итәләр. Бу максатларына ирешү өчен, сионистлар Хамас һәм “әл-Жиһад әл- Ислами" группаларын ил өчен куркыныч каршылык итеп сурәтлиләр һәм Палестина дәүләтен төзүгә ирешү өчен җитәкчелек иң башта, һичшиксез, бу хәрәкәтләрне рәхимсез тар-мар итәргә тиеш дип белдерәләр.

Бүгенге көннәргә кадәр сионистлар үзләре яраткан бу "сабыр итеп көт һәм нәтиҗәсен күрерсен" уенын уйнауларын дәвам итәләр. Осло килешүе буенча 1998 нче елга кадәр хәл ителергә тиешле төп мәсьәләләрнең берсе дә, хәтта бүгенге көннәргә кадәр, хәл ителмәгән. Палестина җитәкчелегенен юрисдикциясе бары тик кеше күп яшәгән торак пунктларны гына үз эченә ала, чөнки сионистлар исламчыларны кисәкләргә бүлгәләү, халыктан налоглар жыю кебек пычрак эшләрен нәкъ мена Палестина хөкүмәте кулыннан эшләтергә телиләр. Жыеп әйткәндә, сионистлар бу территорияләрдә "чиста империализм" булдырырга исәплиләр.

Шул ук вакытта бу территорияләрдә бюрократия һәм иминлекне саклау өчен чыгымнар дәрәҗәсе бик кызу темплар белән үсә. Идарә полициясенең саны 40 меңгә җитә, бу сан, илдәге халык саны белән чагыштырганда, дөньядагы иң югары нисбат исәпләнә. 2000 нче елга кабул ителгән ил бюджетының 70% ы иминлекне саклау һәм Арафат офисына тотылырга исәпләнгән. Сәламәтлек саклау, мәгариф, электричество һәм башка шундый жәмгыять чаралары министрлыклары һәм сервизларының барысына да исә бары тик бюджетның калган кечкенә кисәге тотыла.[90]

Бу "дәүләт-полиция"нең төп чыгымнары, шул рәвешле, халыкның саяси азатлыкка ирешү өчен көрәшенә һәм көнкүреш яшәү шартларын яхшыртуга тотылырга тиешле акча хисабына алына. 1995 нче елның маенда басылган БМО Үсеш программасы отчёты буенча, Газа Полосасындагы бер кешенең еллык уртача кереме 500 Америка долларына кадәр кискен кимегән, бу исә 1993 нче ел белән чагыштырганда 38% ка азрак дигән сүз.[91] 2000 нче елның апрелендә күренекле Палестина шәхесләре халык хокукын яклау җәмгыяте белән берлектә Вашингтонда Осло Килешүен сәяси һәм экономик катастрофа дип атаган документ бастыралар һәм Арафатның үз җаваплылыгыннан баш тартуын сорыйлар. Бу документта әйтелгәнчә, илдәге уртача керем 1993 нче ел белән чагыштырганда 30% ка төшкән, шул ук вакытта илдәге эшсезлек саны өч тапкырга арткан.[92]

Кайбер ышанычлы чыганаклар Палестина житәкчелеге арасында исрафчылык, бозыклык (фәсәд), әшнәчелек кебек тискәре күренешләрнең бик кин урын алуына басым ясыйлар. "Фәтәх"нен элеккеге җитәкчесе Мөхәммәд Жиһад әйтүенчә: "Арафат үзен караклар һәм оппортунистлар көтүе белән әйләндереп алган".[93] Аның икенче бер коллегасы исә илдә башкаларны санга сукмау, ришвәтчелек, женси тотнаксызлык кебек сыйфатлар артудан зарлана.[94] Палестина житәкчелегенең Югары Советы Күзәтчелек Комитеты 1997 нче елның маенда биргән рапортта исә илнең финанс өлкәсендә коррупция күренеше киң таралу телгә алына, монда хәбәр ителгәнчә, бюджетта каралган 1500 миллионның 326 млн. доллары[95] хөкүмәт тарафыннан үзләштерелгән. Советның бу шаккаткыч саннан күңеле шулкадәр кайта ки, әгъзаләре бертавыштан дип әйтерлек (56-1) Арафат хөкүмәтенә каршы тавыш бирә. 1999 нчы елның ноябрендә исә шушы "мөстәкыйль" дип аталучы җирләрдә гомер сөрүче егерме галим һәм күренекле шәхесләр "Егерме петициясе" кабул итәләр. Бу петиция Палестина җитәкчелегенең бозыклык, әшнәчелек һәм деспот сәясәте чыганагы икәнлеген ачып бирә. Шул ук вакытта Хишам Шәрәби: "Хәзерге көндәге Палестина житәкчелеге бу жир халкы вәкиле түгел. Ул халыкның хәзерге көндәге авыр шартларын яхшы якка үзгәртергә бөтенләй сәләтсез. Бу хөкүмәт, фактта, үзе үк менә шушы илдәге катастрофаның бер сәбәбе булып тора"[96],— ди.

Бу житәкчелекнең иң зур "уңышы" булып илдәге оппозицион якны рәхимсез рәвештә бастырып, аның тамырын чабып өзү санала алыр иде. Хакимлекнең беренче елларында ук инде бу житәкчелек уникедән артык кулга алу кампанияләре оештыра, хәтта кечкенә генә Газа Полосасында да (363 кв.км) егерме дүрт полиция пункты һәм егерме өч хәрби блокпостлар урнаштыра. Шул ук вакытта, ислам хәрәкәтенә каршы террорлык сәясәте кулланып, бер айдан да азрак вакыт эчендә (1995 нче елның 19 нчы апреленнән 9 нчы маена кадәр периодта) илле жиде мәчеткә 138 тапкыр тенту ясый,[97] сионистларга каршы үткәрелгән һәрбер жиһад операциясеннән соң рәхимсез рәвештә үч ала. Житәкчелек Хамаслыларнын Яхья Эййәш үтерелгәннән сон сионистлардан үч алып оештырган шәһидлек операциясенә карата бигрәк тә шәфкатьсез була. Хөкүмәт һәм Хамас арасында тыныч юл һәм сөйләшүләр белән генә мәсьәләләрне хәл итәргә омтылыш уңышка ирешә алмый. Хәтта житәкчелек берничә тапкыр сөйләшүләр алып бару өчен хөкүмәт органнарына килгән Хамаслыларны кулга ала, жәзалый. Хамаслы Хәсән Йосыф һәм Жәмәл Сәлим белән дә нәкъ менә шундый башка килмәслек хәлләр кабатлана. Бу систематик сионист-Палестина-Америка иминлек координациясе, шул рәвешле көрәш алып барып, күп сандагы жиһад операцияләрен алдан фаш итеп юкка чыгара һәм күпләгән мөҗәһидләрне кулга алуга ирешә. 1997 нче елның январенда кеше хокукын яклау организацияләре хәбәр итүенчә, Палестина төрмәләрендә шул вакытта 1600 тоткын булып, шуларның 700 енә хәтта хөкем дә булмаган.[98] Хәзерге көнгә кадәр бу тоткыннарның егермесе газаплап үтерелгән.

Шул рәвешле, сионист берләшмәсе җирле халыкның жирләрен конфискацияләү, Көнбатыш Яр Буе һәм Газа өлешләрендә колонияләр төзү, Палестинага массакүләм яһүдләрне китерту, Иерусалемдагы ислам эзен юкка чыгару кебек репрессияләр алып барган вакытта Палестина житәкчелеге исә оялмыйча да үз азатлыклары өчен көрәш алып баручы халык жиһадына каршы килеп, мөҗәһидләрне газаплап көн күрә.

(Бу урында 2000 нче елның 28 нче сентябрендәге әл-Әкъса баш күтәрүеннән соң Палестина җитәкчелегенең оппозициягә карашы үзгәрүен әйтеп китү бик урынлы булыр иде.

Җитәкчелектәгеләр сионистларның үз килешүләрен үзләре да үгәмәгән, тәкәбберлек белән Палестина халкын көннән-көн катырак кыса барган бу чорда геройларча кыю рәвештә үзләрен һәм изге җирләрен яклап кулларыннан килгәнчә агрессорларга каршы көрәш алып барган үз халкына Палестиналыларга каршы мондый бастыру тактын кулланунының мәгънәсезлек икәнен бик яхшы аңлыйлар. Җитәкчелек үзенең каршылык активлыгына карата тыюларын киметә, күп тоткыннарны азат итә, шулай ук сионистларга каршы демонстрацияләр оештыруга һәм протест хәрәкәтләре алып баруга ирек бирә. Әлбәттә, хөкүмәт Израил гражданнарын үтерүне ачыктан-ачык тәнкыйтьли, шәһидлек операцияләрен якламый. Шул ук вакытта бу операцияләрне аклап, аларны сионистларның варварлыкларына, гаепсез Па- лестиналыларны үтерүләренә, аларның милекләрен конфиска- цияләүләренә, дини һәм изге җирләрен атакалауларына каршы табигый реакция дип белдерә).[99]

**Сионист берләшмәсе һәм хәзерге көндәге ситуация:**

21 нче гасырга кергән көннәрдә сионист берләшмәсенен инде мактанырлык уңышлары, ныгып-зураеп, көчле илләрнең актив ярдәме белән бөтен Палестина җирен басып ала алырлык, бу җирләр белән идарә итә алырлык бөтен мөмкинчелекләре дә була. Үзенең оешкан көннәреннән алып илле ике ел эчендә (1948- 2000), ул, гарәп-мөселман деньясының көчсезлегеннән файдаланып, Палестина җиренә 2900000 эмигрантлар алып килергә, шул рәвешле басып алынган Палестина җирендә яһүдләр санын кискен рәвештә арттыруга ирешә: 1948 нче елда Палестина җирендә 650000 яһуд исәпләнсә, 2000 нче елның азагында бу җирләрдәге яһүдләр саны 4947000 гә житә. Бу — дөньядагы бөтен яһүдләрнең 38% ы дигән сүз.[100]

Советлар Союзы һәм коммунистик блок таркалу нәтиҗәсендә ул илләрдәге яһудләр дә озакка сузылган изоляциядән чыгуга ирешәләр. Рәсәй һәм Көнчыгыш Европа илләре хөкүмәтләре сионист берләшмәсе белән дипломатик, сәяси һәм икътисадый бәйләнешләрен яңартырга һәм ныгытырга омтылалар. Шуңа өстәп, катастрофик Фарсы Култыгы сугышы (1990-1991) һәм Осло килешүенең уңышсызлыкка очравы

Иорданияне дә сионистлар белән тынычлык килешүе төзергә этәрә. Катар, Оман, Тунис кебек башка гарәп илләре дә сионист берләшмәсе белән ике арада сәүдә эше алып барырга килешәләр. Дөньядагы тагын илледән артык дәүләт сионист берләшмәсе белән дипломатик һәм экономик бәйләнешләр урнаштыра.

"Азатлыкка ирешү планы"ның һәм гарәп илләре алып барган сугышның тукталуы сионист берләшмәсенә чагыштырмача тотрыклылык (стабиллек) бирә, бу исә ил экономикасының ике тапкыр үсүенә китерә. Илнең җирле производствосы товарлары кыйммәте 1983 нче елда 15.3 млрд. Америка долларына тигез булса, бу сан 2000 нче елда 105.4 млрд.ка сикерә. Икенче сүзләр белән әйткәндә, җирле производство товары жиде тапкырга, төгәлрәк әйткәндә — 689% ка арткан, бу исә илнең Америка һәм башка чит илләрнен ярдәменә бәйлелеген кискен киметә. 1983 нче елда экспорт товарлары милли керемнең 25% ын тәшкил иткән булса, 2000 нче елда исә бу сан 4% ка гына калган, ә экспортның еллык суммасы үзе бер үк күләмдә, ягъни дүрт миллиард доллар. 2000 нче елда сионист берләшмәсендәге бер кешелек еллык керем 18300 долларга житә. Бу сан дөньядагы иң биек күрсәткечләрдән санала. Израил экспортларының кыйммәте 1990 нчы елда 11.6 млрд. доллар булган булса, 2000 нче елда исә 23.6 млрд. долларга үскән. Илнең 2000 нче елдагы кереме 40 млрд. доллар, ә чыгымы исә 42.4 млрд. доллар булып тора. Бу доход бөтен Сирия, Мисыр һәм Либнанның доходларын бергә алып караганда да, алардан 8 млрд.ка югарырак дигән сүз.[101]

Израилнен армиясенә килгәндә исә, ул кораллану һәм солдатларның мөмкинчелеге буенча Якын Көнчыгыштагы ин көчле армия санала. Аның регуляр солдатлар саны 178 мен, ләкин бу сан житмеш ике сәгать эчендә 700 меңгә җитә ала, башка мәгълүматлар буенча исә аның резервтагы көче хәтта бер миллион санала. Бу армия гадәти һәм шулай ук күпләп юк итү коралларына ия булу буенча да иң югары дәрәҗәдә, Америкада чыккан ин яна кораллар иң беренче һәрвакыт бу армиягә килеп тора. Шуңа өстәп, Израилнең ике йөзләп үз компаниясе дә сугыш индустриясе белән шөгыльләнә. Шуңа күрә дә АКШ үзенең сионист берләшмәсе белән рәсми килешүендә Израил

армиясенең көче бөтен гарәп илләре армияләре көчләрен бергә алганда да күпкә артык булуга гарантия бирә. Сионист берләшмәсе ике йөздән артык атом-төш коралына ия, монда шулай ук бу илнең корал чыгару буенча дөньяда бишенче урында торуын да өстәргә кирәк. Бу дәүләт 1999 нчы елда гына да башка илләргә 2 млрд. долларлык кыйммәткә корал сатарга контракт төзегән.[102]

Шунысын да әйтергә кирәк, сионист берләшмәсенен дә саяси, хәрби һәм җәмгыяви проблемалары юк түгел. Хәтта әйдәп баручы төп сәяси партияләрнең эчендә дә үзара килеш- мәүчәнлекләр һәм конфликтлар булу илнең сәяси тотрык- лылыгына зур зыян китерә. Шул ук вакытта Израил армиясе чагыштырмача артык санда һәм деморализацияләнгән, бу исә кайбер үз-үзләрен үтерү яисә дезертирлык кебек тискәре күренешләргә китерә. Җәмгыятьнең социаль тукымасы исә Әшкиназ, Сәфәрдим һәм Фәләшә кебек төрле яһүд җәмгыятьләре арасындагы дини һәм расачыл конфликтлар тәэсирендә акрынлап таркала бара, нәтиҗәдә аерылышулар саны үсә... Туучылар саны бик аз булу сәбәпле, Рәсәй һәм Көнчыгыш Европадан килгән яһуд эмиграциясе илдәге яһуд халкының төп чыганагы булып тора. Шул ук вакытта Америка һәм Көнбатыш Европа яһүдләренең Израилгә эмиграция ясарга теләмәүләре дәүләткә тискәре тәэсир ясый. Бу алда санап үтелгән проблемалар барысы да сионист проектының киңәю планына һәм дәүләтнең киләчәгенә куркыныч тудыра.

Әлбәттә, бу проблемалар әлегә сионист берләшмәсен бөтенләй юкка чыгарырлык дәрәҗәдә җитәрлек житди төс алырга өлгермәгән. Бу ил әле һаман да сәяси, икътисадый һәм ижтимагый даирәләрдә бик йомшак булган гарәп-мөселман илләре арасында хәрби яктан ин көчле булуын дәвам итә. Бу кечне бары тик киләчәктә төрле яктан уяну-ренессанс кичерүче гарәп-мөселман дөньясы белән йөзгә йөз очрашу гына юкка чыгара алачак.

**Кудс (Иерусалем) һәм хәзерге көндәге ситуация:**

1948 нче елгы сугыш вакытында яһудләр Иерусалемнын көнбатыш өлешен, ягъни изге шәһәр территориясенең 84.1% ын

басып алуга ирешәләр. Бу яуланган жирләрнең 85% ы гарәпләр милке булган булса да, сионистлар бу территорияне бик тиз арада яһүлләштерүгә ирешәләр: монда яһудләр өчен торак урыннары төзиләр, якындагы гарәп авылларының жирләрен конфискациялиләр. Мәсәлән, Израил Парламенты Кнессет һәм берничә министрлык элеккеге Лифта исемле гарәп авылы урынына төзелгән, шулай ук якындагы Әин Кәрим, Дэйр Ясин һәм әл-Мәлиһә авыллары да жир йөзеннән юкка чыгарылган.[103]

Сионистлар алга таба шәһәрнең көнчыгыш өлешен дә үзләренә кушып һәм бу җирләрне кулларыннан килгәнчә кызу темплар белән яһүдләштереп, 1967 нче елга инде бөтен Иерусалем жирен басып алуга ирешәләр. Шунысы аянычлы: мөселманнарның изге мәчетләре әл-Әкъса урнашкан бу көнчыгыш өлеш Көнбатыш Яр Буе регионының бер кисәге булып торган була. 1967 нче елның 27 нче июнендә изге шәһәрнең ике өлеше дә Израил хакимияте астына берләштерелә. Ә 1980 нче елның 30 нчы июлендә исә бу Берләшкән шәһәр рәсми рәвештә сионист берләшмәсенең башкаласы дип игълан ителә.[104]

Әлбәттә, яһуд-сионист идеологиясе буенча тарихи һәм дини яктан бик мөһим урын алып торган бу Иерусалем шәһәренә ирешү яһудләрнең иң баштан ук төп максатлары булган була. Хәтта сионист берләшмәсе төзелгәнче илле ел элек үк, Бөтендөнья Сионист Организациясен оештыручы шәхес Герцль болай дигән: "Әгәр дә без Иерусалемны мин үлгәнче басып ала алсак, мин үзем шәхсән андагы яһудләр өчен изге булмаган һәрбер нәрсәне жир йөзеннән юкка чыгарып, гасырлар буе төзелгән бөтен кыйммәтләрне яндырачакмын".[105] Израил дәүләтен фактта оештырган шәхес һәм бу илнең беренче Премьер Министры Давид Бән-Гурион исә бу мәсьәләгә кагылышлы түбәндәге фикерне әйткән: "Израилнең Иерусалемнан башка мәгънәсе юк, а Иерусалемның исә Сөләйман храмыннан башка мәгънәсе юк".

Сионист берләшмәсе, эзлекле һәм киңкүләм яһүдләштерү программасы нигезендә, Иерусалем шәһәре жирен Көнбатыш Яр Буе территориясе ягына дәвамлы рәвештә зурайта бара. Мәсәлән, 1967 нче елда шәһәр территориясе 6.5 кв.км. булган булса, 1990

нчы елда исә 123 кв.км.га җитә. Дәүләт алга таба бу планны тормышка ашыруны дәвам итеп, 840 кв.км. жирдә "Бөек Иерусалем" шәһәре төзергә исәпли, бу исә Көнбатыш Яр Буе регионының тагын 15% ы киләчәктә басып алыначак дигән сүз. Сионистлар Көнчыгыш Иерусалем территориясендә һәм иске шәһәр (әл-Әкъса мәчете дә шунда төзелгән) тирәсен бөтен яктан әйләндереп алып, чылбыр рәвешендә унбер яһүд торак кварталлары төзиләр, монда хәзер 190 мен яһүд исәпләнә. Ә инде зуррак чылбыр — унжиде яһүд колониясе исә Иерусалем шәһәренең үзен төрле яктан әйләндереп алып төзелгән һәм нәтиҗәдә бу шәһәрне тышкы гарәп-мөселман дөньясы тәэсиреннән изоляцияләп тора. Шулай итеп, киләчәктә Палестина дәүләте төзелгән очракта да Иерусалем шәһәрен, хэтта аның мөселманнар өчен изге булган әл- Экъса мәчете урнашкан территориясен дә берничек тә инде Палестиналыларга бирү мөмкин булмаячак.[106]

2000 нче елгы статистик мәгълүмәтләр буенча, Көнбатыш һәм Көнчыгыш Иерусалемның халык саны 650 мен исәпләнә, шуның 450 мене яһүдләр булса, калганнары, ягъни 200 мене гарәпләр булып, алар күбесенчә шәһәрнең көнчыгыш өлешендә яшиләр. Шул рәвешле, Британия оккупациясенә кадәр шәһәрнен 90% ы гарәпләр кулында булган булса, Иерусалем прогрессив һәм агрессив рәвештә яһүдләштерелеп, 2000 нче елда инде яһүдләр шәһәр территориясенең 86% жиренә хужа булып торалар. Хәзерге көндә гарәпләрдә шәһәрнең бары тик 4% жире генә сакланып калган, калган 10% жир исә киләчәктәге яһүд планнары өчен резервта тора.[107]

Бу фажигалар арасында ин аянычлысы — әлбәттә, мөселманнарның изге әл-Әкъса мәчетенең язмы язмышыдыр. Көнчыгыш Иерусалемны басып алуга берничә көн үтүгә, яһүдләр мәчетнең әл-Буракь стенасы (бу стена яһүдләрдә "елау стенасы" исеме белән атала) каршына урнашкан әл-Мәгърибә кварталын жимерәләр. Бу кварталда урнашкан 135 йорт һәм 2 мәчетне жир белән тигезләп, яһүдләр бу урынны үз ритуалларын үткәрү өчен ачык җиргә әверелдерәләр. Алар монда Сөләйман храмының калдыклары бар дип фараз итеп, шуларны табу өчен бу жирдә һәм Иерусалемның көньяк һәм көнбатыш өлешләрендә бик

житди рәвештә археологик казу эшләре алып барсалар да, аларның бөтен табылган әсбаплары ислам диненә кагылышлы тарихи калдыклар булып чыга. Бу исә шәһәрнең хаклы рәвештә ислам шәһәре булуын бик ачык исбатлап тора. 1967 нче елдан алып 2000 нче елга кадәр яһүдләр кызулык белән, ләкин яшерен рәвештә ун этаптан торган казу эшләре алып барып, әл-Әкъса мәчете астына туннель казыйлар һәм мәчетнен фундаментын какшату һәм жимерү өчен химик матдәләр кулланалар. Бу мәкерле һәм астыртын ният белән оештырылган эшләр нәтиҗәсендә, хәтта көчле давыллы яңгыр яисә йомшак кына жир тетрәү генә булган очракта да Изге мәчет җимерелергә бик мемкин.

Сионист-яһудләр 1967-1993 нче еллар аралыгында әл-Әкъса мәчетенә кырык тапкыр һөҗүм оештыралар. Бу котырынган һөҗүмнәрне хәтта, ике арада төзелгән Осло килешүе дә туктата алмый. Сионистлар бу килешүне бөтенләй санга сукмыйча, 1993- 1998 нче еллар аралыгында тагын җитмеш ике тапкыр бу мәчеткә атака ясыйлар. Ләкин бу атакалар арасында мөселманнарны соңгы чикка житкереп түбәнсеткәне һәм мыскыллаганы 1969 нчы елның 21 нче августында булган әл-Әкъса мәчетен яндыру фаҗигасе була. Шулай ук сионистлар дүрт тапкыр мәчетне бомбага тотарга талпыналар: 1980 нче елның 1 нче маенда, 1984 нче елның январь, август һәм декабрь айларында. 1989 нчы елның 17 нче октябренда исә бер төркем яһүд экстремистлары әл- Экъса мәчетенең керү урыны янына үзләре киләчәктә төзергә фараз иткән яһуд храмының беренче нигез ташларын салалар.[108]

Палестина халкы сионист берләшмәсе оккупациясе астында яшәүдән һәм мөселман-гарәп кардәшләренең ташлавыннан бик нык зыян күрсә дә, алар әл-Әкъса мәчетен саклап калу өчен кулларыннан килгәннең барысын да даими рәвештә эшләп киләләр. Һәрбер яһуд атакасы нигездә мөселманнарның үч алу һөҗүмнәреннән башка узмый. Яһудләр исә, үз чиратларында, тагын да кансызрак үч алу һәм массакүләм үтерүләр белән җавап бирәләр. Мәсәлән, 1990 нчы елның 8 нче октябренда әл-Әкъса мәчете эчендә үзләренә яңа храмның нигез ташларын салырга талпынган экстремист яһүд группасына каршылык күрсәткән халыкның 34е үтерелеп, 115е яралана. Ә инде яһүдләрнең мәчет

астында туннель казу эшләренә каршы протест рәвешендә кабынып киткән "ачулы баш күтәрү" вакытында (1996 нчы елның 25-27 нче сентябре) 62 Палестиналы шәһид китеп, тагын 1600 кеше яралана.[109]

1967 нче елдан башлап, БМО һәм аның Иминлек Советы Израилнен Иерусалем шәһәренең көнчыгыш өлешен басып алуын кире каккан һәм шәһәрнең статусын үзгәртергә омтылган теләсә кайсы физик, административ һәм кануни чараларны юкка чыгарган күп садагы резолюцияләр кабул итә. Алга таба алар, Израил дәүләтен басып алуда гаепләп, аның бик тиз арада Иерусалемнан һәм шулай ук Көнбатыш Яр Буе белән Газа дә чыгып китүен таләп итәләр. Бу өлешләреннән резолюцияләрнең беренчесе булган 2253 нче номерлы резолюция 1967 нче елның 4 нче июлендә кабул ителгән булып, 1980 нче елның 29 нчы июлендә исә, Израил Иерусалемны басып алгач, БМО бертавыштан дип әйтерлек (112 риза, 7 каршы һәм 24 - тоткарлана) ES 712 нче номерлы резолюция кабул итеп, сионистларны бөтен басып алынган җирләрдән, шул исәптән Иерусалемнан да чыгып китәргә чакыра. Икенче көнне исә Иминлек Советы бертавыштан дип әйтерлек (14 әгъза да риза, Ләкин АКШ катнашмый) ризалык белән резолюция чыгарып, Израилнең басып алуын туктатырга һәм Иерусалемнын статусын үзгәртергә омтылган бөтен чараларны законсыз дип хөкем итәргә карар чыгара. Шул рәвешле, бу резолюцияләр Палестиналыларның үз җирләренә хокукларын рәсми рәвештә таныйлар, ләкин шул ук вакытта Израилне көч белән бу резолюцияләргә буйсындыру механизмы бөтенләй эшләнмәгән була һәм бу хакта беркем дә җитди рәвештә уйланмый, шуңа да Израил бу резолюцияләрдәге карарларны үтәргә хәтта кирәк тә санамый.[110]

**"әл-Әкъса" күтәрелеше (2000 нче елның 28 нче сен- тябреннан алып 2001 нче елның декабрена кадәрге чорга күзәтү):**

Палестина мәсьәләсенә кыскача күзәтү рәвешендә язылган бу хезмәт инде тәмамланып килгән бер чорда үзенә аерым игътибар таләп итүче бер бик мөһим вакыйга урын алды. Бу

вакыйга – "Изге ал-Экъса күтәрелеше", бу дулкын сионистларның агрессиясенә каршы алып барылучы Палестина- гарәп-ислам каршылык көрәшен бөтенләй яна юнәлешкә кертеп җибәрде. Шуна да китапның бу соңгы бүлеген без нәкъ менә шушы үзенчәлекле көрәшкә багышларга һәм аның теп сыйфатларына кыскача күзәтү ясарга карар иттек.

Басып алынган җирләрдә массакүләм кабынып китү булсын очен бөтен шартлар да инде әзер иде: Израилнең хатта бөтендөнья җәмгыятенең акыллы тавышына колак салудан баш тартуы, шулай ук сионистларның Палестина мәсьәләсендәге ин теп проблемалар – качаклар һәм бу жирләрдәге яһуд колонияләренең киләчәге проблемаларын хәл итүдән качулары, аларның Иерусалемда, әл-Әкъса мәчетендә һәм башка Палестина жирләрендә яшерен рәвештә, ләкин киң күләмдә җимерү эшләре алып барулары, нәтиҗәдә бөтен тынычлык процессына куркыныч янау...

Израилнең Премьер Министры Барак 2000 нче елның 25 нче октябренда булып узган яшерен жыелышта болай дип белдерә: илдә килеп туган бу критик шартлардан иң яхшы чыгу юлы – "проблеманы кабынып китәргә этәрү"[111], икенче сүзләр белән әйткәндә, Барак күпме күбрәк каршылык күрсәтсә, шуның кадәр популярлыгы артачак һәм тынычлык килешүе төзү эше бөтенләй туктаячак, нәтиҗәдә йомшак Палестина җитәкчелеге күптән көтелгән җиңелүгә дучар ителәчәк, дип фикер йөртә.

Ләкин "доянен сыртын сындырган салам кисәге", ягъни халыкны бердәм рәвештә көрәшкә күтәргән вакыйга – Ликуд партиясе җитәкчесе террорист Ариель Шароннын 2000 нче елның 28 нче сентябренда әл-Экъса мәчетенең хөкем залына провакацион визит ясавы була. Ул үзе белән 600 солдат алып килә, тагын 3000 солдатны Иерусалем һәм аның тирә-ягы белән контрольлек итәргә куя. Шаронның тәкәбберләнеп һәм Палестина халкын түбәнәйтеп шушы рәвешле үз көчен күрсәтеп һәм каршы якны көрәшкә чакырып рәсми шоу ясавы Израилнең шул чордагы Премьер Министры тарафыннан да кин яклау таба. Ләкин мөселманнар бу провакацион актка кыю рәвештә каршы чыгалар, нәтиҗәдә биш кеше шәһид китә, йөздән артык кеше

яралана. Бу вакыйга бөтен мөселман дөньясында ярсу һәм ачу дулкыны уята, мөселман массасына бу изге жирне жаннары һәм каннары белән сакларга тәвәккәллек бирә.

"әл-Әкъса" күтәрелеше, җыеп әйткәндә, бөтен дөнья халкына түбәндәге хакыйкатьләрне ачып салды:

**Беренчедән**. Мөселман өммәте – исән, түзәлмаслык авырлыклар, җәрәхәтләр һәм катастрофик вакыйгалар да аның рухын сындыра алмаган, бәлки Өммәттә ин кирәкле сыйфатларның берсе жиһад рухы һәм шәһид китәргә теләү хисе сакланып кала алган. Гаҗәеп күренеш: мөселман дөньясының ин көнбатыш чиге булган Рабаттан алып көнчыгыш чиге Жакартага (Индонезия) кадәрге арадагы мөселман дөньясында массакүләм демонстрацияләр кабынып китә. Барысы да жиһадка – изге әл- Әкъса, Иерусалем, Палестинаны саклап калу өчен көрәшкә кушылырга чакыралар. Палестинага төрле яклардан, төрле юнәлешләрдән юмарт сәдәкалар агыла. Болар барысы да бу Бөек Мөхәммәд салаллаһу әләйһи вәссәллам Өммәтенең бөек потенциалын һәм аның җиңүгә ирешергә мөмкинчелеге барын бик ачык күрсәтеп тора.

**Икенчедән**. Палестина мәсьәләсе, Изге жир Иерусалем һәм әл-Әкъса — мөселманнарны бергә туплаучы көч, үзара булган каршылыкларны җиңеп бергә берләшергә, уртак дошман булган сионистларга каршы сугышырга әйдәүче төп сәбәп булып тора. Кыскача әйткәндә, бу мәсьәлә Өммәт игътибарының үзәгенә һәм аның төп проблемасына әверелә.

**Өченчедән**. Бу интифадаһ тынычлык проектына һәм сионистлар белән ике арада алып барылучы нормальләшү процессына житди удар ясый, жиһадның Палестина мәсьәләсен хәл итүдәге бердәнбер һәм иң хәерле чишелеш икәнлеген исбатлап бирә.

**Дүртенчедән**. Бу интифадаһ кешеләрнең карашларына, фикерләү рәвешләренә һәм көндәлек тормышларына да зур йогынты ясады. Сионист проектына һәм аны тормышка ашыруга төп ярдәм күрсәтүче Америкага булдыра алганча дошманлык

күрсәтеп, мөселман массалары үзгәреш кичереп, Америка һәм Израил товарлары һәм продуктларына бойкот белдерергә Согуд Гарәпстанында Мәсәлән, чакырдылар. Америка ресторанннары булган Макдональдс һәм КФС (KFC) ларда азык сатып алу кискен түбән тәгәрәп, 80% ка кимеде. Ә Мисырдагы Пепси Кола компаниясенең кереме исә 40% ка түбәнәйде. Халык үз илләрендә чыккан милли азык-төлек һәм эчемлекләр сайлый башлады. Нәтиҗәдә, кайбер Америка компанияләре үзләренен сионист берләшмәсе белән бәйләнешләре юклыгын киң рәвештә рекламаларга мәжбүр булдылар. Согуд Гарәпстанындагы Макдональдс, мәсәлән, интифадаһ вакытында һәрбер ашамлык сатудан кергән акчаның бер риялын (андагы акча берәмлеге) сәдәка итеп Палестинага җибәрә башлады.[112]

**Бишенчедән**. Үзләренә золым һәм җәбер салган сионистлар белән ике араны бары тик тынычлык килешүе төзеп кенә хәл итүнең бөтенләй гадел түгеллеген һәм үзләрен шул рәвешле мескен итеп залимнар алдында түбәнәйтү тиеш тә түгеллеген, шулай ук бу килешүләрдән бернинди дә файда чыкмаячагын төптән аңлаган Палестина һәм гарәп халкы шул рәвешле тынычлык программасы төзеп үзләренең бу изге җиргә булган хакларын башкаларка жиңел генә бирүдән бөтенләй баш тарттылар.

**Алтынчыдан.** Интифадаһ вакытында, бигрәк тә аның беренче стадиясендә про-сионист Көнбатыш медиасының Палестина мәсьәләсен үзләренә кулай итеп берьяклы гына яктыртуларын фаш итүдә мөселман масс медиасы, ТВ станцияләре һәм интернетның әһәмияте бик зур булды. Нәтижеде, Палестина мәсьәләсе буенча халыкара аренада илнен төп жирле халкы файдасына тагын да күбрәк яклау жыюга ирешелде.

Икенче яктан, төрле сәяси төркемнәрдән, яисә илнең төрле почмакларыннан булган Палестина халкының бергә берләшеп бу интифадаһта кин күләм катнашулары сионистларнын террористик жавап операцияләре күбәюгә китерде. Сионистлар халыкара закон буенча тыелган коралларны киңкүләмдә

кулландылар, күп очракларда бер гаепсез тыныч тормыш кешеләрен һәм самими балаларны үтерделәр.

Интифадаһның үткән унөч ае дәвамында Палестиналылар зур югалтуларга дучар булдылар. Статистик мәгълүматлар буенча, 2000 нче елның 28 нче сентябреннән алып, 2001 нче елның 28 нче сентябренә кадәрге бер ел вакыт эчендә 727 Палестиналы шәһид киткән, 30 меңләп кеше яраланган (кайбер башка статистик мәгълумәтләр буенча 35 мен), алар арасыннан 2800е гомерлек гарип булып калган. Шулай ук 159 Палестина сабыеның гомере өзелеп, тагын меңләп бала яраланган. 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган балалар бөтен югалтуларның 40% ын тәшкил итәләр. Шунысын да әйтергә кирәк, Палестина азатлыгы өчен көрәштә шәһид киткәннәрнең унөче 1948 нче елда басып алынган Палестина жиреннән булып, алар сионист империализмына каршы көрәшүче Көнбатыш Яр Буе һәм Газа өлешендәге туганнарына кушылып ып киткән булалар. Бу интифадаһ вакытында сионист берләшмәсе Палестиналыларның 5 менләп йортларын жимерә, 200 мең агачларны сындыра- яндыра, 95 мәктәпне бомбага тота, 218 авыл халкын блокадага тотып, аларны сусыз интектерә, Көнбатыш Яр Буе һәм Газа халкы арасында эшсезлек 11% тан 57% ка кадәр үсүгә сәбәпче була. Шулай итеп, бу жирләрдә 265 мең кеше эшсез кала, бу — аларны гаиләләре белән бергә санаганда, бер миллион һәм 270 мең кеше дигән сүз, ягъни бу ике территория халкының 45.5% ын тәшкил итә. Нәтиҗәдә, Палестина халкының 50% тан артыгы чиктән тыш фәкыйрьлек дәрәҗәсенә төшә...[113]

Шул рәвешле, кырыс сионистларның Палестина торак пунктларын блокада шартларында тотулары нәтиҗәсендә Палестина экономикасы авыр югалтуларга дучар була, икътисад өлкәсендә бер көнгә 19 млн. доллар югалту исәпләнә. Гарәп Эшчеләр Организациясе хәбәр иткәнчә, югалтулар ил яшәешенең (экономикасының) бөтен тармакларында да чагыла: көнлек югалту илнең завод фабрикаларында – 6.6, сәүдә өлкәсендә — 5.5, промышленностьта – 3.3 һәм авыл хуҗалыгында 3.2 млн. доллар исәпләнә.[114]

Сионист полициясе һәм хәрби кораллы көчләре хатта кулларында таштан башка бер нәрсә дә булмаган протесторларны да күрә торып ният белән атып үтерәләр. Шуна да корбаннарның 65% ы гәүдәнең өске өлеше – баш, жилкә һәм эч өлешләренә атылып үтерелә, шуна өстәп, бу үтерүләрнең 40% очрагында деньякүләм тыелган төр кораллар файдаланылган. 18 яшьтән кечерәк булган сабыйлар һәм яшүсмерләр исе ботен югалтуларның 40% ын тәшкил итә.[115] Сионист иминлек сакчылары үз кулларына төшкөн Палестина җитәкчеләрен, бигрәк тә Хамас һәм Фәтәх лидерларын, үтерүдә варварлык алымнарын кулланалар. Бу ерткычларча эшләнгән актларның барысы да сионист дәүләте үзе сөйләгән "демократия" һәм "модернизация" сыйфатларының аларга хас түгеллеген, гомумән, аларда бөтенләй юклыгын исбатлап тора.

Шул ук вакытта, сионистларның бу кансызлык һәм рәхимсезлекләре алар көткән нәтиҗәләрне бирми, инде нык дәрәҗәдә кабынып киткән интифадаһны туктата алмый, бәлки киресенчә, аны тагын да ныграк көчәйтә. Израиллеләр хәтта бер көн эчендә аларга каршы 50-60 лап хәрби операция оештырылуын үзләре үк яшермиләр. Шулай да сионист медиасында "матур һәм мавыктыргыч саннар" бирү бик еш күзәтелә. Шул рәвешле каршылык көрәшенең көчен кечерәйтеп күрсәтү һәм үзләренең югалтуларын яшерү кебек мондый "күз буяулар" публикага һәм сионист берләшмәсе солдатларына мораль яктан этәргеч бирү, Палестина можәһидләренә исә рухи яктан удар ясау һәм шулай ук гарәп-мөселман дөньясын бу сугышта катнашудан ерагайту максаты белән эшләнә.

Бу каршылык көрәшенә һәрбер Палестина хәрәкәтләре үзләренең өлешләрен кертәләр. Сионистлар үзләре хәбәр иткәнчә, Хамас, "әл-Жиһад әл-ислами", Фәтәх, "Халык һәм Демократлар Фронтлары" оештырган операцияләр нәтиҗәсендә бер еллык интифадаһ вакытында 165 сионист үтерелә, 1400 ләп яралана. Палестина азатлык хәрәкәтләре эшчәнлегенең сыйфатына килгәндә, бу группалар арасында Хамас үзе оештырган операцияләрнең иң сыйфатлы, югары кыйммәткә ия һәм сионистларга көтелмәгән удар ясый алу сәләте белән аерылып тора. Бу хәрәкәт бер ел эчендә 12 шәһидлек операциясе

оештырып, аз дигәндә 61 сионистны үгерүгә ирешә. Шунысын да әйтергә кирәк, бу һөҗүмнәрнең күбесе 1948 нче елда басып алынган Палестина жирендә, төбәп әйткәндә, Тел Авив, Нәтәния, Кудс, Нәхәрия һәм Гизза шәһәрләрендә оештырыла. Хамаслылар оештырган ике һөҗүм бигрәк тә игътибарга лаек. Беренчесе – 2000 нче елның 7 нче ноябренда оештырылган Рафаһ операциясе, монда Израил көймәсе җимерелүгә дучар ителеп, тирән суга батырыла. Икенчесе – Худәйрәһ операциясе. 22 нче ноябрьдә булып узган бу операцияда 21 сионист үтерелеп, тагын 65 кеше яралана. Шулай ук Хамас оештырган 31 нче декабрьдә булып узган экстремист КӘХ хәрәкәтенең лидеры сионист Бенжамин Кәхәнәне ликвидацияләү операциясен, 2001 нче елның январенда булган ике сионист танкын ерактан шартлату һәм шулай ук 4 нче марттагы Натанияһ Шәһидлек операцияләрен аерым атап китү бик урынлы булыр иде.

Бу каршылык вакытында бер ел эчендә 165 кеше үтерелү һәм 1400 кеше яралануны, дөреслектә, сионист берләшмәсе югары дәрәҗәдәге зур югалту дип исәпли. Чөнки моңарчы сионистларның еллык югалтулары 20-30 кеше тирәсе генә була торган була. Бу вакыйгалар нәтиҗәсендә Израил хәтта Көньяк Либнанны калдырырга мәҗбүр була.

Шулай итеп, интифадаһ сионистларга кыйммәткә төшә. Нәтиҗәдә, 2001 нче елның 6 нчы февралендә Баракның "Эшчеләр партиясе" хөкүмәттән төшерелә. Ләкин ил белән житәкчелек итү постына Ликуд партиясеннән булган тагын да кансызрак, экстремист һәм “гаепсезләрнең канына пычранган" сугыш криминалы Ариель Шарон утыра...

Кыскача әйткәндә, Интифадаһ сионист җәмгыятен куркуга сала, бу бигрәк тә аларның йөрүләре чикләнүдә ачык күренә, сионистлар автобуслар куллануда кача башладылар. Теләсә кайда һәм теләсә кайсы минутта шартлау булырга мөмкин урыннарда буш вакыт уздыруны яисә рекламалар ясауны мөмкин кадәр киметтеләр. Шулай итеп, аларның гарәп һәм мөселманнарны мыскыллы шартларда кысрыклап яшәтергә дигән хыяллары жилләр белән очып таралды, Тынычлык Проекты исә тарихның чүплек савытында бер мәгънәсез һәм файдасыз нәрсә булып калды. Бу интифадаһ сионистларның чын кабәхәт йөзен бөтендөнья

җәмгыятенә тагын бер кат ачып бирде. Варварларча үч алучы сионистлар кулыннан легендар бала Мөхәммәд әд-Дуррәһ үтерелү вакыйгасы турыдан-туры трансляция белән тапшырылып, бөтендөнья халкы бу ерткычлыкларга шаккатты.

Интифадаһ сионист берләшмәсенең экономикасына да кискен удар ясады. Туризм өлкәсендәге югалтулар миллиард доллар исәпләнса, Израилнең милли продукты кереме исә 9.8% ка тешке (интифадаһка кадәр, ягъни 2000 нче елның 3 нче кварталында бу өлкәдәге керем 9% ка кадәр күтәрелгән булган). Тышкы сәүдәдәге баланс 31% ка кимеде. Бу өлкәдәге кытлык 2000 нче елның октябрь ае өчен генә дә 486 млн. доллар тәшкил итә.[116] (2001 нче елның августында Израилнең көнлек финанс югалтуы 14-16 млн. доллар исәпләнә).

Интифадаһ сионист берләшмәсен нык селкетте, бу дәүләт төзелгәндә төп ике нигез итеп алынган "үзенне имин итеп тою" һәм "экономик яктан нык һәм тотрыклы булу" идеяләрен челпәрәмә китерде. Нәтиҗәдә, иминлек эзләп килгән дистәләрчә менләгән яһудлар Европа, Америка һәм Австралияга китү өчен чемоданнарын әзерли башладылар. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, Палестина жирендәге яһүдләрнең 25% тан артыгы илне калдырып башка жирләргә күчеп китү турында ныклап уйлана икон.

Сионист берләшмәсе, бигрәк ТО башлыгы Шарон, интифадаһны сүндерү өчен террорист алымнарын туктаусыз куллануын һаман да дәвам итә. 2001 нче елның 11 нче сентябренда Нью Йорктагы Бөтендөнья Сәүдә үзәге җимерелү вакыйгасы, нәтиҗәдә, Американың Афганстанны буйсындыруы, талибаннарга һәм Бин Ләденга каршы сугыш алып баруы сионистлар өчен "күктән төшкән бәхет" булды. Дөнья халкы бу вакыйгалар белән ыгы-зыгы килеп, Палестина мәсьәләсен вакытлыча онытып торган бу чорны Израил үзе өчен бик оста файдаланды: тагын да ныграк явызлык белән Палестина халкын массакүләм үтерү, жимерү һәм юкка чыгаруны дәвам итте. Ләкин бу интифадаһка теп куркыныч Палестинаның үз эченнән, ачык итеп әйткәндә үз җитәкчелегеннән яный. Хәзерге көндәге Палестина җитәкчелеге интифадаһны бастырып, сионист берләшмәсе белән сәяси алыш-бирешләрен алга таба да дәвам итәргә йөз тота.

## НӘТИҖӘЛӘР:

Хезмәтебезнең бу сонгы бүлегендә без Палестина мәсьәләсен өйрәнү барышында туган фикерләребезне һам нәтиҗәләребезне берга туплап, укучыларга жинел аңлашылырлык бер эзлеклелеккә салып бирүне кирәк дип таптык:

1. Палестина жире — изге һәм мәбәрәк жир. Аның төп жирле халкы Кәнгәнлеләр (Ханааняне) сонгы 4500 ел буена монда гомер сөрәләр. Бу жирдә яшәүче "Фәләстыйн" һәм башка гареп кабиләләре исә Кәнганлеләр белән акрынлап кушылган, ассимиляцияләшкән, гарәп теле исә барысының да аралашу һәм ана теленә әверелгән. Безнең эраның 636 нчы елында (һижри: 15 нче ел) Палестина жире исламга ачылып, халкы ирекле рәвештә ислам динен кабул иткән, зур ризалык белән Ислам дәүләте астында яшәгәннәр. Ислам хакимияте исә Палестина жирендә хөкем сөргән башка хакимиятләргә караганда иң озын вакытка сузылганы исәпләнә.

2. Мөселманнар Бәнү Исраил халкының ерак тарихта Палестина жиренең кайбер өлешләре белән 4 гасыр дәвамында идарә итүләрен кире какмыйлар. Ләкин монда шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: яһүдләр алга таба нигезендә бер Аллаһка ышану идеясе яткан хак дин — Аллаһе Тәгалә аларга индергән динне үзгәрткәннәр, аларга жибәрелгән пәйгамбәрләрне үтергәннәр. Шуна да Аллаһе Тәгаләнең ризасызлыгы һәм каргышына дучар булып, Палестина жиренә хужа булу хакын бөтенләй югалтканнар. Бу изге җиргә ия булу хакы исә автоматик рәвештә шушы Бер Аллаһка ышану идеясен күтәргән Мөселман Өммәте кулына күчә. Шуңа өстәп, яһүдләрнең чынбарлыкта соңгы 1800 ел буена Палестина жире белән сәяси һәм мәдәни яктан бернинди дә бәйләнешләре булмый (б.эраның 135 нче елыннан алып 20 нче гасырга кадәр).

3. Сионист хәрәкәте барлыкка килү һәм Палестина жирендә яһүдләр өчен Милли Ватан төзелүдә түбәндәге факторлар

теп рольне уйныйлар: Европа христианнарынын, бигрәк тә протестантларның, яһудләргә көчле ярдәме, национализм идеясе барлыкка килү, Көнчыгыш Европада "яһуд проблемасы" тууы, Европа һәм АКШтагы яһудләрнең идарә эшендә һәм шулай ук җәмгыяви даирәләрдә тәэсирләре бик нык үсү.

